PRESSA.RU

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№9 (297) – СЕНТЯБРЬ 2016

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан
нәшер ителә

Яңа «Әлифбалы»
мәктәпләр

Иннокам: киләчәк
контурлары

Борынгы
венгрлар эзләре

ТАТАРСТАННЫҢ КЫР БАТЫРЛАРЫ

PRESSA.RU

Полимочевина —
гидроизоляция нового поколения

Реклама



2015 елда Казанда су спорт төрләре буенча 16нчы дөнья чемпионатын ачу тантанасы.

СУНЫ ТЫНЫЧЛАНДЫРУЧЫ

Полимочевина теләсә кайсы өслекне судан саклау мөмкинлеген яңача хәл итә. Бу технологиянең Россиядәге иң эре вәкиле булып Татарстандагы «Эластолюкс» компаниясе исәпләнә.

«Эластолюкс» компаниясенең портфелендә – гаять зур проектлар.

2013 ел Универсиадасын ачу көнендә «Казан-Арена» стадионындагы гаҗәеп матур тамаша күпләрнең хәтеренә сеңеп калгандыр. Әмма ул тамаша барган бассейнның фанерадан ясалган вакытлы корылма гына икәнлеге берәүнең дә башына килмәгәндер, мөгаен. Ә бит аның өслегенә «Эластолюкс» салган нибары өч миллиметр калынлыгындагы полимочевина гидроизоляцияне тулысынча тәэмин итте!

2015 елда Казанда су спорт төрләре буенча дөнья чемпионатын ачу һәм ябу тантаналарын уздырганда да «Эластолюкс» хезмәтләреннән файдаланылды. Су тутырылган бассейннар каскадына махсус рәвештә урнаштырылып, 1500 диодлы яктырткычлар белән яктыртылган «Пилигрим» дип аталган искиткеч гүзәл күренешне күреп, «Татнефть-Арена» Боз сараена тамаша кылырга килгән 80 меңнән артык кеше генә түгел, төрле илләрдә яшәүче миллиардлаган телевизор караучылар да таң калды. 300 тонна суны сыйдырган бассейнның иң тирән (3 метр) өлешендәге өслекнең техник мөмкинлекләре нәтиҗәсендә стенаның кайбер өлешендә үтә күренмәлелекне тәэмин итү яктырткычын эшләү мөмкинлеге туды. «Эластолюкс»ның ярдәме кирәк булды. Полимочевинаның уникальлеге шунда ки: ул теләсә нинди материалдан ясалган өслек белән нык итеп тоташа, шул рәвешчә бөтен корылманы да ныгыта һәм аны судан ышанычлы саклый.

Агрессив мохиткә каршы торучанлык буенча да бүген «чиста» полимочевина белән бернине дә чагыштырып булмый. Әлеге технология теләсә кайсы йөзү бассейнына икенче тормыш бирә. Элегрәк су саркуны туктату өчен плита мозаикасын ватарга туры килә иде. Ә полимочевина ремонтка тотылырга тиешле акчаны янга калдырырга мөмкинлек бирә. Бүген өслекне эластомер белән каплаганда махсус җиһаз ярдәмендә сиптерү ысулын кулланалар. Кипкәч, гидроизоляциянең юка, җөйсез һәм үтә күренмәле катламы барлыкка килә.

«Эластолюкс» шулай ук сәнәгать объектлары белән дә нәтиҗәле эшли. Мәсәлән, «Алабуга» МИЗнда «Аутоматив гласс альянс рус» автопыяла җитештерү заводында чимал саклау өчен корылган түбә һәм бункерларга гидроизоляция ясалды.

Полимочевинага торак-коммуналь хуҗалыкта да ихтыяҗ арта бара. Полимочевина чыгымнарны экономияләргә дә ярдәм итә: әйтик, эретеп ябыла торган түбәнең шуу мөмкинлеген исәпкә алырга кирәк булса, полимочевина белән эшләгәндә мондый проблема юк, чөнки ул тоташ була. Шул ук вакытта башкарылган эшкә 10–15 еллык гарантия бирелә, ә материал үзе 50 ел «яши»! Таләп ителгән төстәге капламнарның исе юк, эш бер сменага 5000 кв. метрга кадәр тизлек белән башкарыла, каплам исә температураның 150 градус салкынлыктан 170 градус эсселеккә кадәр сикерүенә чыдый. Теләсә кайсы өслекне судан саклау мөмкинлеге технологиянең мөһим өстенлеге булып тора. Казан циркы гөмбәзенең полимочевина белән каплануына дүрт елдан артык вакыт узды, бу да аның ышанычлы икәнен раслаучы бер мисал.

Полимочевина теләсә кайсы өслеккә ябышу сәләтенә ия, һәм бу аны төрле зурлыктагы савытларны гидроизоляцияләү өчен файдаланырга мөмкинлек бирә. Инде берничә ел «Эластолюкс» ТР Газлаштыру фонды белән берлектә суэтем манараларын «Чиста су» ФМП кысаларында гидроизоляция эшләрен башкара. «Эластолюкс» бөтендөнья әйдәүче полимер җитештерүчеләрнең берсе – Huntsman-NMG капламнарын файдалана. 2014 ел азагында компания өчен махсус ELASTOLUX маркасы астында эчә торган су салына торган полимочевина эшләнде һәм патент алды.

«Эластолюкс» компаниясен Татарстаннан читтә дә яхшы беләләр. Алда телгә алынган компанияләрдән тыш, «Эластолюкс» клиентлары арасында «ТАИФ» ААЖ, «Менделеевсказот» ҖЧҖ, «Аммоний» АҖ, «Казан Оргсинтез» ГАҖ кебек тармак лидерлары бар. Бетон каплату эшләре сигез стадионда башкарылды, полимочевина технологиясе биналарның һәм корылмаларның 128 түбәсе, 88 чистарту корылмалары объекты, өч бассейн, 12 фонтан өчен кулланылды.

2015 елның җәендә Мәскәүдә «Христос Спаситель» гыйбадәтханәсендә «Милли байлык» хәйрия фонды «Россия икътисады үсешенә керткән өлеше өчен» номинациясе буенча «Эластолюкс» компаниясен Казандагы Универсиада-2013 һәм Сочидагы Олимпиада-2014 объектлары төзелешендә инновацияле технологияләр кулланган өчен, «Ватанның Алтын Йолдызы» ордены белән бүләкләде.

2002 елдан башлап, компания үзенең җайланмалар паркын киңәйтә һәм полимочевинаны төзелешнең төрле өлкәләрендә куллануны камилләштерә бара. Соңгы биш ел эчендә генә дә фирма тарафыннан 200 мең кв. метрдан артык эш башкарылган!

Реклама

«ЭЛАСТОЛЮКС» ҖЧҖ
Яр Чаллы шәһәре, тел.: +7 (906) 122-21-21, e-mail: elastolux@chelny.com, www.elastolux.ru



16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Троицкая
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская
Линар Закиров
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Веб-редактор: Олеся Бондаревская,
bond@tatmedia.com
Авторлар: Альберт Борһанов, Татьяна Колчина,
Катерина Котова, Владимир Матылицкий,
Искәндәр Хәбибуллин, Гадел Хәиров, Фаяз Хуҗин,
Ольга Шмелёва
Фотографлар: Солтан Исхаков, Ната Смирнова,
Александр Эшкинин
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Әхмәрова
Беренче тышлыкта Сарман районы комбайнеры
Наил Әхмәтшин улы белән. Александр Эшкинин фотосы
Соңгы тышлыкта Ләйсән һәм Аида Илһамовалар.
Ната Смирнова фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж: 3500 данә,
шул исәптән татар телендә – 1000.

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми. «Промо» һәм «Медиа» рубрикалары материаллары реклама-коммерция нигезендә басыла.

Журнал «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә **басылды:**

420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № М-2350

Басарга кул куелды: 23.09.2016

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com
Коммерция директоры:
Нина Әхмәтшина, nivlana@tatmedia.com,
тел. (843) 222-09-76
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Юлия Фәсахова, тел. (843) 222-06-05
Махсус проектлар бүлеге белгече:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru
Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ИҢ ТӨП ТОП-ИСЕМЛЕК

Без һәм без кылган гамәлләр – бу дөньяда барысы да үз урынына куелган. Рейтингларга, топ-исемлекләргә, хит-парадларга. Бу теләсә кайсы өлкәне бер рәткә тезә, аның структурасын кора һәм аңа ярыш төсе бирә – кечедән зурракка, яхшыдан начарга таба... Шуның аркасында кешелек рейтинглардагы «иңиңнәр» белән танышып бара: миллиардерлар арасындагы иң бай егерме кеше кем, иң матур җырлаучы беренче унлыкта кемнәр, иң шәп йөгерүче беренче бишлеккә кемнәр керә, акчасын уйламыйча да уңга-сулга таратучылар исемлегенең башында кем тора, Россиядә ауга йөрү өчен иң яхшы ун нокта, допинг белән тотылган Америка спортчылары кемнәр... Кем нәрсә белән кызыксына – һәркем өчен иң беренчеләрнең исемлеге бар.

Шушы төрледән-төрле, кайчак хәтта акылга сыймаслык исемлекләрдә чыннан да иң яхшылар югалып кала. Без аларны тормышыбызның әллә ни мәгънәле булмаган бер мизгелендә мәгълүмат шаукымы астында игътибардан читтә калдырабыз. Ун минут үтүгә без Голливудның иң бай гаиләләре рейтингындагы иң беренче фамилияне яки дөньядагы иң эре кофейня челтәренең исемен искә төшерә алачакбызмы? Шикле. Әмма без ул рейтингларга һәм топ-исемлекләргә даими рәвештә реакция белдерүебезне дәвам иттерәбез. 21 гасыр кешесенең баш мие шулай көйләнгән. Ләкин аны яңадан көйләргә – күктән җиргә төшәргә вакыт җитте. Җирдә исә һаман элеккечә – онытмаган булсагыз, Җир-анабыз һәм анда үсеп чыккан шытымнар. Көзгә ул мул уңыш булып өлгерә – быел исә ул бигрәк тә мулдан – республика бөртеклеләрдән 4 млн тонна уңыш җыеп алды. Узган елгыга, аннан алдагы елга караганда күбрәк. Чынлыкта исә бу – вакыйга. Алгарыш. Җиңү. Һәм иң яхшы комбайнчыларның топ-исемлеге Авыл хуҗалыгы министрлыгының интернет-сәхифәсендә тыйнак кына эленеп тора. Аңа лайк куймыйлар, үзләренең битенә күчереп алмыйлар, карамыйлар. Дәрәҗәсе ул түгелме? Рейтингы ул түгелме? Нибары халыкның кыйммәтләре үзгәрде. Икмәк – төп кыйммәт түгел анда. Бәлки, шулай тиеш тә булгандыр. Ипи бәясе белән чираттагы айфон бәясе чагыштырырлык та түгел бит. Ә куелган хезмәт ягыннан чагыштырып карасаң? Менә шунда проблемалар башлана да инде. Бер якта – халыкны ашатыр өчен теләсә нинди һава шартларында югалтуларсыз җыеп алынырга тиешле иксез-чиксез иген кырлары. Икенче якта – IT-акылның иксез-чиксез киңлекләре, аны исә бер бәләкәй тартмага сыйдырып бетерергә кирәк. Айфонның әлеге моделеннән туйган кешеләрнең тормышын җиңеләйтер өчен...

СЕЗНЕҢ РЕДАКЦИЯГЕЗ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«Татмедиа» АҖ
Нәшер итүче:
«Татмедиа» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе:
864 сум 24 тиен

Фото: Солтан Исхаков

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

6. Кыр батырлары. Татарстанның иң уңган комбайнчылары

12. Класс эшләре. Әгәр мәктәптә ремонт эшләнсә…

16. Кайсы мәктәп иң яхшысы? Экспертлар фикере

20. Имтиханга әзерлек. Балаларга нинди авырулар яный?

22. Иннокам киләчәкне төзи. Россия өчен илнең үсеш моделе кайда сынала?

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

50. Чүл патшасы командасы. «Дакар» герое белән әңгәмә

52. Туфан чишмәсе. Атаклы драматургның илһам чыганагы

56. Ташкент пәхләвәсе. Татар сыйларының чит җирләрдәге үзенчәлеге.

60. Спорт тормышы. Казанда – дөнья чемпионаты

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

66. Венгрлар һәм татарлар. Бу халыкларны ни бәйли

71. Татар авыллары. Республикабыз салаларында кунакта

76. Яшерен канцелярия. Яла ягучылар ни өчен «донос» сүзен яратмый

80. Ял сәгате. Көзгә кәеф тудыручы китаплар

84. Әдәби сәхифә. Нәбирә Гыйматдинованың «Акмаңгай» хикәясе

88. Җүкәтаулы төбәк. Чистай безне үзенә дәшә

112. Кара күл серләре. Биектаулылар нигә су үгезеннән куркалар

PRESSA.RU

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

26.08

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты, – электрон ММЧ редакторлары белән очрашуда:

– Дәүләт Думасында безнең көчле командабыз бар иде, хәзер бу команда тагын да ныграк, тагын да нәтиҗәлерәк булачак. Без алардан депутат значогын гына түгел, ә сайлаучыларга файда, безнең республика, шәһәрләребез, районнарыбыз, торак пунктларыбыз халкы сизәрлек гамәлләр көтәбез. Менә шундый бурыч куябыз.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

24.08

Илсур Метшин, Казан мэры, – педагогика хезмәткәрләренең шәһәр конференциясендә:

– Без төрле рейтингларда әйдәп баручы позицияләрне тотабыз, эшчәнлекнең барлык өлкәләрендә үсеш күрсәтәбез. Миңа шунысы мөһим: шушы күрсәткечләр белән беррәттән, Казан төп әһәмиятле репутацияне – игелекле кешеләр шәһәре дигән исемне дә яулый алсын иде. Ышанам, безнең тырышлыгыбыз белән Казан шәфкатьлелек, игелеклелек, ярдәмчеллек сыйфатларын һәр кеше норма буларак кабул иткән шәһәргә әверелер.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

5.09

Александр Прошкин, кинорежиссёр, XII Казан халыкара мөселман киносы фестиваленең жюри рәисе, – КХМКФ ачылышы алдыннан узган матбугат конференциясендә:

– Бүген, беркайчан да булмаганча, төрле халыклар арасында рухи диалогны җайга салу, башка мәдәниятләренең тирән катлауларын аңлау мөһим. Һәм бу мәгънәдә Казан халыкара мөселман киносы фестивале – бигрәк тә безнең күп конфессияле илдә – кинематограф үсеше күзлегеннән генә түгел, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр ягыннан караганда да уникаль һәм бик тә мөһим күренеш.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Татарстанның иң уңган кыр батырлары **КАЙСЫ** районда яши

Авыл мәктәпләрен капиталь ремонтлау **НИЧЕК** башкарылган

Татарстан мәктәпләре **НИНДИ** юнәлешләрдә белем бирә

Россия өчен илнең үсеш моделе **КАЙДА** сынала

PRESSA.RU

ТАТАРСТАННЫҢ **КЫР БАТЫРЛАРЫ**

«КОНТАКТТА» ДА, ОНЛАЙНДА ДА ТҮГЕЛ, АЛАР КОМБАЙНДА ЭШЛӘП ТИР ТҮГӘ!*

2016 елның эссе җәе, бәхеткә, Татарстан игенчеләренең уңышка йөз тоткан планнарын бозмады: республика урып-җыю эшләрен төгәлләде, бөртеклеләрдән гомуми күләме 4 млн тонна уңыш суктырып алды (чагыштыру өчен: 2015 елда әлеге сан – 3,6 млн тонна, ә корылыклы 2010 елда нибары 700 мең тонна булган иде). Быелгы урып-җыю йомгаклары буенча Авыл хуҗалыгы министрлыгы иң яхшы комбайнчыларның исемлеген бастырып чыгарды. Бу исемлекнең башында Сарман районы тора (гәрчә бөртеклеләрнең тулай күләме буенча Буадан калышса да): исемлектә аннан 15 комбайнчы бар. Шуларның бишесе «Нөркәй» хуҗалыгында эшли. Һәм 36 градуслы челләдә «Татарстан» Сарман кырларының батырлары янына юл тотты.

Автор: Татьяна Колчина

Быел хуҗалык бөртеклеләрдән һәм бөртекле-кузаклы культуралардан 48 мең тонна уңыш суктырып алган. Гектарына уртача 36,7 центнер – республикадагы иң яхшы күрсәткечләрнең берсе. Гәрчә Сарман районында җәй буена бер тамчы яңгыр төшмәгән. Бөтенләй дә.

«Нөркәй»нең җитәкчесе Вазыйх Гыйльметдинов бу «парадокс»ны бик гади генә аңлата:

КЕШЕЛӘР ЭШ СӨЯ, ТӨШКӘ КАДӘР ЙОКЛАП ЯТМЫЙ!

– Составына безнең агрофирма да кергән «Агросила ГРУПП» холдингы быел миллиард ярым сумлык авыл хуҗалыгы техникасы сатып алды. Комбайннарны гына да 20 данә сатып алдылар! Тагын берничә трактор, йөк төягеч, чәчкечләр һәм шикәр чөгендере игү комплексы. Чөгендерне соңрак җыячакбыз – көзге яңгырларны көтеп алырбыз, шәт.

Хуҗалык комбайнчыларының рекордлы казанышларын да шулай гади итеп аңлата Гыйльметдинов:

– Кешеләр эш сөя, төшкә кадәр йоклап ятмый! Комбайнчы кырда таңнан таңга кадәр инде ул. Монда сезгә шәһәр түгел, сигез сәгатьлек эш көне дигән төшенчә юк. Һава шартлары мөмкинлек биргәндә, эшлибез.

ИГЕНЧЕНЕҢ ИЗГЕ БУРЫЧЫ

Урып-җыю вакыты – авыл хезмәтчәннәре өчен кесә калынайтып, гаилә бюджетын тулыландырып калу өчен менә дигән форсат. Бер сезон эчендә – быел ул «Нөркәй»дә 18 июльдә башланып, 18 августка кадәр дәвам иткән – 150шәр мең сум эшләп калганнар. Ә иң мөһиме алар өчен барыбер беренчел чиратта – икмәк үстерүгә салынган хезмәт бушка китмәсен. Икмәкне нинди генә шартларда да җыеп алырга кирәк – игенченең изге бурычы ул.

* Волгоград егете Игорь Растеряевның «Комбайнерлар» җырыннан

PRESSA.RU



Николай Сапожников, 57 яшь.

Иген кырында яшьтән үк эшли. Комбайн штурвалы артында – 10 ел. Бу ел аның өчен икмәк суктыру буенча рекордлы булган: бәләкәй генә «New Holland»** та эшләп, ул 500 гектар җир эшкәрткән, 17 мең центнер бөртекчеләр уңышы җыеп алган. Комбайнның әлеге маркасы һәм моделенең бер сезонга уртача күрсәткече 12–13 мең центнер булганда әле бу.

– Әйбәт эшлидек. Кабинада кондиционер бар, эшләргә рәхәт. Бөтен кешегә дә офиста утырырга димәгән бит!

Наил Әхмәтшин, 44 яшь.

Комбайн штурвалы артында эш тәҗрибәсе – 17 ел. Сезон йомгаклары буенча меңнәрчә гектар эшкәрткән, 30 мең центнер икмәк суктырган. Быел кырда улы белән бергә эшләгән. Улы киләчәген, бәлки, авыл белән бәйләмәс тә, чөнки егетебез ТИСБИда логист белгечлегенә укый, шуңа да ипи кадерен һәрчак белер, дип өметләник.

– Кешеләрне ипи белән тәэмин итәм – шуңа сөенәм!

Линар Габдрахманов, 29 яшь.

Урып-җыюда җиденче сезоны. Шәхси рекордын 2014 елда куйган булган (дөрес, һава шартлары уңай килгән ул елны): 32 мең центнер җыйган. Быел Авыл хуҗалыгы министрлыгының исемлегенә бөртекчеләрдән 25 мең центнер уңыш суктырып, 800 гектар җир эшкәртеп эләккән.

– Без «бурыч» турында уйламыйбыз – без эшлибез. Менә икмәк. Аңа хезмәт кергән, тир түгелгән. Хәзер менә шул югалмасын өчен җыеп алырга кирәк.

ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –



«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ!

** «New Holland» -«Нью Холланд»



Фәнис Гарипов, 46 яшь.

10 ел урып-җыюда. Быел 600 гектар эшкәрткән, 26 мең центнер җыеп алган. Рекордын 2011 елда куйган – «Киев» комбайнында мең гектарга якын мәйданнан 37 мең центнер икмәк суктырып алган.

– Икмәк басуына барганда, кайчак юл бирмиләр. Шул чакта уйлыйм: йә инде, нишләвең бу?! Соңыннан үзең бит шул ипине ашыйсың!

Илдус Габдрахманов, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының игенчелек буенча урынбасары:

– Бөртеклеләрне урып-җыю төгәлләнде диярлек – 99,9 процент чәчелгән мәйданнан уңыш җыеп алынды, 4 миллион тоннадан артык икмәк булды. Соңрак өлгерә торган культураларга да кердек. Алар арасында кукуруз, шикәр чөгендере, рапс, көнбагыш, бәрәңге һәм яшелчәләр. Тулаем 2 млн гектар мәйданнан уңыш җыясы бар дип фаразлана. Хәзерге вакытка 882 мең гектар – планның 43 проценты җыелган инде. Чәчелгән мәйданнарда 1,2 мең берәмлек техника эшли.
600 мең гектар мәйданга уҗым культуралары чәчәргә планлаштырыла. Хәзерге вакытта 443,7 мең гектар чәчелгән – планның 74 проценты. Нурлат, Сарман, Әлки, Кайбыч районнары чәчүне төгәлләде инде.

Әлмир Саттаров, 25 яшь.

Комбайнчы булып дүртенче елын эшли. Быелгы сезон йомгаклары буенча уңышы – 22,5 мең центнер. Иң күп уңышы 2013 елга туры килә – 23,5 мең центнер.

– Комбайнчы уңышны югалтмыйча җыеп алырга тырыша. Дөрес тизлектә барырга, машинаны көйләргә. Чөнки ипи – җир йөзендәге иң мөһим әйбер.

PRESSA.RU

ООО «АнгарПоволжье»

Строительство бескаркасных и каркасных ангаров

Зернохранилища

Овощехранилища



Коровники

Профессиональное строительство ангаров круглый год

460021 г. Оренбург, ул. 60 Лет Октября, 16а

Тел.: 8 800 100-22-46 (звонок по РФ бесплатный)

Факс: 8 (3532) 70-66-37

www.angar-pfo.ru

e-mail: zakaz@angar-pfo.ru

Реклама

РЕСПУБЛИКА МӘГАРИФЕ: НӘТИҖӘ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫЛЫК

Традиция буенча яңа уку елы алдыннан Татарстан мәгариф һәм фән хезмәткәрләре август педсоветына җыелдылар. Бу юлы ул Лаеш районында узды. Республика Президенты тарафыннан тармак алдына куелган бурычлар арасында Татарстанда белем бирү стандартын камилләштерү дә бар: аның сыйфатын, ачыклыгын, көндәшлеккә сәләтлелеген.

Без бүген укытуның төрле юнәлешләре, мәктәпләрнең белем бирүгә әзерлеге, укучыларны бердәм дәүләт имтиханына әзерләү проблемаларын күзгатабыз.

МӘКТӘПЛӘР
Кайда яңа мәктәпләр төзелгән һәм искеләре төзекләндерелгән

ЮНӘЛЕШЛӘР
Мәктәпнең билгеле бер уку-укыту юнәлешендә эшләве ни бирә

ФИКЕРЛӘР
Укучыга нинди психологик ярдәм күрсәтелергә тиеш

PRESSA.RU

... Гомуми белем бирү мәктәпләре белән тәэмин итү Сыер абзарларын капиталь төзекләндерү Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү Балалар бакчалары төзү Яшүсмерләр клубларын капиталь ремонтлау Спорт мәйданчыклары төзү «Уңайлы мохит» программасы Социаль хезмәт күрсәтү стационар оешмаларын капиталь ремонтлау Балалар сәламәтләндерү лагерьларын капиталь төзекләндерү **Мәктәпләрне капиталь ремонтлау** Мәдәният объектларын капиталь ремонтлау ФАПлар төзү, сәламәтлек саклау объектларын капиталь ремонтлау Ветеринария хезмәте күрсәтү биналарын төзү Ветеринария берләшмәләрен һәм авыл хуҗалыгы идарәләрен капиталь төзекләндерү Участок ветеринария пунктларын төзү һәм капиталь төзекләндерү Силос-сенаж траншеяләрен төзү Яшелчә саклагычларын капиталь ремонтлау Тузган торак Социаль ипотека Күп балалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү...

ПРЕЗИДЕНТ ПРОГРАММАЛАРЫ.
НӘТИҖӘЛӘР

ЯҢА «ӘЛИФБА»ЛЫ МӘКТӘПЛӘР

2012 елдан Татарстанда мәктәпләрне капиталь төзекләндерү программасы гамәлгә ашырыла. 700гә якын белем учагына икенче сулыш өрелгән инде. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов тарафыннан расланган программа мәктәпләргә генә түгел, шунда белем алучы балаларга да яңа тормыш башларга мөмкинлек бирде.

Программаның үтәлешен тикшерү максаты белән Саба районындагы Явлаштау һәм Эзмә авылларының танымаслык булып үзгәргән мәктәпләрендә булдык. Безне яшел һәм сөт төсендәге төзелеш материаллары белән тышланган белем учаклары каршы алды.

Фото: Ната Смирнова

Автор:
Линар Закиров

ЯШЬ УКЫТУЧЫЛАРГА – ТОРАК

Авыл мәктәбендә яшь мөгаллимнәрнең, өстәвенә, ир-атларның күп булуына таң калдым. Инглиз теле укытучысы Рамил Халиков Казанда туса да, авыл җирендә үз йорты белән торырга хыялланган. Аның ике улы бар, гаиләсе белән Явлаштауга өч ел элек килеп төпләнгән. Сабада авылга яшь кадрларны җәлеп итү программасы эшли, аның буенча йорт җиткереп бирәләр, чыгымнарның 70 процентын район бюджеты күтәрә, калган 30 процентын белгечләр үзләре түли. Бу мөмкинлектән файдалану өчен, яшь укытучы авыл җирендә, ким дигәндә, берничә ел эшләргә тиеш.

Без кабинетка килеп кергәндә Рамил әфәнде бишенче классларда дәрес үткәрә иде.

– Бу минем иң көчле класс, алар белән өстәмә рәвештә дә шөгыльләнәм, – диде ул. – Бүген, җәйге каникулдан соң, исәнләшү, саубуллашу, җиләк-җимеш, мәктәпкә кагылышлы сүзләрне кабатладык.

– Сез шәһәр мәктәбендә дә эшләгәнсез бит. Авыл һәм шәһәр укучысын чагыштырсак, нинди аермалы яклары бар? – дим.

– Авылда барысы да диярлек бер-берсен белә, күп кенә балаларның әти-әниләре укытучы булып эшли, шуңа да берәр сорау килеп туса, һәркайсы белән аерым сөйләшергә мөмкин. Ә шәһәрдә гаиләләрнең төрлесе, хәтта үз баласының укуы белән кызыксынмаучылары да бар. Шәһәрдәге 25–30 балалы класста инглиз телен укыту авыррак, ә авылда укучы саны азрак, һәрберсе белән репетитор сыман аерым эшлисең, – дип сөйләде Рамил Халиков.

«ФИЗКУЛЬТУРАНЫ ТАТАРЧА АЛЫП БАРУ УҢАЙСЫЗ»

90 бала укый торган Явлаштау мәктәбен 18,5 миллион сумлык капиталь төзекләндерү тулысынча үзгәрткән. Ильич лампаларына алмашка диодлылары, совет чорындагы шыгырдавык ишекләргә заманчалары килгән. Барлык тәрәзәләр, җылыту, вентиляция системасы алыштырылган. Түбәдән дә су акмый хәзер. Элек бәдрәфләр урамда булса, хәзер балалар тышка чыгып йөрми – бөтен нәрсә бина эчендә. Хәер, соңгысы икенче бер программа буенча башкарылган.

– Мәктәп 1983 елда төзелә башлап, эшләр озакка тукталып торды. Бина җимерелә башлагач, аңа кабат тотынып, сафка бастырдылар. Капиталь төзекләндерү программасы кысаларында бинаның фасадын яз көне үк тышлап, җылыта башладылар. Бу укыту барышына берничек тә йогынты ясамады. Ремонт балаларның күз алдында барды, – дип сөйләде мәктәп директоры Зөлфәт Гыйбадуллин.

Спорт залына кердек. 2014 елда махсус программа нигезендә аны ике миллион сумга рәткә китергәннәр, шулай ук җылылыкны саклый торган лампочкалар урнаштырылган. Укытучы, балалар белән русча исәнләшеп, командаларны да русча әйтте.

– Сездә укыту татарча алып барылмыймы әллә? – дип гаҗәпләндем.

– Без татар мәктәбе булып йөрибез, аралашуыбыз да татарча. Әмма физкультурада бөтен терминнар рус телендә, аны татарча алып бару өчен бернинди кулланмалыклар юк. Физкультура дәресен татар телендә алып бару балаларга да уңайсызрак булыр иде. Без бит аларны, беренче чиратта, тормышка әзерлибез, армиядә дә бөтен терминнар, командалар рус телендә, – дип аңлатты директор.

УКУЧЫЛАР УКЫТУЧЫНЫ ЯШӘРТӘ

Математикадан бердәм дәүләт имтиханына әзерләнүче 11ләр янына да сугылдык. Класста берничә генә бала иде, барысы да – гүзәл затлар. Моның хикмәте аңлашыла: 9дан соң күп кенә укучылар училище-техникумнарга китә. Ә 10нчыда югары уку йортларына барырга ниятләгән укучылар кала.

– 11ләр шундый яшь күренә! – дим гаҗәпләндем, класска атлап кергәч.

– Без 17 яшьтә чыга идек, ә хәзер мәктәпне 19 яшьтә тәмамлыйлар, – диде директор.

26 яшьлек математика укытучысы Гөлүсә Гафиятова балаларга синус-косинусларны 19 яшьтән бирле өйрәтә, Явлаштауда икенче елын эшли. Мәктәптәге ремонтка таң калган ул, мондый дәрәҗәдә булыр, дип күз алдына китермәгән. Кабинеттагы парталарны да алыштырсалар, бигрәк әйбәт булыр иде, ди ул.

– Шушы авылда укып, шушында эшлисем килде. Укытучы булу күбрәк ошый. Укучылар янында күңелле, алар безнең белән үз фикерләрен, уйларын бүлешә. Бер елны 11нче класс укучыларын БДИга әзерләп, баллары район белән республиканың уртача күрсәткечләреннән дә югары булды.

ДҮРТ ЧИЛӘК БӘРӘҢГЕ

Укучыларның мәктәптәге тагын бер яраткан урыны – ашханә белән таныштык. Аның да күпчелек өлешен яңартканнар. Ишекләрне алыштырасы калган.

Балаларны көнгә ике тапкыр ашаталар. Иртәнгесе бушка булса (ботка, чәй һәм ипи, монысын район бюджеты күтәрә), көндезгесе – аш, икенче һәм чәй – нибары 20 сум. Былтыр бөтенләй дә 17 сум гына булган, кайбер ризыкларның кыйммәтләнүе аркасында, быел түләүне өч сумга күтәргәннәр. Балалар ашый торган ризыктан без дә авыз иттек.

Фотографыбыз: «Балаларга да шундый зур порцияләр бирәсезме?!» – дип шаккатты. Директор «әйе» ди. Күп балалы гаиләдә, кимендә, өч балигъ булмаган бала булса, аларны икенче тапкыр да бушлай сыйлыйлар. Шунысы гаҗәп: ризыкларны барыбыз да гадәтләнгән фарфор түгел, тимер савытларга салып бирәләр.

– Биш ел элек районыбыз башлыгы тәкъдиме белән Сабаның барлык мәктәпләре нержавейкага күчте. Пыяла савытлар озакка чыдамый, энә күзе кадәр кителгән җире булса да, аны инде кулланырга ярамый. Ә бу югары сыйфатлы корычтан ясалган. Дөрес, ул кыйммәт, әмма аны теләсә кайсы температурада юып була, ватылмый да, тора-бара үзен аклый, – дип аңлатты мәктәп директоры.

Шәһәр җирендә бала-чага «тегене ашамыйм, моны теләмим», – дип киреләнсә, Явлаштауда укучыларның 100 проценты да кайнар ашлар белән тәэмин ителгән.

– Итегез хәләлме? – дип сорыйм.

– Әлбәттә, бу – беренче таләп. Район буенча итне дә, ипине дә, сөтне дә бөтен мәктәпләргә берешәр генә оешма китерә. Үзебезнең бакчада яшелчә, бәрәңге үстерәбез, шуның хисабына ашау очсызрак килеп чыга, – диде Зөлфәт әфәнде.

Бер почмакта чиләккә тутырылган вак бәрәңгегә күзебез төште.

– Аш пешерүчеләр шушындый бәрәңге әрчеп интегәме? – дип сораулар яудыруымны дәвам иттем.

– Быел бәрәңге начар чыкты шул, – дип көрсенде директор. – Аны алырга, гадәттә, өлкән сыйныф укучыларын һәм укытучыларны дәрестән соң алып чыгабыз. Ике-өч сәгатьтә эш бетә. Авыл хуҗалыгы оешмасы техника белән тәэмин итә.

Әңгәмәгә аш-су остасы Гөлнур Галимҗанова да кушылды:

– Бәрәңге боламыгына дүрт чиләк бәрәңге китә. Өч кеше ярты сәгатьтә әрчеп бетерәбез, – диде ул.

Гөлнур ханым балаларга инде 23 ел тәмле ашлар пешерә. Капиталь төзекләндерүдән соң ашаханәдә зур ванналар барлыкка килде, ә элек савыт-сабаны кечкенә раковиналарда юа идек, ди.

– Элек балаларны бер генә тапкыр ашаттык. Соңгы 3-4 елда ике тапкыр әзерлибез. Районнан бердәм меню килә. Сабаның бөтен мәктәпләре шуның буенча гына пешерә, – дип сөйләде аш-су остасы.

Авыл хуҗалыгы оешмалары Корбан гаетендә, үгез яки тана суеп, итне бер балага 100 грамм исәбеннән берничә мәктәпкә бүлеп бирә. Аш булган көнне тантаналы линейка җыеп, догалар укыйлар.

– Авылыбызда совет чорында да манарасы киселмәгән мәчет бар. Һәр класста яулыклы кызларыбыз бар, алар да, малайлар да мәчеткә бик теләп йөри. Рамазан аенда балалар шунда җыелышып, динне өйрәнәләр, уйныйлар, ә кичкә, авыз ачарга һәр баланың әти-әнисе берәр ризык пешереп алып килә, – дип сөйләде Зөлфәт әфәнде.

СЫЕРЧЫК ОЯСЫ: ТЕОРИЯГӘ – 10, ПРАКТИКАГА – 1 СӘГАТЬ

Явлаштау мәктәбеннән иганәчеләрнең өзелгәне юк. «Үз мәктәбеңә ярдәм ит!» акциясе кысаларында хәлле кешеләр (күбесе шушы мәктәпне тәмамлаучылар – авт.) йорт җиһазлары, башка төрле кирәк-ярак алып бирүдә булыша.

Габдулла Кариев исемендәге татар яшь тамашачы театры директоры Мансур Ярмиев ел саен беренче класста укучыларга һәм авыррак хәлдәге гаиләләрнең балаларына тулы комплектлы сумкалар бүләк итә. Алай гына да түгел, театр коллективы белән кайтып, авыл халкына бушка спектакль дә күрсәтәләр. Сүз уңаеннан, быел Явлаштау мәктәбенә беренче класска җиде бала укырга кергән.

Зөлфәт әфәнде белән мәгариф өлкәсе турында да гәпләшеп алдык.

– Элек хезмәт дәресе «труд» дип атала иде, ә хәзер – «технология». Сыерчык оясы ясарга уйласак, аның технологик картасын әзерләүгә 10 сәгать бирелә, практикага – бер генә сәгать.

БЕЗНЕҢ «ӘЛИФБА» – СЕЗНЕҢ «ӘЛИФБА»

Эзмә мәктәбендә бала саны күбрәк – 147, шуңа күрә төзекләндерүгә акчаны да күбрәк бүлеп биргәннәр – 25 миллион сум (бер яртысы – республика, икенчесе – район бюджетыннан). Бу мәктәптә дә бөтен нәрсәне рәткә китергәннәр, яңа җиһазлар алганнар, ашханә дә кырт итеп тора. Җитәкчелек тарафыннан барлык шартлар тудырылган, балаларга исә әйбәт кенә укырга кала.

Айнур Шәймәрданов белгечлеге буенча математика укытучысы, өч ел элек директор вазыйфасына керешкән. Ул безне сигезенче класс укучыларының татар теле һәм әдәбияты дәресенә алып керде. Кабинетны парталар һәм проектор белән җиһазларга иганәчеләр ярдәм иткән.

Өстәлләрдә өч төрле смайлик ята: яшел, сары һәм кызыл төстә. Укытучы Гөлнара Һадиева сөйләвенчә, дәрес азагында укучылар дәрестә ничек эшләүләренә карап, үзләренә

Фото: Ната Смирнова

Гомуми белем бирү оешмаларын капиталь төзекләндерү буенча республика программасы

	2012	2013	2014	2015	2016
Гомуми белем бирү оешмасы:	165	160	151	119	80
Махсус (коррекцион) мәктәп:	5	7	8	7	15
Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы:	–	–	–	10	53
Гомуми суммасы:	2 427,5 млн сум	2 450,0 млн сум	2 550,0 млн сум	2 579,6 млн сум	2 520,0 млн сум

* ТР гомуми белем бирү учреждениеләрен капиталь төзекләндерү программасына 1981 елга кадәр төзелгән мәктәпләр кертелде. 2015 елдан программага 1983 елда һәм аннан да иртәрәк төзелгән мәктәпкәчә белем бирү оешмалары кертелде.

бәя бирә: яшел төс – бик яхшы, сарысы – яхшы, кызыл – канәгатьләндерерлек, дигәнне белдерә.

– Укучылар күтәргән билгене генә куябыз, дип уйламагыз. Аларның һәм үземнең дә билгене кушып, уртак нәтиҗәгә киләбез. Балалар үзләренә төгәл бәя бирергә өйрәнделәр инде, каршылыклар туганы юк, – диде укытучы.

Башлангыч класс укучылары янына керсәк, нәниләр караңгыда утыра булып чыкты. Никлеген генә ачыклый алмадык. Партада беренче сентябрьдән калган чәчәкләр һаман да балкып утыра, суын алыштырып торалар.

– Бу – 1Б классы, 1А классында да мондагы кебек 12 бала, – диде мәктәп директоры.

Ләйсән Галимуллина нәниләргә «Әлифба» серләрен 24 ел ача. Без укыган – малай белән кыз сурәте төшерелгән дәреслек сафтан төшеп калган инде, аның урынына яңа «Әлифба» чыгарганнар.

– Хәзерге балалар бик хәрәкәтчән, бакчадан күпне өйрәнеп киләләр, беренче класска килүчеләрнең кайберләре хәтта укый да белә, – диде укытучы.

Илфат Шакиров, Саба районы мәгариф идарәсе башлыгы:

– 2012–2016 елларда 8 мәктәп, 3 балалар бакчасы төзекләндерелде. Билгеле булганча, 30 елдан өлкәнрәк мәктәпләрне тәртипкә китереп бетергәч, балалар бакчаларына күчәләр. Белем учакларын ремонтлауга район бюджетыннан да акча күп бүлеп бирелде.

Бездә балалар дәресләр беткәч кайтып китми, дүрткә кадәр түгәрәкләрдә шөгыльләнәләр, бу мәҗбүри куелган. Шуңа да укучыларны ике тапкыр ашатабыз.

Сабада бала саны кими торган мәктәпләр дә бар. Укыту сыйфаты яхшырсын өчен, районда башлангыч мәктәпне өчне генә калдырдык. Районлагы иң кечкенә белем учагы Завод-Ныртыда, анда 64 укучы белем ала. Мәктәп автобуслары йөреп тора. Авыллар бер-берсенә якын урнашкан, аралары 2–3 километр гына.

Фәрхәт Нәбиуллин, Сабадагы ПМК-159 төзелеш оешмасы директоры:

– Укучылар һәм укытучылар алдында оят булмасын, кем эшләде икән, дип сорасыннар өчен, мәктәпләрне, балалар бакчаларын төзекләндергәндә төзелеш материалларының сыйфатлысын алырга тышырабыз. Әйтик, мәктәпләрне тышлаганда яшел һәм сөт төсендәге материалларны кулландык. Тыныч төсләргә өстенлек бирәбез. Әмма иң элек моны мәктәп директорына, аннары мәгариф идарәсендә, соңыннан башкарма комитетка күрсәтергә кирәк.

Коллективыбызда 120гә якын кеше хезмәт куя. Бер бригада түбә яба, икенчесе су кертә, өченчесе мрамор җәя һ.б. Зур эшләрне, гадәттә, бишенче августка тәмамлыйбыз. Тынычланып, бераз хәл алабыз да мәктәпне августның 25енә кадәр өлгертәбез.

PRESSA.RU

ТИРӘНТЕН ӨЙРӘНҮ

Быел республикада Белем көнен 400 меңләп бала билгеләп үтте. Шулардан 170 меңе «фән ташын кимерергә» лицейларга, гимназияләргә һәм кайбер предметларны тирәнтен өйрәтә торган мәктәпләргә юл тотты. Әмма бу үзен аклыймы соң? Без юнәлешле мәктәптә укуның, баланың язмышына һәм киләчәктә һөнәр сайлавына ничаклы йогынты ясарга сәләтле булуын ачыкларга уйладык. Үзебезнең сорауга җавапны нәкъ менә урыннарда эзләргә булдык.

IT-ЛИЦЕЙ:



+ ШАХМАТ ҺӘМ ҺӘРКЕМГӘ ӨЧӘР ТОМЕР

КФУның IT-лицей директоры кабинетында күзгә иң беренче чалынган нәрсә – шахмат уены.

– Үзем дә яратам, безнең балалар да уйный. Фикерләүне үстерә! – дип мин сораганчы аңлатып өлгерә Тимербулат Сәмерханов.

IT-кушымчасына карамастан, лицейда өч профильле юнәлеш бар: информатика, физика-математика һәм химия-биология.

– Быел безнең беренче чыгарылыш булды: 54 кешедән икесе генә югары уку йортларына гуманитар юнәлешкә укырга керде, бүтәннәре барысы да – булачак программистлар, физиклар, химиклар һәм биологлар, – дип горурланып таныштыра безне үзенең статистикасы белән Тимербулат Рәшит улы. – Юнәлешле уку йорты гади мәктәптән аерылып тора ул! Барыннан да бигрәк профильле предметларга бүленгән сәгатьләр саны белән.

Мәсәлән, гуманитар сыйныфларда шул ук информатика нибары 1 генә сәгать яки бөтенләй юк, ә математика – 4 сәгать. Лицейның информатика сыйныфында исә – 7 һәм 10 сәгать. Атнасына! Ике елга аерма 800 сәгатькә кадәр җитәргә мөмкин.

– Укучылар максатчан рәвештә профильле сыйныфларны сайлый – бу БДИ га да, киләчәк тормышка да әзерлек булып тора, – ди Сәмерханов.

Мәктәпне тәмамлаганда нәтиҗәләр нинди булырга тиешлеген биредә бик яхшы күзаллыйлар – чыгарылыш сыйныфы укучысының портреты бу урынга хас математик төгәллек белән сурәтләнгән. Ватанпәрвәрлек һәм башка «дөрес» сыйфатлардан тыш, анда профессиональ критерийлар да бар. Әйтик, лицейны тәмамлаучы инглизчә иркен сөйләшергә (кирәкле фәнни әдәбият белән танышып барыр өчен), инженер яки программист күнекмәләренә ия булырга, үзенең интеллектына гына түгел, кулларына да таянып иҗат итә белергә – мәсәлән, роботны җыярга, аннары аңа it-гомер өрергә тиеш.

Без иң заманча ноутбуклар һәм планшетлар белән җиһазландырылган Samsung кабинетына керәбез. Тимербулат Рәшит улы горурланып мобиль кушымтаны күрсәтә. Бу – бәләкәйләр өчен «санагыч». «9га 7не кушкач ничә була?» – кебек гади сорауларга җавап бирергә кирәк, тик «уйнаучының» өч кенә «гомере» бар! Мин аптырап калдым. Әлеге кушымта исә лицейчыларның чыгарылыш биреме икән. Менә шулай.

– Бүгенгә кадәр татар теленнән дөрес онлайн-тәрҗемәче юк. Безнең укучылар аны да ясарга тырыша. Күргәнегезчә, аларның тәмәке эзләп, бушка селкенеп йөрергә вакыты юк, бөтенләй башка проблемаларны хәл итәселәре бар. Күптән түгел минем яныма бер укучы килде: «Тимербулат Рәшитович, мин сезгә сайт ясадым», – ди. Җиденче сыйныфта гына укый үзе! Минемчә, бу шаккатарлык хәл.

IT-лицей – балалар укый торган гына түгел, шунда яши дә торган интернат. Сыйныфлар түгел – төркемнәр – 12шәр кешедән формалаша. Сайлап алу өч этаптан тора. Нәтиҗәдә бирегә мәктәп «йолдызлары», олимпиада призерлары кабул ителә. Һәм шундук «кырыс чынбарлык» белән очраша. Лицейны беренче тәмамлаучыларның берсе Тимур Алабугадагы гади мәктәптән килеп укый башлауга «өчле»гә тәгәрәвен исенә төшерә.

– Төркемнәр кечкенә, димәк, синнән күбрәк таләп тә итәләр, ешрак сорыйлар да. Әйе, биредә укуы авыррак, әмма бу тырышырга сәбәп булып тора! Күнектем, билгеләр дә яхшырды. Лицейны тәмамлагач, КФУның Мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати системалар югары мәктәбенә укырга кердем. Укуның беренче көннәре шуны күрсәтте: түгә семестр материалы информатиканы яхшы белгәннәргә җиңел биреләчәк. Ә мин, лицейда укыганга, информатиканы шәп беләм.

Икенче ел рәттән лицей төп дәүләт имтиханнары (ОГЭ) нәтиҗәләре буенча Казан мәктәпләре рейтингында беренче урында тора. БДИ буенча беренче унлыкка керә – әле 2012 елда гына оешуын исәпкә алганда, бу нәтиҗәләр бер дә начар түгел. Сүз уңаеннан, бирегә кызларны да алалар.

– Без кызларны укырга алмыйбыз, дигән сүз каян килеп чыккандыр ул, белмим. Алабыз! – ди директор.

1 сентябрьдә IT-лицейга 25 кыз кабул ителгән.

ИНГЛИЗ МӘКТӘБЕ:

+ ТРАДИЦИЯЛӘР ҺӘМ... КЫТАЙ ТЕЛЕ

– Хәзерге заманда чит тел белмичә көндәшлеккә сәләтле булырга мөмкинме? – дип сорый миннән Надия Шевелева. Ул директор булып эшләгән 18 нче мәктәп ерак 1959 елда инглиз телен тирәнтен өйрәтә торган республикада беренче мәктәп буларак ачылган. Аны укучылар да, әти-әниләр дә, тәмамлап чыгучылар да үзара «традицияле мәктәп», дип йөртә. Шулардан берсе – Мария.

– Мин бу мәктәпне тәмамладым, хәзер исә биредә улым укый, – дип сөйли ул. – Күңелгә якын диварлар, яхшы коллектив – болар барысы да мөһим. 18 нче мәктәпне тәмамлаучыларның күбесе балаларын да биредә укыта. Миңа балаларның максатчанлыгы ошый – барысы да нәрсә белән булса да мавыга. Минемчә, бу нәкъ менә мәктәп йогынтысыдыр.

Мариянең мәктәптә алган белемнәренең кирәге чыккан. Америкада стажировка үткәндә биредә алган белемнең югары сыйфатлы булуы тагын бер тапкыр дәлилләнгән. «Мин университетта рус телендә сөйләшүче бердәнбер шәкерт идем, әмма минем мәктәптә өйрәнгән инглизчәм Америка студентлары сафына бер каршылыксыз кушылырга һәм хәтта тьютор булып эшләргә дә мөмкинлек бирде», – ди Мария.

18 нче мәктәптә инглиз теле сәгатьләре «гади» уку йортларындагыдан өч тапкырга артыграк – алты. Моңа әле тагын чит телдә үткәрелә торган конференцияләр, инглиз-америкаң җырлары фестивале, ораторлар конкурсы өстәлә... Мәктәпне тәмамлаучылар инглизчә иркен аралаша. Әле ул гына да түгел, биредә кытай телен дә өйрәнәләр. Әлегә үзләре теләгәннәр генә, әмма инде алар, хәзер үк бөтенроссия олимпиадаларында, компетентлы жюрины үзләренең искиткеч дөрес сөйләме белән таң калдырып, призлы урыннар ала.

– Сезнең мәктәпне тәмамлаучыларның ничә проценты профильле югары уку йортларына керә? – дип кызыксынам Надия Мәсгуть кызыннан.

– Чит тел белү – әле мәҗбүри һөнәр дигән сүз түгел. Ул – корал. Теләсә кем – атаклы галим, нәтиҗәле җитәкче, искиткеч эшче булырга һәм шул ук вакытта чит тел белергә дә мөмкин.

Бүген төрле интеллектуаль үсеш үзәкләренең, баланы бер ел эчендә чит телгә өйрәтеп була, дип мактануларын еш ишетергә була. «Бу ялганмы, әллә чынмы?» – дип сорыйм директордан.

– Моны сез аларның үзләреннән сорагыз инде. Бер генә нәрсә бәхәссез – алар күп акча эшли, ә бездә уку түләүсез. Без барлык предметлар буенча яхшы классик белем дә бирәбез бит әле. Безне гуманитар мәктәп дип атасалар да, математиканың бер генә сәгатен дә киметмибез. Чөнки яхшы аңлыйбыз – баланың киләчәктә теләсә нинди белгечлекне сайлап алу мөмкинлегенә булырга тиеш.

РЕСПУБЛИКА МӘГАРИФ ӨЛКӘСЕ: НӘТИҖӘ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫЛЫК

ФИЗИКА-МАТЕМАТИКА ЛИЦЕЕ:

+ ИНТЕЛЛЕКТ ҺӘМ ГОМУМИ КУЛЬТУРА

Мәктәпләрдәге күнегелгән кыңгырау урынына Казанның 131 нче физика-математика лицеенда классика уйный.

– Бу төгәл фәннәргә сәләткә ничек тә булса йогынты ясыймы? – дип сорыйм директор Әлфия Хәбибуллинадан.

– Бу интеллектка һәм гомуми культурага йогынты ясый. Аларның булуы –безнең мәҗбүри таләп.

Лицейның мактанырлыгы бар: типлаштырылмаган мәктәпләрнең БДИ нәтиҗәләре буенча рейтингында ул беренче урында тора. Аны тәмамлаучыларның 90 проценты шул ук профиль буенча вузларда укуын дәвам итә. Әлбәттә, араларында гуманитар белгечлек сайлаучылар да бар. Сүз уңаеннан, шундыйлардан – танылган опера җырчысы Эдуард Трескин, балалар язучысы Борис Вайнер, күренекле драматург Равил Бохараев һәм хәтта хәзерге ТР эчке эшләр министры Артем Хохорин.

– Минемчә, физика-математика гыйлеме – иң әүвәл яхшы фикерләү нигезе, – ди Әлфия Блигвардовна. – Мәгълүмат белән эшли белү: эзләү, системага салу, иң мөһимен аерып алу. Хәтта филология факультетына кергән укучыларыбыз да, без биргән белем үзләренә бик булыша, дип ышандыра.

Атнасына биш сәгать физика, тугыз сәгать математика, тагын профильле түгәрәкләр – махсуслашкан мәктәпне еш кына балаларга артык зур нагрузка бирүдә гаепләүләре бер дә гаҗәп түгел. 131 нче лицейга отличник һәм ударник булып килгәннәр барысы да диярлек өчлегә укый башлый.

– Бу котылгысыз хәл, – ди директор. – Бездә конкурс – бер урынга биш кеше. Үз мәктәпләрендә бу балалар яхшыларның да яхшысы саналган. Безгә киләләр, ә биредә бөтенесе дә шундый! Таләпләр югары, һәм бик күп нәрсә баланың үз характерына бәйле. Әгәр, тешләрен кысып, хәленнән килгәнне дәлилли алса, үз дигәненә ирешәчәк. Ә без аңа ярдәм итәргә һәрвакыт әзер. Билгеле, кайберәүләрнең хәленнән килми. Алар йә китә, йә яраклаша – кайчакта күчерәләр, кайвакыт хәйләлиләр... Ни өчендер җәмгыятьтә, өчле капчыклары тормышта отличниклардан уңышлырак, дигән фикер яши. Мин моның белән каттый килешмим! Чөнки өчлегә укучы ул – гомере буена өчле капчыгы. Хәтта зур җитәкчегә әйләнсә дә, өчлелек кенә җитәкче булачак.

– Сезнең укучыларыгызның әти-әниләренә репетиторларны еш ялларга туры киләме?

– Минемчә, репетиторлар – балаларының белеме өчен әти-әниләрнең үзләре өстеннән җаваплылыкны төшерергә маташуы ул. Чөнки күпчелек очракта репетиторлар бала өчен өй эшен эшләгәнгә акча ала. Балагыз программаны тарта алмыймы? Янына утырып, шөгыльләнергә кирәкләгән аңлатыгыз. Бары тик бер очракта гына репетитор яллауны аклап була: әгәр бала озак авырса, артта калса. Дәрестә укытучыны игътибар белән тыңласа, өй эшләрен пөхтәләп эшләп барса, шул җитә.

Лицейның горурлыгы булган Әмир репетиторлар белән шөгыльләнмәгән. БДИны уңышлы бирү һәм югары уку йортына керү өчен, мәктәп программасы җитә, дип раслый ул. Үзе КФУның химия факультетын сайлаган. Әлеге предметка мәхәббәтне ул директордан «йоктырган». Аның түгәрәгенә йөргән, һәртөрле олимпиадаларда катнашкан. Мәктәптәге соңгы «трофее» – химия буенча халыкара олимпиаданың бронза медале – бүген дә аның социаль челтәрдәге сәхифәсен бизәп тора.

– 131 нче мәктәпне анда әтием һәм абыем укыганга сайладым, башкалардан аерылып торасым да килде. Мин анда үземнең сәләтләремне үстерә алдым, дуслар да таптым. Безнең мәктәпнең атмосферасы искиткеч – кайчандыр Пушкин үзе данлаган чын лицей туганлыгы биредә.

ЭКОЛОГИЯ МӘКТӘБЕ:

+ ДЕНДРОБАКЧА ҺӘМ ЭКОЙОРТ

Химия һәм биологияне тирәнтен өйрәтә торган 86 нчы мәктәпкә барганда ук гаҗәеп үсемлекләр таң калдыра. Мәктәп яны территориясендәге дендробакчаны балалар утырткан – һөнәр сайлау табигатьне кайгыртудан башлана.

– Быел «Планетаның үпкәсен саклыйк» дигән бик кызыклы проектны тәгәлләп киләбез, – дип сөйли миңа директор Гөлназ Галиева. – Балалар макулатура җыялар, аннары шул рәвешле ничә агачны саклап калганнарын исәплиләр. Һәр төркемнең үз тотемы бар. Кемдер наратларны коткара, кемдер – каеннарны… Башлангыч мәктәптә уку чорында – дүрт ел буена коткаралар. Быел бу агачларның аллеясын утыртачакбыз.

Химия һәм биология буенча көчәйтелгән программа бишенче сыйныфтан башлана. Предметларны тирәнтен өйрәтә торган башка мәктәпләрдәге кебек үк, биредә балалар киңәйтелгән укыту-тематик план буенча укый: аерма дәресләрнең эчтәлегендә генә түгел, сәгатьләр санында да. Тагын әле түгәрәкләр, өстәмә консультацияләр, олимпиадаларга әзерлек өстәлә. Бу мәктәп укучылары тикшеренү эшен инде башлангыч сыйныфтан ук башлый.

– Без Казан милли-тикшеренү технология университеты белән бик тыгыз хезмәттәшлек итәбез, – дип сөйли Гөлназ Ринатовна. – «Школа всезнайки» проекты кысаларында икенче сыйныф укучыларын җәлеп итәбез. Кызыклы сигез юнәлеш буенча эшлибез. Мәсәлән, экология, экойортлар төзү…

Директор әйтүенчә, юнәлешле мәктәпнең төп миссиясе – баланы конкрет предмет белән кызыксындыру, аны үзләштерү мөмкинлеге бирү, профильле югары уку йортына керүгә әзерләү. Сүз уңаеннан, бу мәктәпнең махсуслаштырылган сыйныфларын тәмамлаучылар арасында профильле белгечлекләр сайлаучылар саны 70 процентка җитә. Бу гомуми статистикада конкрет мисал – Валерия. Ул хәзер КМТТУ магистратурасында биотехнолог һөнәрен үзләштерә.

– Предметны тирәнтен өйрәтә торган мәктәп – үзенең киләчәген әлеге юнәлеш белән бәйләргә теләгәннәр өчен идеаль вариант, – ди ул. – Профильле вузга укырга керер өчен БДИ бирергә махсус уку программасы кысаларында да бик шәп әзерләнеп була. Һәм бернинди репетиторлар да кирәкми.

Лера әле мәктәптә үк биология белән «җенләнүен» искә төшерә. Иң хәтердә калган мизгеле – үзенең Татарстан шартларына җавап биргән экойорт проектын төзүе. Эшләрне яклау «Химградта» үткән.

PRESSA.RU

ИМТИХАН БИРӘ АЛМАСАҢ, УРАМ СЕБЕРЕРСЕҢ!

Ольга Шмелёва, гаилә психологы, ике бала анасы, БДИ бирер алдыннан балаларны тынычландыру турында.

– Хәзер, БДИ хакында төрле уйдырмалар йөргәнгә, бик күпләр аннан курка. Ә курыкканга куш, йодрыгы белән биш булып күренә! Шунлыктан балалар өчен дә, әти-әниләр өчен дә психологик әзерлек бик мөһим. Психологлар курыккан нәрсә турында мөмкин кадәр күбрәк белергә киңәш бирә. Интернеттан имтиханның видеосын карагыз, инде БДИ биргәннәр белән сөйләшегез, укытучылардан сорап, чынны ялганнан аерырга өйрәнегез. Еш кына укытучылар, укучыларны куркытсалар да, әти-әниләргә чынбарлыктагы вариантның серен чишә… Мин үзем дә әни, һәм кызым имтихан (ГИА) биргәндә шактый нәрсәгә төшендем.

Әйе, имтихан ул – һәрвакыт стресс. Һәм аннан куркалар. Бу – норма. Ә менә стресска бирешмәскә өйрәнү инде – икенче мәсьәлә. Барысы да бик гади – уңыш әзерләнгәннәрне ярата. Шунлыктан алдан ук – 2 ел алдан әзерләнә башлыйбыз. Кирәк булган предметлардан репетитор табу зарурлыгын бүген сәламәт акыллы һәр әни белә. Әмма кайвакыт әнигә дә ярдәм кирәк була – күп кенә аналар имтиханны үзләре биргәндәй борчыла. Һәм алар үзләрен мондый фикерләр белән җәфалый: «Мин начар әни, чөнки минем балам – өчле (икеле) капчыгы». Иң әүвәл шуны аңларга кирәк: әгәр балагыз өчен мөмкин булганның барысын да эшлисез икән, димәк, сез яхшы ана. Баланы исә икелеләре белән дә, өчлеләре белән дә, бишлеләре белән дә бер үк төрле яратырга кирәк.

Әниләр турында аңлаштык. Хәзер балалар хакында сөйләшик. Әлбәттә, стресска бик тиз бирешүчән балалар бар. Нәкъ менә шундыйларда имтихан вакытында паника башланырга мөмкин. Аларны алдан ук паниканы җиңәргә өйрәтү зарур. Берничә гади ысул бар:

1. Паника вакытында үзеңә «Тукта» диярргә кирәк.
2. Берничә тапкыр әкрен генә тирән сулыш алырга, сулышны чыгарырга.
3. Бер стакан су эчәргә.
4. Килеп туган хәлгә читтән, үзеңне видеокамера итеп тоеп карарга.
5. Абруйлы кешене искә төшереп, сезнең урында ул нишләр иде, дип уйларга.

Яки бераз гына онытылырга һәм куркуыгызны күзәтергә. Кайда ул? Нинди төстә? Нинди зурлыкта? Нәрсәгә охшаган? Ә аны үзгәртеп буламы? Үз-үзеңне шулай күзәтү имтиханда стресстан котылырга булышыр һәм тынычландырыр. Әмма аны баш-

Картина И.Сидорова «Дворник»

ка стресслы хәлләр вакытында да берничә тапкыр сынап карау яхшырак.

Ата-аналарның да, укытучыларның да исләренә төшерәсе килә: чыгарылыш сыйныфы укучыларын куркытырга ярамый! Тормыш күрсәткәнчә, «Имтихан бирә алмасаң, урам себерүче булачаксың» мотивациясе яхшы эшли! «Имтиханны яхшы бирсәң – уңышлы һәм бай буласың!» мотивациясе дә эшли! Шунлыктан беренче мотивацияне сирәк очракта гына кулланы сорала. Үз балаларыгызның «кыйммәтләре» телендә сөйләү яхшырак! Мәсәлән, күп сәяхәт итү һәм төрле илләрдә эшләү турында хыялланган кызга болай аңлату зарур: югары уку йортына «туризм» белгечлегенә керү аны хыялындагы һөнәргә якынайтачак.

Балага үз ихтыярыңны көчләп тагарга ярамавы һәркемгә мәгълүм. Әмма мондый хәлләр дә очрый. Мәсәлән, үсмер табиб булырга хыяллана, әмма ул хәрбиләр династиясеннән һәм бөтен гаилә аның бу һөнәрне сайлавына каршы! Яисә 11 сыйныф укучысы нинди һөнәр сайларга белми, һәм аның өчен барысын да әти-әнисе хәл итә. Ике очракта да котылгысыз конфликтка, үзара гаепләүләргә әзер тору сорала, иртәме-соңмы шулай була да.

Болай килеп чыкмасын өчен, мәктәпнең соңгы елы башында ук һөнәрне сайлап куярга кирәк. Үз тармагыңны, үз һөнәреңне табарга ярдәм итә торган махсус тренинглар, тестлар бар. Шуларның берничәсен генә атыйм: «Кеше – Кеше», «Кеше – Табигать», «Кеше – Техника», «Кеше – Образ» һ.б.

Һөнәр сайлауга юнәлтелгән тренинглар һәм тестлар кешенең үзгәртеп булмый торган психотибын да исәпкә ала. Тумыштан рәссам булган кеше тикшерүче була алмый.

Чыгарылыш сыйныфы укучылары һәм аларның әти-әниләре өчен иң куркыныч сорау мондый: «Әгәр икеле булса?», «Әгәр белешмә белән генә тәмамласаң?» Белешмәдән соң тормыш бармы соң?

Әлбәттә инде бар! Һәм бу Тормышның үзе. Чөнки безне үтермәгән һәрнәрсә безне көчлерәк итә! Вазгыятьне үзгәртә алмыйсың икән, аңа булган мөнәсәбәтеңне үзгәрт! Фәндәге, бизнестагы, дөнья практикасындагы мәктәптә бик начар укыган бөтен даһиларны искә төшерегез! Кичерегез мине, тик алар чыннан да күп. Еш кына өчлегә укыганнар тормышта отличникларга караганда күбрәк нәрсәгә ирешә! Алар «уңышсызлыкларга» яраклашырга өйрәнгән. Ә инде гел җиңүгә генә күнеккән отличниклар җиңелүне шәхси драма сыйфатында кабул итә.

Чынлыкта исә мәктәптән аттестат урынына белешмә белән чыгучылар бик аз. Әмма бик күп кеше шуннан курка! Мондый куркудан котылу өчен, аны күз алдына китерү зарур. Шулай туры килсә, нишләячәксез? Балагыз эшкә урнашачакмы? Колледжда укыячакмы? Яхшыга өметлән, тик начарга әзерлән дигән шигарь белән яшәү алда билгесезлек торганда бик булыша.

БДИ – кеше тормышындагы бик әһәмиятле моментларның берсе. Киләчәктә аласы һөнәр дә, киләчәк тормыш та аның нәтиҗәләренә бәйле. Шунлыктан бар яктан әзерләнергә кирәк. Матди яктан да, психологик яктан да. Әмма бу мөһим елда балаларга иң кирәге – әти-әни ярдәме һәм мәхәббәте. Һәм бернинди куркыту да булмаска тиеш – сез бер гаилә.

PRESSA.RU

«ИННОКАМ»: КИЛӘЧӘК КОНТУРЛАРЫ

«Иннокам»ның РФ Хөкүмәте раслаган концепциясе һәм үсешенең юл картасы шуны дәлилли: Татарстанда төбәкне үстерүнең Россиядәге беренче моделе сынала. Аның каркасы – транспорт-логистика, энергия-чимал һәм социаль инфраструктуралар, ә үзәге – дәүләт-хосусый партнерлык принципларындагы сәнәгать мегапроектлары.

Автор:
Владимир Матылицкий

Инде 2020 елга ук кластердагы сәнәгать җитештерүе бер ярым тапкырга, югары технологияле эш урыннары саны да шулкадәргә үк артыр, дип көтелә. Инновацияләр үсеше 40 процент чамасы булачак. Социаль бонуслар сыйфатында – федераль бюджеткa бүлеп бирелгән 150–200 миллиард сум һәм атмосфераны зыянлы матдәләр белән пычратуның 20 процентка кимүе.

ЮЛЛАР ҺӘМ КЕШЕЛӘР

Федераль финанслау параметрлары әле ачыкланып бетмәсә дә, М-7 трассасының Казан–Чаллы участогында дистәләрчә техника берәмлеге туфрак өю белән шөгыльләнә инде. Реконструкция 2019 елда юлны беренче категориягә күчерү белән тәгәлләнәчәк – газон һәм отбойник белән бүленгән юнәлешләрнең һәркайсында ике полоса булачак, бу юлны югары тизлеклегә һәм куркынычсызракка әйләндерәчәк. Кластерда йөкләр ташу яңалыгы – аларны алынмалы универсаль контейнерларда йөк машинасы шассиеннан судно, самолет яки тимер юл платформасына эстафета рәвешендә күчерү булачак, бу йөкләр агымының интенсивлыгын берничә тапкырга арттырачак.

ТР Президенты Түбән Каманы, «Иннокам»ның үсеш ноктасы, дип очраклы гына атамагандыр. Биредә «Түбән Кама Нефтехим», ТАНЕКО, «ТАИФ-НК» нефтьне тирәнтен эшкәртү комплексы, «Татнефть»нең шиннар комплексы һәм полимерлар эшкәртү буенча Россиядә иң зур сәнәгать мәйданчыгы – «Кама Аланы» индустриаль паркы урнашкан. Ә инде «Алабуга» МИЗның нефть химиясе проектлары өчен Түбән Кама районында «Алабуга-2» индустриаль паркын төзү планлаштырыла.

«Этилен-600» проекты исә кластер таҗындагы энҗе бөртегенә әйләнәчәк: «Түбән Кама Нефтехим» ГАЖ куәте елына 1,2 миллион тонна этилен булган олефин комплексын төзүне планлаштыра. Ул 9 миллиард долларга төшәчәк, әмма ТКНХның кереме дә 2025 елга – 3,4 тапкырга, ә саф табышы 10,2 тапкырга артачак. Өстәмә рәвештә биш меңгә якын эш урыны булдырылачак, ә бар дәрәҗәдәге бюджетларга салымнар 5,6 тапкыр үсәчәк.

– «Түбән Кама Нефтехим»ның киләчәктәге үсеше транспорт-логистика инфраструктурасын үстермичә мөмкин түгел, – ди «Түбән Кама Нефтехим» җитәкчесе Азат Бикмурзин. – Елына 3,5 миллион тонна чимал эшкәртүгә исәпләнгән ЭП-1200 олефин комплексын төзү шулкадәр үк күләмдәге продукцияне читкә чыгаруны да күздә тота. Ә транспорт инфрастуктурасының тутырылу дәрәҗәсе инде болай да үз чигенә якынлашкан. Логистика Кама кластеры предприятиеләренең тыгызрак элемтәсе өчен дә кирәк. Безнең өчен чимал кертү мәсьәләсе дә мөһим. «Ямал – Идел

буе» ШФЛУ-үткәргечен төзү идеясе Татарстан, Башкортостан, Самара өлкәсе предприятиеләренең үсеш перспективаларын да исәпкә ала – аларга елына 9 миллион тонна ШФЛУ таләп ителәчәк. Шулкадәр күләмне бер юнәлештә тимер юл белән күчерүне күз алдыгызга китереп карагыз әле! Торбаүткәргеч буенча куркынычсызрак та, арзанрак та булуы бәхәссез, чимал составы да тотрыклы булачак. «Иннокам» концепциясендә бу күрсәтелгән. Проектлар сәнәгать округлары предприятиеләре үсеше, чимал һәм әзер продукция логистикасы белән бәйле.

Нефтехимиклар әле Соколка авылы янында Кама аша күпер салып, юл төзергә дә тәкъдим иткән, ул 2017–2018 елларда башланырга да мөмкин. Әлеге юл Түбән Камадан Казанга кадәр араны 100 километрга диярлек кыскартачак, транспорт чыгымнарын һәм атмосферага зыянлы матдәләр чыгаруны киметәчәк, ГЭС плотинасын, Чаллы һәм Түбән Каманы транзит йөк машиналарыннан бушатачак, кафе, кунакханәләр, логистика үзәкләре төзү мөмкинлеге бирәчәк.

Кама кластеры шәһәрләренең киләчәге тагын да кызыклырак. Бераз вакыттан соң биредә Казан – Екатеринбург югары тизлекле тимер юлы үтәчәк, ә Түбән Кама, Алабуга, Менделеевск һәм Чаллыны югары тизлекле трамвай яки электр поезды бердәм системасы үзара бәйләячәк.

Сүз уңаенда әйткәндә, XVII гасырда Вятка (Нократ) крестьяннары нигез салган Соколка кайчандыр зур пристань булган. Халкы 7 меңгә кадәр җиткән, аларның яртысы сал агызу белән шөгыльләнгән. Бүген ул – транспорт тупигы, Кама аръягына кичектергесез очракларда катер белән, кышын исә боз өстеннән генә барып җитеп була. Күпер салынса, күп нәрсә үзгәрәчәк.

Кама кластеры шәһәрләренең киләчәге тагын да кызыклырак. Бераз вакыттан соң биредә Казан – Екатеринбург югары тизлекле тимер юлы үтәчәк, ә Түбән Кама, Алабуга, Менделеевск һәм Чаллыны югары тизлекле трамвай яки электр поезды бердәм системасы үзара бәйләячәк. Рельслар һәм шпаллар күп кирәк булачак. Электр энергиясе дә. Шунлыктан Түбән Кама ГЭСында су би-

Фото: Ната Смирнова

PRESSA.RU



Республика, «ТАИФ» Компанияләр төркеме һәм җирле бюджет акчаларына шәһәр паркын төзекләндерү эше төгәлләнеп килә. Шәһәр юлларын ремонтлауны республика, ТАИФ һәм «Татнефть» финанслый. Сулыкларны саклау елы кысаларында шәһәр яр буйлары күз алдында үзгәрә, ярлар ныгытыла, төзекләндерелә.

еклеген арттыру мәсьәләсе карала, Зәй ГРЭСын реконструкцияләү һәм Түбән Кама ТЭЦында өстәмә куәтләр булдыру планлаштырыла. Яңа подстанцияләр төзелә.

Инде хәзер үк яңа бинасы белән күзне иркәли торган «Бигеш» халыкара аэропортын реконструкцияләү 2017 елда төгәлләнәчәк, әмма инде хәзер, илдә авиакүчерешләр кимегән чорда да, аэропорт төп юнәлешләрдә «үсә».

«Иннокам»да 2020 елга фаразлана торган 4 миллиард кубометр күләмендәге газ кытлыгы Можга – Алабуга газүткәргеченә 70 километрлы системаара тоташтыргыч төзеп һәм Миңлебай – Ижевск газүткәргеченнән Түбән Кама узелына күчеп хәл ителәчәк. ТАНЕКОга өстәмә 7 миллион тонна нефть өчен дә торбаүткәргеч төзү зарур.

Биклән – Круглое Поле – Әгерже участогында икенче юл һәм Круглое Поле станциясендә өстәмә сортировкалау юлларын төзү Кама арьягындагы йөк һәм пассажир поездлары йөрешен тизләтәчәк. Түбән Кама сәнәгать төененә Биклән, Соболеково, Предкомбинатская һәм Тунгуча станцияләренең яңа инфраструктурасы кирәк. Хәзергесе проекттагы 9,5 миллион тонна урынына елына 16 миллион тонна йөк үткәрә һәм инде өлгерә алмый.

Түбән Кама шәһәре эчендәге юлларны да онытмыйлар: концепция кысаларында беренче чиратта Собо-

лековотрактын һәм Көньяк трассаны реконструкцияләү тәкъдим ителгән, 1 нче Промзона буендагы аларны тоташтыра торган юл яңартыла инде.

ИННОВАЦИЯЛӘР – «ҮЗ АКЧАЛАРЫНА»

Түбән Кама районы башкарма комитеты рәисенең икътисадый үсеш буенча урынбасары Ильвира Пузырева концепциягә башкарма комитет тәкъдимнәренең ике генә пункты керүгә борчыла:

– Чаллы – Түбән Кама – Чистай трассасын һәм Зәй елгасы аша кичүдәге күперне киңәйтү планга кертелде, бу бистәләр һәм «Кама Алане» индустриаль паркы арасындагы элемтәләрне яхшыртачак. Трамвай юлларын 13 километрга озынайту расланды – Промзонадан яңа микрорайоннарга кадәр. Микрорайоннар бик еракта, ә халыкның күпчелеге сәнәгать предприятиеләрендә эшли: алар юлга 40-45 минут сарыф итә, югыйсә 10 минутта барып җитә алырлар иде. Башка проектларны – яңа микрорайондагы мәктәп һәм бакчаларны – кабул итмәделәр, торак массив «йокы» районы булып калачак.

«Кире кагылган» тәкъдимнәр арасында – яңа микрорайоннардагы өстәмә юллар һәм транспорт маршрутлары, елга портын реконструкцияләү, спорт-сәламәтләндерү инфраструктурасын капиталь ремонтлау. Аларны аерым пунктлар итеп «Иннокам»ны үстерү концепциясенә кертү теләге аңлашыла, әмма кластерның үз предприятиеләре дә социаль объектлар төзүдә катнашырга тиеш. Ярый әле республика да читтә калмый.

Республика, «ТАИФ» Компанияләр төркеме һәм җирле бюджет акчаларына шәһәр паркын төзекләндерү эше тәгәлләнеп килә. Шәһәр юлларын ремонтлауны республика, ТАИФ һәм «Татнефть» финанслый. Сулыкларны саклау елы кысаларында шәһәр яр буйлары күз алдында үзгәрә, ярлар ныгытыла, төзекләндерелә.

Шунысы гаҗәп, «Иннокам»ның федераль бюджеттан әле планда гына булган уртак финанслануы кайбер экспертларга «чамадан тыш» тоела: янәсе, татарстанлылар «инновацияләргә» йөзләрчә миллиард сум таләп итә, ә үзләре гади инфраструктура төзеп куячак. Әмма, беренчедән, «Иннокам» ул болай да «Сколково» яки «Роснано»га альтернатива буларак каралмады. Ә икенчедән, икътисадый алга киткән республикада бишьеллыкта югары җитештерүчән эш урыннарын 150 меңгә арттыру һәм шул ук вакытта сәнәгать җитештерүен бер ярым тапкырга ишәйтү инновацияләрдән башка бөтенләй мөмкин түгел.

PRESSA.RU

ГАЗГА КҮЧҮ: ФАЙДАСЫ БӘХӘССЕЗ

Татарстанда мотор ягулыгы сыйфатында кулланылачак тыгызландырылган һәм сыекландырылган табигый газны җитештерү, транспортлау һәм куллануның бердәм комплекслы системасы булдырыла. Инде 2023 елга ТРндагы барлык җәмәгать транспортының яртысы, коммуналь транспортның – 30 проценты, шулай ук төзелеш техникасының 30 проценты газда эшләр, дип көтелә.

Газ-мотор ягулыгының өстенлекле яклары бик яхшы мәгълүм: ул традицион ягулыкка караганда экологик яктан чистарак һәм арзанрак, бу сыйфат исә авто хуҗаларына һәм автомобиль предприятиеләренә шактый акчаны янга калдырырга мөмкинлек бирә. Әмма Россиянең күп кенә төбәкләрендә газ салу станцияләре экзотикага тиң, бу, әлбәттә, техниканы газга күчерүне шактый тоткарлый. Бу яктан Татарстандагы хәлләрне уңай бәяләргә була. Биредә ачылган автомобильләргә газ тутыру компрессор станцияләре (АГТКС) челтәре инде бүген автомобильләрне күпләп газга күчерергә мөмкинлек бирә. Шул ук вакытта челтәр бик тиз киңәя бара, мәсәлән, июньдә ТРнда инде булган ун АГТКСка Яшел Үзәндә, Түбән Камада һәм Бөгелмәдә урнашкан гомуми җитештерүчәнлеге 27,4 млн кубометр булган тагын өч станция килеп кушылды. Алар көн саен 600дән артык автомобильгә табигый газ салуны тәэмин итәргә сәләтле. Ә ТРнда газ салу инфраструктурасының җитештерүчәнлеге 106 млн кубометрга кадәр артты. Татарстан тәҗрибәсе – газ-мотор ягулыгы базарында, аерым алганда, гомумроссия масштабында чын мәгънәсендә алгарыш үрнәге ул. Яңа АГТКСларны Яшел Үзәндә, Түбән Камада һәм Бөгелмәдә бер үк вакытта эшләтеп җибәрү тантанасында «Газпром» ГАҖ Директорлар советы рәисе Виктор Зубковның, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның, шулай ук «Газпром» Төркеме компанияләре җитәкчеләренең һәм газ-мотор ягулыгын төп кулланучыларның катнашуы да очраклы түгел.

2013–2015 елларда Татарстан 869 берәмлек газ-мотор техникасы сатып алды, аларның күбрәк өлеше – автобуслар.

– Европада мондый станцияләр төземиләр. Без исә транспорт тарафыннан газ куллану күләмен елына 9–10 млрд кубометрга җиткерергә планлаштырабыз, – диде Виктор Зубков. – Моның өчен ил буенча шундый меңнәрчә станциядән торган челтәр төзергә кирәк булачак. Хәзер үк «Газпром» ГАҖ әлеге максатка 80 млрд сумга якын акча бүлеп бирергә әзер.

Зубков сүзләренчә, кайбер төбәкләрнең яңалыкны хуплаулары күренми. Һәм бу очракта ул Татарстаннан үрнәк алырга киңәш бирде. Республикада мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ инде дистә елдан артык вакыт дәвамында кулланыла. Болар барысы да «Газпром»ның бүлендек җәмгыятьләре арасында беренчеләрдән булып әлеге өметле юнәлешне тормышка ашыруга алынган «Газпром трансгаз Казан» тырышлыгы белән башкарыла.

Бүгенге көндә «Газпром трансгаз Казан» Казан, Яр Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама, Мамадыш, Бөгелмә, Буа, Шәмәрдән, Яшел Үзәндә 13 газ салу станциясен эксплуатацияли. Ел азагына кадәр республикада тагын берничә яңа АГТКС эксплуатациягә кертеләчәк. Узган елны мотор ягулыгы сыйфатында «Газпром трансгаз Казан» 14,2 млн кубометр күләмендә тыгызландырылган табигый газ сатты, бу, бер ел элек булган нәтиҗә белән чагыштырганда, 32,6 процентка артыграк дигән сүз.

Әлбәттә, масштаблы бурычны уңышлы итеп тормышка ашыру газ җитештерү структуралары һәм төбәк хакимиятенең уртак тырышлыгыннан башка мөмкин түгел. Бу җәһәттән дә Татарстан – үрнәк. Республикада «2013–2020 елларга Татарстанда газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» комплекслы программасы эшләнгән һәм үтәлә башлаган, аны тормышка ашыруда «Газпром трансгаз Казан» актив катнаша. Максат – 2023 елга җәмәгать транспорты паркының – 50 процентын, коммуналь һәм төзелеш техникаларының 30ар процентын газ-мотор ягулыгына күчерү.

Виктор Зубков хәбәр иткәнчә, «Газпром мотор ягулыгы» компаниясен төзү газ-мотор ягулыгы базарын алга таба үстерү юлында тагын бер мөһим адым булып тора – АГТКС челтәре белән махсуслашкан предприятие шөгыльләнү нәтиҗәләрәк. Шуңа күрә алга таба эш алгоритмы түбәндәгечә булыр дип күзаллана: әкренләп яңа АГТКСларны гамәлгә кертә барырга, искеләрен реконструкцияләргә һәм «Газпром газ-мотор ягулыгы»на бирергә.

Бүген автотранспортны газга күчерүне җитди тоткарлап тора торган фактор – газ-мотор техникасының бәясе: ул гадәтигә караганда 20 һәм аннан да күбрәк процентка кыйммәтрәк. Потенциаль кулланучылар өчен ул хәлиткеч әһәмияткә ия.

Реклама

Яшел Үзәндә Татарстан Республикасында «Газпром» автомобильләргә газ тутыру буенча компрессор станцияләре (АГТКС) челтәрен гамәлгә кертүгә багышланган тантаналы чара узды.

Максат ачык: яңа газ-мотор техникасының бәясе бензин яки дизель ягулыгында эшли торганга караганда кыйбатрак булмаска тиеш. Виктор Зубков сүзләренчә, хәл итү юлын ил Хөкүмәте белән бергә эзләячәкләр.

Оптималь карар кабул иткән чакта, ихтимал, кабат Татарстан тәҗрибәсенә таянып эш итәрләр. Бирелә, аерым алганда, ТР Министрлар Кабинеты һәм «Газпром газ-мотор ягулыгы» компаниясе арасында газ-мотор ягулыгы базарында үсешне стимуллаштыра торган программаларны тормышка ашыру буенча килешүгә кул куелды. Аның буенча, мәсәлән, республика транспортны газ-мотор ягулыгына күчерү буенча чыгымнарны субсидияләүгә акча бүлеп бирәчәк, ә «Газпром» ягыннан яңадан җиһазландыруга уңайлы займ алу өчен акчалар юлланачак. Шулай ук 1,5 мең кубометр ягулык сатып алуга шәхси ягулык карталары тапшырылачак, бу газ-мотор ягулыгына күчүне тиз арада башкаруга этәргеч булырга тиеш. Программада юридик затлар да, физик затлар да катнаша ала.

Исегезгә төшерәбез, Татарстан Россия Энергетика министрлыгы тарафыннан транспортта газ куллану буенча пилот проектларны гамәлгә ашыручылар исемлегенә кертелгән һәм бүген үк газ баллоны техникасы сатып алу саны буенча лидер булып тора. Пилот проект кысаларында республикада табигый газны сыекландыру буенча комплекс һәм КриоАЗС челтәрен төзү планлаштырыла. Бу җитештерүдән башлап куллануга кадәр илткән бердәм технологик чылбыр булдыру юлы белән алга киткән бурычны комплексны чишүнең ачык мисалы булып торачак.

«Газпром» Татарстанда аз тоннада СТГ җитештерү һәм аны салу инфраструктурасы булдыру буенча пилот проектны тормышка ашырырга планлаштыра. Проект «Чистай» индустриаль паркы территориясендә газны сыекландыру буенча комплекс һәм республиканың төп магистраль юлларында 13 криоген ягулык салу (КриоАЗС) станциясеннән торган сату челтәре төзүне күздә тота.

Проектны тормышка ашыру транспорт чараларына һәм махсус техникага тыгызландырылган һәм сыекландырылган табигый газ салуны тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк. Ягулык станцияләренең киң челтәреннән файдалану хәзерге вакытта бензин салу станцияләреннән файдалану кебек үк уңайлы һәм җиңел булачак. ТР территориясендә объектлар төзү буенча планнар төбәк хакимиятенең барлык төр транспортта табигый газ куллануны киңәйтү буенча планнарына тулысынча туры килә. Республика җитәкчелеге белән үзара хезмәттәшлек – проектны уңышлы тормышка ашыруның нигезе.



СҮЗ УҢАЕННАН
2016 ел азагына кадәр «Газпром» Татарстанда тагын биш яңа АГТКС гамәлгә кертергә һәм эшләп килә торган бер станцияне реконструкцияләргә ниятли. 2019 елга газ тутыру станцияләре челтәрен 25 берәмлеккә кадәр арттырып, шактый күп эре торак пунктларны колачлау күз алдында тотыла.

PRESSA.RU

ТаграС
нефтесервисный холдинг

Татарстанга инвестияләр җәлеп итү мөмкинлеген бай тарихлы һәм күпьеллык тәҗрибәгә ия булган компанияләр булдыра. Георазведка, нефть һәм газ сәнәгате инфраструктурасын төзекләндерү һәм үстерү буенча нефть сервисы хезмәтләренең тулы комплексын тәкъдим итә торган «ТаграС» холдингы республика икътисадындагы шундый локомотивларның берсе булып тора.

«ТаграС» компанияләр төркеме Россиядәге бүлекчәләре илнең нефть һәм газ сәнәгате инфраструктурасын төзү һәм үстерүгә шактый зур өлеш кертә торган нефть тармагына сервис күрсәтү холдинглары арасында иң эреләрдән санала. Бүгенге көндә холдинг 11 сервис күрсәтү дивизионына берләштерелгән йөзгә якын предприятиене үз эченә ала.

Аларның күбесе хәзерге Татарстан территориясендә әле совет заманында ук төзелгән, совет, ә хәзер инде советлардан соңгы пространство территориясендәге эре проектларда катнашып, алар шактый зур тәҗрибә туплады.

Элекке заманда да, бүгенге көндә дә эшкә инновацияле яктан якын килүгә бәйле рәвештә холдинг предприятиеләре үз тармакларында лидер булып тора, дәрәҗәле халыкара һәм Россия бүләкләренә ия була. Бүгенге көндә холдингның уңышлы эшләп килүе – Татарстанга зур күләмдә инвестицияләр җәлеп итә алуның бер өлеше булып тора.

Холдинг дивизионнары «Татнефть», «Роснефть», «Газпром», «Газпром нефть», «Лукойл», «Русснефть», «Славнефть», «Сургутнефтегаз» компанияләре белән уңышлы хезмәттәшлек алып барып, сервис хезмәте һәм технологияләр белән тәэмин итүче сыйфатында капитал сыйдырышлы һәм инфраструктур проектларны тормышка ашыруда катнаша, мөстәкыйль һәм кече нефть компанияләренә нефть сервисы хезмәтләрен күрсәтә.

Россия территориясендәге агымдагы төп проектлар Татарстанда, Төмән, Самара, Оренбург һәм Иркутск өлкәләрендә, Коми, Удмуртия, Калмыкия, Якутия Республикаларында һәм Красноярск краенда, шулай ук якын чит илдә – Казахстан һәм Үзбәкстанда тормышка ашырыла.

Россиядән читтә холдингның Африка һәм Якын Көнчыгыш, Төньяк һәм Көньяк Америка, Һиндстан һәм Төркия, Вьетнам һәм Әфганстан регионнарында сервис хезмәтләре, технология һәм җиһаз китерү буенча шактый зур тәҗрибәсе бар.

Холдинг дивизионнары, шул исәптән коммуналь төзелеш, транспорт, энергетика белән бәйле булган социаль юнәлешкә ия инфраструктур проектларда катнаша, бу хәл холдинг предприятиеләренең үз икътисадый тотрыклылыгын ныгытуда мөмкинлекләрен киңәйтүгә мөмкинлек бирә.

ХОЛДИНГНЫҢ ДИВИЗИОННАРЫ ҺӘМ ЭШЧӘНЛЕК ЮНӘЛЕШЛӘРЕ

ТНГ-ГРУПП
Нефть ятмаларын эзләү һәм тикшерү, бораулау, скважиналарны ремонтлау һәм эксплуатацияләү вакытында геофизик тикшеренүләр үткәрү. Геофизик материалны аңлату.

ТАТБУРНЕФТЬ
Яңа технологияләр һәм җиһазлар кулланып, авыш юнәлешле һәм горизонталь скважиналар, кечкенә диаметрлы скважиналар бораулау.

ТМС ГРУПП
Нефть табу һәм скважиналар бораулау өчен кирәкле җиһазларга комплекслы хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау.

ТАТСПЕЦТРАНСПОРТ
Махсуслашкан технологик транспорт хезмәтләре күрсәтү.

ТАГРАС-ТРАНССЕРВИС
Йөк ташу, пассажирлар йөртүне тәэмин итү.

ТАГРАС-РЕМСЕРВИС
Кечкенә диаметрлы скважиналар бораулау һәм яннан кисеп керү. Катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру ысулларын куллану, скважиналарга капиталь һәм агымдагы ремонт үткәрү, сыгылмалы торба белән ремонт уздыру, скважина эчендәге тоткарлыкны юкка чыгару, химия продукциясен җитештерү.

ТАГРАС-ЭНЕРГОСЕРВИС
Нефть-газ табу объектларын электр һәм җылылык белән тәэмин итү, электр энергетикасы объектларына сервис күрсәтүне тәэмин итү.

СИСТЕМА-СЕРВИС
Электр ярдәмендә төялә торган насос җайланмаларына, катлам басымын тоту (КБТ) системасы җайланмаларына һөнәри хезмәт күрсәтү.

ТАТНЕФТЕДОР
Автомобиль юлларын төзү һәм ремонтлау, юл буендагы полосаларны карап тоту.

ТАГРАС-НЕФГАЗСТРОЙ
Нефть һәм газ чыганакларын төзекләндерү, магистраль нефть һәм продуктүткәргечләр, граждан төзелеше объектларын торгызу.

ТАТИНТЕК
Скважиналар белән идарә итү процессын автоматлаштыру («интеллектуаль скважиналар»), клиентлар өчен автоматлаштырылган эш урынына хезмәт күрсәтү, тикшерү-үлчәү аппаратурасы паркына метрологик сервис күрсәтү.

Элемтә өчен:
Гагарин урамы, 10 йорт, Әлмәт,
Татарстан Республикасы, Россия, 423450
тел. +7 8553 31 46 00
факс +7 8553 31 46 49
e-mail: info@tagras.ru
www.tagras.ru

Реклама

ТМС ГРУПП

Төрле катлаулылыктагы конструкторлык документациясе

Югары квалификациягә ия инженерлар командасы кыска вакыт эчендә КДБС һәм нефть һәм машина төзү тармаклары өчен дәүләт тарафыннан регламентлана торган башка документлар нигезендә конструкторлык документациясенең тулы комплектын эшли.

ЭШ ТӨРЛӘРЕ:

- 2D-, 3D-модельләштерү;
- Конструкциянең һәр элементындагы көчәнешне бүлү мөмкинлеген билгеле торган APM Structure 3D автоматлаштырылган программа комплексын кулланып, соңгы элементлар ысулы белән проектлаштыру һәм ныклыкны исәпләп чыгару;
- Конструктор документларының (детальләрне, җыю берәмлекләрен, спецификацияләрнең сызымнарының) тулы комплектын эшләү;
- Норматив-техник документацияне (эшләп чыгаруга, эксплуатацияләү, сынау программалары һәм методикалары буенча кулланмалар, җиһазларның куркынычсызлыгы нигезләрен) эшләү;
- Эшкәртә торган күпфункцияле үзәкләрдә (Mitsubishi MVR 30) һәм санлы программа белән идарә ителә торган станокларда тәҗрибә рәвешендә стандарт булмаган продукция җитештерү;
- Катлаулы элементлар һәм технологик җиһазлауның тулы комплектларын, шулай ук инструментлар ясау;
- Конструктор тарафыннан продукция ясауны озатып бару;
- Продукциягә сертификат һәм патент бирү буенча эшләр. Төрле катлаулылыктагы конструкторлык документациясе.

СЫЙФАТ ГАРАНТИЯСЕ

- Башкарылган эшләрнең киң портфолиосы, хөкүмәт һәм тармак бүлекләре һәм даими заказ бирүчеләр ышанычы;
- Нәтиҗәгә эшли торган профессионалларның бердәм командасы;
- Эш нәтиҗәләренең нәтиҗәлелекнең заказ бирүче тарафыннан килештерелгән һәм расланган төп күрсәткечләренә төгәл туры килүе;
- Эшләп чыгарыла торган һәр продукт буенча мәгълүматларның конфиденциаль булуы;
- Заказ бирүченең эш нәтиҗәләренә 100 процентлы хокукы;
- Эшләнмәнең сәнәгать дизайны буенча проектлау һәм тәкъдим итүнең һәр этабында сакчыл җитештерүнең киңәйтелгән инструментариен куллану.

1

КАЗАНЫШЛАРНЫ ТАНУ

Гражданнар өчен очкычлар төзүдә кулланыла торган детальләр китерүгә лицензия алынды. МС-21 урта магистраль очкыч өчен компонентлар җитештерүгә технологик җиһазлар чыгарудагы тәҗрибә.

8-800-250-79-39
tmcg@tmcg.ru
www.тмс-групп.рф

ТАГРАС
нефтесервисный холдинг

Реклама

PRESSA.RU



Найми профессионалов

8-800-250-7-116
oco@mechservice.ru

г. Альметьевск,
ул. Мира, д. 6

«ЯҢА ТЕЛЕФОНИЯ» – ЫШАНЫЧ ҺӘМ САКЛЫК НИГЕЗЕ

Һәрвакыт синең белән булган элемтә – бизнесны уңышлы алып баруның иң мөһим өлешләренең берсе булып тора. Компания һәм предприятие хуҗалары һәм идарәчеләре өчен телефон номерының төгәл бер урынга бәйле булмавы, элемтә өчен чыгымнарның аз күләмлелеге, өзлексез эшләве, ә элемтә операторының клиентларына өстәмә функцияләрнең киң сайлау мөмкинлеген тәкъдим итүе мөһим. «Ростелеком» югарыда санап үтелгән таләпләрнең барысына да җавап бирә торган «Яңа телефония» дип аталган инновацияле хезмәт тәкъдим итә.

«Яңа телефония» – функционалы традицион телефониядән шактый киңрәк мөмкинлекләргә ия булган виртуаль АТС. Аңа тоташкан чакта клиентка куллану өчен географик яктан бәйле булмаган дөньяның төрле почмакларыннан шалтырату кабул итү, аудио-һәм видеоконференция оештыру, үзеңнең виртуаль контакт-үзәгеңне булдыру һәм тавыш яздыру өчен күпканаллы телефон номеры бирелә. Кыска номерлы корпоратив челтәр төп офисны, филиалларны, үз офисларын һәм читтә урнашкан урыннарда эшли торган хезмәткәрләрнең телефоннарын колачларга мөмкинлек бирә. Аңа күпканаллы телефон номерлары кушарга, шулай ук өстәмә функцияләр, мисал өчен интеллектуаль рәвештә башка адреска юллау, шалтыратуны бүлүнең тавыш сценарие, тавыш почтасы, текст һәм видеочатлар. «Яңа телефония»нең гомуми сервислары – 40тан артык. Шул ук вакытта алар аларга кирәк өчен кирәк булган бердәнбер һәм иң мөһим шарт – интернет челтәренә керә алу мөмкинлеге.

Шулай ук компания өчен аның күләме һәм урнашкан урынына бәйсез рәвештә «Яңа телефония» кысаларында клиент өчен 8-800 номеры буенча шалтыратуны түләүсез башкару мөмкинлеген аерым ассызыкларга кирәк. Мондый номерга шалтырату кысаларында башкарылган барлык сөйләшүләр дә язылып барырга мөмкин, һәм бу компания бүлекчәләренең эшен күзәтеп барырга мөмкинлек бирә.

Хәер, уңайлылык һәм нәтиҗәлелек – бу әлеге хезмәтнең бердәнбер үзенчәлеге түгел: «Яңа телефония»гә күчәргә теләк белдергән кеше традицион «тимер» АТСны сатып алуга, урнаштыруга һәм аңа хезмәт күрсәтүгә китә торган акчаны янга калдыра. Ә «Яңа телефония» кысаларында болыт аша башкарылган шалтыратулар традицион вариант белән чагыштырганда арзангарак төшә.

Хезмәт ачык тарификация һәм юнәлешләр буенча шалтыратуларның бердәм бәясе белән аерылып тора.

«Яңа телефония» SIP (СИП)-телефоннарда да, VoIP (ВоАйПи)-шлюз кулланыла торган гадәти телефон аппаратларында да эшли. Моннан тыш, «Ростелеком» үз клиентлары өчен Windows ОС («Виндовс» операцион системасы) базасында эшли торган компьютерлар һәм iOS («айОС» операцион системасы) һәм Android («Андроид» операцион системасы) платформаларындагы мобиль җайланмалар өчен программалы телефоннар тәкъдим итәргә әзер. Шул рәвешле, «Яңа телефония»гә тоташырга теләүчеләр өчен «Ростелеком» хезмәт белән җиде көн дәвамында тест рәвешендә бушлай куллану мөмкинлеге бирә.

«Яңа телефония» белән идарә итү процессы исә нииндидер махсус күнекмәләрне таләп итми – җиңел веб-интерфейс белән эшләүне һәрбер хезмәткәр башкарып чыга алачак. Ә хезмәтне берничә минут эчендә «Ростелеком» сайты аша (www.rt.ru) тоташтырырга мөмкин.

«Яңа телефония» турында өстәмә мәгълүматны **8-800-200-3000** телефоны буенча шалтыратып алырга мөмкин.

Реклама

PRESSA.RU



Проектирование, производство
и установка «под ключ»
эксклюзивных изделий и конструкций
из ценных пород дерева



ООО «ЗАВОД ДЕКО»
г. Ижевск, ул. Архитектора П. П. Берша, 32.
Тел.: (3412) 608-751, 50-88-06, 8-912-760-45-42
www.deko-izh.su zavoddeko@yandex.ru

ДЕКО™

Реклама

СЫЙФАТ БИЛГЕСЕ

«Сыйфат билгесе» проекты кысаларында «Татарстан» журналы дәрәҗәле премияләр җиңүчеләре һәм дипломантлары – иң яхшы предприятиеләр, иң яхшы җитәкчеләр, иң яхшы товарлар һәм хезмәтләр турындагы сөйләшүне дәвам итә.

«Иң яхшы товарлар һәм хезмәтләр – ГЕММА» Халыкара конкурсы

«Иң яхшы товарлар һәм хезмәтләр – ГЕММА» Халыкара конкурсы финалында катнашу хокукы сайлап алу турының иң югары бүләге – Алтын медальгә лаек булган компанияләргә бирелә. Конкурсның финал этабы җиңүчеләре почетлы лауреат исеменә һәм конкурсның иң югары бүләге – «ГЕММА» алтын сынына ия була.

«ГЕММА» премиясенә тәкъдим ителгән барлык товар продукциясе мәҗбүри тәртиптә лаборатор тикшеренү үтә. Азык-төлек товарлары үрнәкләре Новосибирск өлкәсенең Кольцово фән шәһәрчегендәге бөтендөнья әйдәүче тикшеренү үзәкләренең берсе – «Вектор» лаборатория базасында аеруча җентекле сынау уза. Конкурс лауреатлары чит ил хөкүмәтләре һәм дәүләтара берләшмәләр, шул исәптән БМО, БРИКС, ЕС, ШОС һәм АТЭС вәкилләре белән үзара бәйләнешне тормышка ашыру өчен рәсми делегацияләр составына керү хокукы ала.

«Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары» республика конкурсы

Конкурс ел саен «Россиянең 100 иң яхшы товары» Программасы кысаларында үткәрелә. Аның максаты – югары сыйфатлы товарларны һәм хезмәтләрне ачыклау һәм алга җибәрү, сыйфатлы продукция җитештерүче татарстанлыларның абруен күтәрү, предприятиеләрнең (шул исәптән кече һәм урта бизнес) җитештерелә торган товарлар һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын һәм конкурентлыкка сәләтен арттыру буенча эшчәнлеген стимуллаштыру.

Оештыру комитеты карары белән җиңүчеләр «Россиянең 100 иң яхшы товары» программасы кысаларындагы конкурсның федераль турына, шулай ук Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы хөкүмәтләренең сыйфат өчен премияләренә тәкъдим ителергә мөмкин. Конкурс җиңүчеләре үз продукцияләрен «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары» билгесе белән келәймәләү хокукы ала. Конкурсның рәсми оештыручылары һәм партнерлары түбәндәгеләр:

- Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы
- Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы
- «Татарстан стандартлаштыру, метрология һәм сертификация үзәге» Федераль дәүләт учреждениесе
- «Казан ярминкәсе» ААҖ

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең сыйфат өчен премиясе

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең сыйфат премиясен алу өчен оештырылган конкурсның «ачык» дигән статусы бар. Бу анда Россия Федерациясенең башка төбәкләрендәге компанияләргә дә катнашу мөмкинлеге бирә.

Быел әлеге конкурс ике номинация буенча үткәрелә: «Эшлекле камиллек» һәм «Җитештерү системалары». Конкурсның «Эшлекле камиллек» номинациясендә катнашучыларны бәяләү сыйфат өлкәсендә Россия Федерациясе хөкүмәте премиясе һәм Европа сыйфат менеджменты фонды (EFQM) төзегән Европа премияләре критерийларына охшаш. «Җитештерү системалары» номинациясе җитештерүгә сак караш принципларына нигезләнгән. Премия предприятиеләргә һәм оешмаларга продукция һәм хезмәтләрнең сыйфаты һәм аларның иминлеген тәэмин итү өлкәсендә мөһим нәтиҗәләргә ирешкән һәм идарә итүнең югары нәтиҗәле ысулларын тормышка ашырган өчен ел саен конкурс нигезендә бирелә.

PRESSA.RU

«СЫЙФАТ ЙОЛДЫЗЫ» НУРЛАРЫНДА

Илшат Гафуров, КФУ ректоры:
«Безнең бүгенге максатыбыз – авыр нефть чыгаруның экологик, икътисадый һәм энергоэффектлы ысулларын эшләү, тулаем илебезнең дә, төбәгебезнең дә тотрыклы үсешен тәэмин итү. Бу юнәлештә эш Геология һәм нефть-газ технологияләре институты, Химия институты, Физика институты һәм күп кенә башка институт мәйданчыкларында алып барыла».

Данис Нургалиев, Геология һәм нефть-газ технологияләре институты директоры:
«Укыту программалары төзегәндә Өстәмә белем бирү, менеджмент, сыйфат һәм маркетинг үзәге фән һәм җитештерүне мөмкин хәтле үзара якынайтырга тырыша. Моның белән үзенең тыңлаучыларында актуаль теоретик һәм практик белемнәрнең идеаль ярашуын тәэмин итә, һәм бу, үз чиратында, берничә тармак үсешенә ярдәм итә торган профессиональ мохит формалаштыра».

Без – КФУның Геология һәм нефть-газ технологияләре институты Өстәмә белем бирү, менеджмент, сыйфат һәм маркетинг үзәгенең уку классында. Алдыбызда – гамәлдәге нефть чыганакларының 3D-моделе, Schlumberger[1] компаниясе җитештергән Petrel[2] симуляторы. Стереоскопик күзлек аша зондларның әйләнеп торучы җир катламын тишеп үтүен һәм нефть япмаларына килеп чыгуын күзәтәбез.

Белемне арттыра торган мондый технологияләр биредә көндәлек уку әсбабы буларак кабул ителә, өстәвенә, институт бер җитештерүче белән генә чикләнми, ә CMG[3], ROXAR[4], Schlumberger, Paradigm[5], Beicip franlab[6] кебек алдынгы җитештерүчеләрнең төрле технологияләрен үзендә туплый. Нәтиҗәле эшләүче, конкурентлыкка сәләтле белгечләр хәзерләүнең нигезендә фән һәм техниканың соңгы казанышлары ятарга тиеш, дип исәпли үзәк директоры Илдус Чукмаров.

– Безнең карамакта нефть-газ тармагы өчен инженер кадрлар хәзерләү һәм кабат укыту буенча 69 программа бар, шуларның 12се – читтән торып уку өчен. Тармакның әйдәүче предприятиеләре югары технологияләрдән, өр-яңа программалар һәм инженер табышларыннан файдалана, һәм, димәк, аларның җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре тиешле белемгә ия булырга тиеш. Программаларыбыз актуаль булсын өчен, аларны эшләүгә нефть чыгару һәм аны эшкәртү өлкәсендә иң камил җиһазлар һәм технологияләр җитештерүче компания белгечләрен, бу тармакның экспертларын, һәм, әлбәттә, фәнни тикшеренүләр белән шөгыльләнүче белгечләрне җәлеп итәбез. **Үзәкнең девизы: «Һәркемнең уңышы өчен барыбызның да мөмкинлекләрен берләштерәбез».**

Менә дүрт ел инде КФУның Геология институты үзәге инженер кадрлар хәзерләү буенча федераль максатчан программада катнашып килә. Хезмәтләренең күләме белән ул Россиянең 70 университеты арасында бишенче урынны били.

Үзәк КФУның үзенең динамик үсеше белән бергә атлый. Моңа университет алдына ректор Илшат Гафуров куйган бөек максатларны тормышка ашыру ярдәм итә. Халыкара югарылыкка чыгу, Куба, Гыйрак, Казахстан һәм башка илләр компанияләре белән хезмәттәшлек итү, технологияләрне даими камилләштерү, укыту процессын оптимальләштерү – бу әле ул максатларның берничәсе генә.

– Без вакыттан узып эшләргә тырышабыз, – ди Илдус Чукмаров. – Нефть чыгару технологияләре базары бик тиз үзгәрә, һәм, дөньядан артта калмас өчен, киләчәкне алдан күрә белергә һәм аны үзебез тудырырга тиеш дип уйлыйбыз.

Укыту процессын төгәл һәм нәтиҗәле оештыруда Үзәккә КФУның фәнни эшчәнлек буенча проректоры Данис Нургалиев ярдәм итә. Программалар лекторлары арасында ул җитәкли торган Геология һәм нефть-газ технологияләре институтын тәмамлаучылар, шулай ук Үзәкнең профессорлары, профессиональ хезмәткәрләре һәм чит ил экспертлары – бөтендөнья югарылыгындагы компанияләр вәкилләре бар.

Әмма белем бирү процессының сыйфаты тотрыклы булмаса, бернинди югары технологияләр дә студентның тиешле белем дәрәҗәсен тәэмин итә алмый. Күптән түгел үзәк 2015 ел нәтиҗәләре буенча «Иң яхшы товарлар һәм хезмәтләр – Гемма» халыкара конкурсы лауреаты (Россия Федерациясе) булды. Конкурсның максаты – иң күп төрле тармак предприятиеләре җитештергән продукциянең һәм аларның хезмәтләренең сыйфатын һәм конкурентлыкка сәләтлелеген стимуллаштыру. Илдус Әдһәмович җитәкчелегендә биредә махсус «сыйфат йолдызы» системасы гамәлгә кергән. Аны нәтиҗәле эшләүче менеджмент, инновацион технологияләр, бик яхшы кадрлар, инфраструктура, матди-техник яктан тоткарлыксыз тәэмин ителеш, шулай ук белем бирү процессында катнашучыларның һәммәсендә социаль һәм партнерлык җаваплылыгы формалаштыру тәшкил итә.

– Белем бирүнең сыйфаты өчен без клиентлар алдында җавап бирәбез, алар безнең алда белгечләренең тиешле дәрәҗәдәге хәзерлекләре һәм хезмәтләргә вакытында түләү өчен җавап бирә, һәм барыбыз бергә алынган һәм бирелгән белемнәр өчен дәүләт алдында җавап бирәбез. Шулай итеп, корпоратив культура формалаша – без аны Үзәктән читтә дә җәелдерәбез, һәм, димәк, республикабыз халкының тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрүгә өлеш кертәбез дигән сүз.

Институтның партнёрлары:

Schlumberger	ТНГ-Групп
Trimble[7]	Татнефть
CMG	Газпром
Rock Flow Dynamics[8]	Лукойл
Sercel[9]	Миррико
Beicip Franlab	

Геология һәм нефть-газ технологияләре институты курслары турында төгәлрәк мәгълүмат www.kpfu.ru/geo/cdo сайтында www.cdogeo.ru

Реклама

[1] Schlumberger – «Шлюмберген».
[2] Petrel – «Петрел».
[3] CMG – «СиЭмДжи».
[4] ROXAR – «Роксар».
[5] Paradigm – «Парадигм».
[6] Beicip franlab – «Бесип Франлаб».
[7] Trimble – «Тримбл».
[8] Rock Flow Dynamics – «Рок Флоу Дайнамикс».
[9] Sercel – «Серсель».

ҖИР АСТЫ БАЙЛЫКЛАРЫНА АЧКЫЧ

«Сан белән түгел, осталык белән сугыш» – Суворовның әлеге мәгълүм принцибы бүген тагын да актуальрәк яңгырый. Моның бер мисалы –«Татнефтепром– Зүзәйнефть» АҖ эшчәнлеге. Инновацион технологияләргә таянып эшләп, әлеге нефть чыгаручы кече компания үзенең тотрыклы икътисадый үсештә икәнлеген күрсәтте.

Компаниянең төп «көрәш кыры» – ТР Нурлат районындагы Зүзәй нефть чыганагы. Биредә эш җиңелләрдән түгел: нигездә авыр чыгарыла торган югары үзлелеккә ия нефть запаслары. Нефть чыгаруның икътисадый нәтиҗәлелеген тәэмин итү тагын да катлаулырак, шуңа күрә инновацияләр кулланмыйча булмый. Өр-яңа технологияләр кертү һәм алардан актив файдалануны күздә тоткан сыналган стратегия шуннан килеп чыга да.

Бу стратегияне «Татнефтепром – Зүзәйнефть» АҖндә җиренә җиткереп тормышка ашыралар. Аерым алганда, компания горизонталь скважиналарны һәм яннан бораулауны уңышлы үзләштерде, һәм бу скважиналар дебитын шактый арттырырга мөмкинлек бирде. Нефть чыгару өчен бер үк вакытта аерым файдалану ысулы җайланмалары кертү дә үзен тулысынча аклады, бу нефтьне бер үк вакытта төрле мәйданнардан чыгару мөмкинлеге бирә. Соңгы елларда актив кулланыла торган катлам басымын тоту системасы да үзенең нәтиҗәле икәнен күрсәтә.

Нефть чыгаруның тотрыклы булуы гына түгел, алынган чималны хәзерләү һәм транспортлау да компаниянең мөһим бурычы булып исәпләнә. «Татнефтепром – Зүзәйнефть» АҖ карамагында нефтьне хәзерләү һәм суыртып агызу цехлары да эшли. Биредә чимал катышмалардан арындырыла, дөнья стандартларына җиткерелә һәм «Транснефть» АК магистраль нефть үткәргечләренә кадәр транспортлана. Нефтьне хәзерләү һәм суыртып агызу буенча Зүзәй куәтләре башка компанияләр өчен дә кирәк – алар аша ел саен миллионга якын тонна чимал үтә.

Житештерүнең барлык этаплары, гаять катлаулы технологик процесслар реаль вакыт эчендә заманча мәгълүмати системалар ярдәмендә тикшерелеп һәм идарә ителеп тора – бу да игътибарга лаек. Төрле тайпылышларга оператив игътибар итү мөмкинлеге дә шуннан килә. Бу объектларның әйләнә-тирә мохиткә зарарлы тәэсирен шактый киметергә, җитештерүнең чисталыгын арттырырга мөмкинлек бирә. Сүз уңаеннан, экологик иминлек – компания эшчәнлегенең мәҗбүри шарты. Инде расланган һәм тормышка ашырыла торган экологик программа җир асты һәм җир өсте суларын, туфракны һәм атмосфера һавасын даими күзәтүне үз эченә ала.

«Татнефтепром – Зүзәйнефть» АҖ – социаль юнәлештәге компания. Ничек кенә булса да табыш алырга омтылу биредә гомумән хупланмый. Соңгы елларда ирешелгән икътисадый үсеш компаниягә үз миссиясен үтәргә – аны югары культурага, экологик иминлеккә, хезмәтнең нәтиҗәле һәм сыйфатлы булуына, персоналның социаль яктан яклануына ия булган үрнәк предприятие итәргә мөмкинлек бирүче нигез булып тора.

СҮЗ УҢАЕННАН

- Татнефтепром-Зүзәйнефть» АҖ – 2006 һәм 2007 елларда сыйфат өчен Татарстан Республикасы хөкүмәте премияләре лауреаты.
- «Россия икътисадының лидеры» милли премиясе («Россиянең иң яхшы салым түләүчесе-2009» номинациясе) дипломанты.
- Товарларның һәм хезмәтләрнең сыйфаты милли рейтингы критерийлары буенча предприятиегә «Россиянең иң яхшы предприятиесе – 2016» дигән мактаулы исем бирелде.
- Финанс-икътисадый күрсәткечләр буенча ул «Россия сыйфаты-2016» сертификаты белән бүләкләнде.
- Оешма белән идарә итү өлкәсендә эшмәкәрлек үсешенә ярдәм фонды тарафыннан «Милли сыйфат билгесе-2015» почетлы медале белән бүләкләнде.

Реклама

PRESSA.RU

ЭКОНОМИЯ – ТАБЫШ ЭКВИВАЛЕНТЫ

Бөгелмә механика заводында җир астыннан нефть чыгаруга киткән чагыштырма энергетик чыгымнарны һәм скважиналарның ремонт вакытында туктап тору вакытын киметергә мөмкинлек бирүче мөһим механизм – чылбырлы приводны сериялэп җитештерү 2004 елда башланган.

Биредә эшләнгән чылбырлы приводлар бүген Самара, Оренбург һәм Волгоград өлкәләрендә, Ханты-Манси автономияле округында һәм РФнең башка төбәкләрендә файдаланыла. Алар якын чит илләргә, аерым алганда, Казахстанга да җибәрелә.

Чыгарыла башлаганнан бирле чылбырлы приводларның төзелеше даими яңартылып һәм камилләштерелеп тора. 2016 елда Бөгелмә механика заводы «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре» конкурсы лауреаты булды. Заявка биргән 447 предприятиенең 203е катнашкан әлеге конкурска Бөгелмә механика заводы үз эшләнмәсен – ПЦ30-10-3-0,5/2,5 скважина штанга насосларының чылбырлы приводларын тәкъдим итте.

Нефтьнең бәясе нефть чыгаруны табышлы итүнең нигезен тәшкил итә: баррельнең бәясе түбәнрәк булган саен, нефть чыгаручы компанияләр табышны азрак ала. Аеруча кече дебитлы скважиналарда эшләүчеләр дөнья базарларында углеводородларга бәя төшкән чорда файдалану чыгымнарын киметү мохтаҗлыгы кичерәләр, моның бер юлы – турыдан-туры нефть чыгару җиһазының бәясен киметү. «Татнефть» ГАЖ Бөгелмә механика заводы белгечләре тарафыннан ПЦ30 чылбырлы приводның ике тәҗрибә үрнәге эшләнде.

Яңа привод гадәттә файдаланыла торган ПЦ60 озынлыгында, шул ук вакытта аннан 4,2 тоннага, ягъни 56 процентка җиңелрәк, ә үзе 59 процентка арзанрак. Материалларны һәм финанс ресурсларын шулай сизелерлек экономияләүгә конструкциянең металл сыйдырышлылыгын шактый киметү һәм 3 кВт куәтле шактый экономияле двигатель урнаштыру хисабына ирешелде (ПЦ60 чылбырлы приводында 5,5 кВт куәтле электродвигатель урнаштырыла); җиһазларны арзанайту белән бергә электроэнергияне азрак файдалану нефть һәм газ чыгару чыгымнарын өстәмә киметергә мөмкинлек бирә. Моннан тыш, чылбырлы привод механизмын камилләштерә барып, өч баскычлы махсус редуктор урынына ике баскычлы гомуми промышленность редукторы кулланылды һәм читтән кертелгән ике рәтле чылбыр үзебездә эшләнгән бер рәтлесе белән алыштырылды.

ПЦ30 чылбырлы приводны төзү Бөгелмә механика заводының фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре кысаларында башкарылды. Аны эшләүгә предприятие тарафыннан бер миллион сум акча салынды. ПЦ30 чылбырлы приводның ике үрнәге дә «Лениногорскнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсенә тапшырылды, анда алар скважиналарга урнаштырылды. Тәҗрибә-сәнәгать сынаулары нәтиҗәләре буенча «Татнефть» ГАЖ предприятиегә тагын илле берәмлек ПЦ30га заказ бирде, аның егермесе компаниянең төрле нефть һәм газ чыгару идарәләренә җибәрелде инде.

Бөгелмә механика заводы алдынгы идарә технологияләрен дә уңышлы тормышка ашыра.

Мәсәлән, ASME* Кагыйдәләр җыентыгы таләпләренә туры килү сертификациясенең барлык этапларын уңышлы үтү нәтиҗәләре буенча «Татнефть» ГАЖ Бөгелмә механика заводы 2016 елда «U» белән билгеләнгән ASME келәймәсен сугу хокукы биргән Америка инженер-механиклар җәмгыяте (ASME) сертификатын алды.

Шулай ук быел завод ГОСТ ISO 9001-2011 буенча сыйфат менеджменты системасы ресертификациясен һәм ISO 14001:2004 һәм OHSAS 18001:2007 стандартларына туры килүне раслау өчен сәнәгать куркынычсызлыгы, хезмәтне һәм әйләнә-тирә мохитне саклау буенча интеграцияләнгән менеджмент системасының беренче күзәтчелек аудитын тагын бер кат узды.

Моннан тыш, 2016 елда завод директоры Михаил Швецов Лин (МОО «Лин») фәлсәфәсе һәм принциплары нигезендә җитештерү системаларын үстерү буенча халыкара оешма уздырган конкурсның «Иң яхшы җитәкче» номинациясендә җиңүче булды, ә предприятие үзе конкурс нәтиҗәләре буенча призлы урын алды.

Бөгелмә механика заводы «Сакчыл җитештерү принципларын һәм ысулларын кертүгә салынган өлеш өчен» дигән истәлекле билге һәм Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының мактау грамотасы белән бүләкләнде.

Реклама

* ASME – Америка инженер-механиклар җәмгыяте.

SPA-капсула

Люкс магнитотурботрон

Эчәклекләрне тирәнтен чистарту аппараты

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ, НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТОВ

«ДЕЛЬФИН» – ҖИҢҮЧЕ

4 июльдә ТР Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында «Иң яхшы товарлар һәм хезмәтләр – ГЕММА» Халыкара конкурсының Татарстан Республикасы буенча лауреатларын бүләкләү тантанасы булып узды. Иң югары бүләк – «ГЕММА» алтын сыны Яшел Үзәннең «Дельфин» шифаханә-профилакториенә тапшырылды.

Реклама

Әлеге учреждение бу бүләккә клиентларга күрсәтелә торган хезмәтләрнең (ялны оештыру, яшәү һәм туклану, дәвалау-профилактик чаралар) бик яхшы сыйфатлы булуы нәтиҗәсендә ирешә. Бу өлкәдә ул Европа шифаханәләреннән һич тә калышмый. Биредә тән дә (белгеч-табиблар консультацияләре, диагностик тикшеренүләр, дәвалау ванналары, массаж, турыдан-туры Ессентукидан китерелә торган мәшһүр Тамбукан ләме кулланып дәвалау һәм күп кенә башка нәрсәләр), җан да («Дельфин» – гаилә белән ял итү өчен менә дигән урын), күз дә (биредә табигать искиткеч матур) шифа таба. Югыйсә, бу профилакторий әле чагыштырмача яшь: аңа 1994 елда Яшел Үзәндәге Горький исемендәге суднолар төзү заводының ведомство медицина учреждениесе буларак нигез салынган.

«Дельфин» шифаханәсе диетологлары дөрес туклану системасына аеруча игътибар итәләр, биредә ул «заказ-меню» принцибына яраклаштырып оештырыла: клиент үзенең рационын табиблар тәкъдим иткән ризыклар буенча үзе төзи.

«Дельфин»да сайлау мөмкинлеге дә зур: ризык ассортименты күптөрле, җиләк-җимеш һәм яшелчә, соклар һәм минераль сулар, үзләрендә пешкән камыр ашлары һәрчак булып тора. Дини йолаларны тотучылар өчен менюда хәләл ризыклар да бар.

Актив ял итәргә яратучылар өчен шифаханәдә спорт белән шөгыльләнү мөмкинлеге дә зур: биредә спорт һәм тренажер заллары, йөзү бассейны эшли, өстәл теннисы уйнау өчен кирәкле җиһазлар урнаштырылган. Тренировкадан соң, инфракызыл сауналарда ял итәргә мөмкин.

«Дельфин» шифаханәсе – ел әйләнәсе менә дигән ял итү урыны ул. Кышын чаңгыда йөрергә, җәен урманга ауга чыгарга, елгада балык тотарга, һичьюгы, кошлар җырын тыңлап, табигать белән хозурланырга була. Елның кайсы фасылы булуга карамастан, һәр кунак биредә яхшы сыйфатлы дәвалану процедуралары ала һәм тиешенчә ял итә ала.

«Дельфин» шифаханә-профилакторие коллективы

PRESSA.RU

ИКМӘК ТОРА ТАБЫН ТҮРЕНДӘ!

Фәрит Заһидуллин икмәк пешерүче булып чагыштырмача яңа эшли башлаган, белеме буенча ул – агачка уеп рәсем ясаучы. Аның сыннары һәм чатырлары Казанның ишегалларын, балалар бакчалары белән интернатларны, паркларны һәм шәхси биләмәләрне бизи. Ә дүрт ел элек аның кешеләргә хезмәт итү омтылышы бөтенләй икенче борылыш алган: үз куллары белән төзегән йортта Фәрит Заһидуллин икмәк пешерү белән шөгыльләнә башлаган.

Яңа һөнәргә алынуы хакында ул үзе менә болайрак фикер йөртә: язмышың алдан билгеләнгән һәм сиңа ниндидер программа йөкләтеп куелган икән, иртәме, соңмы, ул барыбер «эшли башлаячак».

Заһидуллин икмәгенең рецепты бик гади: он, су һәм оеткы. Шулай да «Иң яхшы товарлар һәм хезмәтләр – ГЕММА» Халыкара конкурсы экспертлары тарафыннан иң яхшы дип табылган продуктны җитештерә башлаганга кадәр Фәрит башта ике ел вакытын сарыф иткән.

Икмәкне шундый тәмле һәм файдалы итә алырдай оеткы ясарга өйрәнгәнче, ике ел эчендә ул бер тонна он тотып бетергән. Бу ике елдагы «эксперимент нәтиҗәләре» күрше тавыкларын ашатырга киткән. Фәрит үзенең аш бүлмәсендә икегә ике метр зурлыгындагы лаборатория ясап куйган булган, оеткы рецепты менә шунда туган. Онны ул сатып алмый, икмәкнең һәр яңа партиясе өчен өендәге тегермәндә арыш һәм бодайны үзе тарттыра.

– Дым тартмаса, ашлык бөртеге миллионнарча ел сакланырга мөмкин, – дип сөйли Фәрит. – Су тисә, уяна, андагы табигать тарафыннан салынган барлык витаминнар һәм микроэлементлар активлаша, орлык киләчәк үрентегә тормыш бирергә хәзерләнә башлый.

Заһидуллин икмәге витаминнарга һәм микроэлементларга, дөрестән дә, бик бай: яңа тарттырылган бөртектән җитештерелгәнгә, анда B төркемендәге витаминнар, A, E, F, C витамины, шулай ук фосфор, калий, магний, марганец, цинк һәм организмның төп функцияләрен саклау өчен кирәкле күп кенә башка микроэлементлар тулы күләмдә саклана. Алай гына да түгел, «ГЕММА» премиясенә тәкъдим ителгән товарларны һәм хезмәтләрне бәяләү барышында үткәрелгән Роспотребнадзор экспертизасы бу икмәктә зарарлы матдәләрнең һәм катнашмаларның яки бөтенләй юклыгын, яки гамәлдәге ГОСТ рөхсәт иткән нормадан шактый түбән икәнен күрсәтте.

Заһидуллинның икмәк пешерү йортында җитештерү циклы түбәндәгедән гыйбарәт: кичке сәгать биштә ул ашлыкны тарттыра. Кичке унга кадәр камыр басылган булырга тиеш. Бераз йоклап алганнан соң, төнге сәгать өчтә эш дәвам итә. Иртәнге сигездә катысы кетердәп, йомшагы күзәнәкләнеп торган әзер икмәк мичтән чыга. Ә иртәнге унда Фәритнең Казан Агропромпаркындагы сәүдә ноктасы ачыла: икмәкне ул бирегә үз машинасында алып килә. Һәм үзенең сәүдә маркасы төшерелгән сары футболкасын киеп, прилавка артына баса. Аена ул бер ярым тонна тирәсе икмәк пешерә, бу ике мең арыш һәм бодай икмәге дигән сүз. Сатып алучылар арасында очраклы кешеләр аз – аның икмәген бер тапкыр татып караган кеше бу ипине алырга кабат-кабат килә. Үзләре өчен дә, читтән килгән кунаклары һәм туганнарына «сувенир» итеп тә алалар – заводныкыннан аермалы буларак, Заһидуллин икмәге атна дәвамында йомшак саклана. Дөрес, ул «сувенир» иртәме-соңмы барыбер ашалып бетә, әмма Татарстан җире турындагы хатирәне биредә үстерелгән һәм пешерелгән икмәкнең хуш исе бөтен нәрсәгә караганда да яхшырак саклый, дип исәпли Фәрит Заһидуллин.

Реклама

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА ЭЛЕКТРОН ЮЛ БЕЛӘН ЯЗЫЛУ

PRESSA.RU
САЙТЫНДА ОНЛАЙН ЯЗЫЛУ:



1. »ЖУРНАЛЫ» төймәсенә БАС



2. «ОБЩЕСТВО И ПОЛИТИКА» бүлегенә КЕР

3. «ТАТАРСТАН» журналына КЕР



4. «КУПИТЬ» төймәсенә БАС

Реклама 16+

ТИЗ / ҖИҢЕЛ / АРЗАН

Реклама

«КӘГАЗЬ ЮЛБАРЫСЫ» ӨЧЕН НӘФИС СҮЗ СӘНГАТЕ

«Резюмируя, кратко сообщим: предпринята очередная попытка скомпрометировать нашу организацию»... Татарстандагы бер ведомство хезмәткәре Елена Сергеевна бу җөмләдәге хатаны табарга маташа. Тиз генә табылмый хата. Күрше өстәлләрдә аның коллегалары да текстларга төбәлгән – КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбендә җирле «тоталь диктант» бара.

Катерина Котова
әзерләде

ХАТА БӘЯСЕ

Танылган совет афористы Аркадий Давидович дәүләт хезмәткәрләрен «кәгазь юлбарыслары» дип атаган иде. Бигрәк төгәл чагыштыру, әйеме? Чөнки дәүләт эшлеклеләренең төгәллегеннән һәм дөрес яза белүеннән аерым кешеләрнең генә түгел, бөтен бер шәһәрләрнең язмышы да хәл ителергә мөмкин. Безнең тарихта чиновникларның мондый хаталарына да мисаллар шактый.

Аларның берсе... 1960 елда Лениногорск телевидениесе барлыкка килүгә сәбәпче була. Казахстандагы Лениногорскида түземсезлек белән көткән телевизион мачтаны ялгышлык белән ТАССРдагы шул исемдәге шәһәргә җибәрәләр. Чиновниклар югалган мачтаны эзләгән арада, Татарстандагы Лениногорск халкы, бер дә аптырап тормыйча, яңа җиһазларны урнаштырып та куя. Әмма буталчыклык моның белән генә бетми әле: берничә елдан соң Лениногорск телестудиясенә Мәскәүдән... предприятиене ябу турында фәрман белән депеша килә. Моның хата булуы, ягъни боерыкның Казахстандагы адаш студиягә тәгаенләнгәнлеге ачыкланганчы, бездәге телестудияне инде ябып та өлгерәләр.

Бүген, югары технологияләр, мәгълүмати сугышлар һәм маркетинг гасырында, Давидовичның билгеләмәсе актуальлеген югалтмаган гына түгел, бәлки әле өстәмә мәгънә төсмерләре белән баеган да.

– Көн саен минем эш өстәленә бик күп корреспонденция керә, – дип сөйли КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе директоры Игорь Привалов. – Хатның ни дәрәҗәдә дөрес язылуына карап, мин аны язган кеше турында гына түгел, бәлки бөтен предприятие яки ведомство турында да гомуми фикеремне булдыра алам. Бу бик имиджлы нәрсә, һәм дәүләт хезмәте системасы өчен ул аеруча әһәмияткә ия. Бәхеткә, дәүләт идарәчеләре моны үзләре дә яхшы аңлый. Былтыр без сораштыру үткәреп, алар өчен нинди укыту программасының аеруча файдалы булачагын ачыкладык. Нәтиҗәләр гаҗәпләндерде: бүлек һәм департамент җитәкчеләре үз хезмәткәрләренең күпчелеге документлар тутыру һәм грамоталы язу мәсьәләсендә кыенлык кичерүен хәбәр итте. Моннан соң без бүгенге көндә дәүләт хезмәткәрләренең ихтыяҗы иң зур булган «Эш хаты» программасын төзедек.

ДӨРЕС ЯЗУ БУЕНЧА... ТРЕНЕР

Семинар тереш тесттан башлана. Әнә шул, алдарак аталган, Елена Сергеевна баш ватып утырган тексттан. Гомуми нәтиҗә юанырлык түгел – грамоталылык тыңлаучыларның күпчелегендә теге яки бу дәрәҗәдә аксый. Алдарак әле аларны бик күп ачышлар көтә. Менә, мәсәлән, шушындые: «Мегаполис исеме алдыннан «город» сүзен аңлатучы «г.» кыскартылмасы язылмый». Тагын бер әһәмиятле өстәмә – хәзерге әдәби тел дәресе бирелә эчпошыргыч лекция формасында түгел, бәлки... тренинг формасында үткәрелә.

– Бу программаны эшләүгә без Казанда яхшы билгеле филологларны – Алексей һәм Елена Бастриковларны тарттык, – дип сөйли КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе директорының беренче урынбасары Галина

Нәтиҗәдә тыңлаучыларның башында – алынган белем, кулларында – үзара «кәгазь» аралашуның барлык очракларына диярлек «шпаргалка» булырлык тарату материалы кала, аларда реквизитларны дөрес тутырудан башлап, Япониянең Йокогама шәһәрен төрләндерү кагыйдәләренә кадәр бар.

Маштакова. – Бик күп мәгълүмат эшкәрттек. Беренчедән, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрнең иң еш җибәрә торган хаталарын ачыкладык. Икенчедән, аларның эшендә иң еш кулланыла торган хатларның типларын билгеләдек. Гади лекция форматыннан алдан ук баш тарттык, практикага юнәлтелгән дәресләр бирүне сайладык – документларны дөрес итеп ничек тутырырга кирәклеге һәм рус телендә нинди кагыйдәләр булуы хакында тыңлап утыра башласаң, бер сәгать тә гасыр озынлыгы тоелачак бит... Шунлыктан, бездә теория вакытның егерме процентыннан артыгын алмый.

Курсның һәр дәресе күнегүдән башлана. Елена Сергеевнага, мәсәлән, бу юлы «Мытищида үтәчәк бәйрәмгә» чакыру-хат язарга кирәк иде. Беренче карашка гади тоелган бирем шактый катлаулы булып чыкты. Җибәрелгән хаталарны анализлап, ул аларны укытучы белән тикшерә, аннары инде алынган практик белемне рус теле кагыйдәләре белән ныгыта (в городе Мытищи, ләкин: в Мытищах). Икенче этапта «укучы» үзе генә шуңа охшаган хат яза. Бер хатасыз ерып чыга.

Әлеге экспресс-курсның тулы исеме – «Дәүләт гражданлык һәм муниципаль хезмәтендә эш хаты». Хәзерге рус теленең генә түгел, татар әдәби теленең дә (икенче дәүләт теле программага аерым блок булып кертелгән) лексика һәм грамматикасы, орфография һәм пунктуациясе унсигез сәгатькә сыйдырылган. Берничә дәрес эшлекле язышу этикетына һәм идарә документларын тутыру кагыйдәләренә багышлана. Нәтиҗәдә тыңлаучыларның башында – алынган белем, кулларында – үзара «кәгазь» аралашуның барлык очракларына диярлек «шпаргалка» булырлык тарату материалы кала, аларда реквизитларны дөрес тутырудан башлап, Япониянең Йокогама шәһәрен төрләндерү кагыйдәләренә кадәр бар.

ДӘВАМЫ БАР...

– Ә сез бу курсның нәтиҗәлелеген ничек билгелисез? – дип сорыйм Галина Маштаковадан.

– Моның өчен кереш һәм йомгаклау тестларын эшләдек. Алар арасындагы люфт уртача төркем буенча якынча 20 процентны тәшкил итә. Бу бик яхшы нәтиҗә.

– Бу программаны бик шәп кабул итәләр! – ди КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе директоры урынбасары Наталья Аксенова. – Дөресен генә әйткәндә, тыңлаучыларыбызның сүзләре буенча, «Эш хаты» – алар өчен иң файдалы укыту программаларының берсе. Анда бернинди артык нәрсә дә юк. Бу – нәкъ менә алар көткән курс. Бездә аны өчәр тапкыр үткән кешеләр дә бар! Һәм һәр очракта үзләренә нинди дә булса яңа, файдалы мәгълүмат алганнар. Чираттагы бурычыбыз – курсның дәвамын булдыру: вакыт алга чаба, эшлекле хатларга куела торган таләпләр үзгәрә, хәзерге әдәби телнең дә эволюциясе дәвам итә.

Былтыр «Эш хаты» программасы кысаларында сигез йөз кеше белемен арттырган. Быел мәктәп инде республиканың тугыз йөздән артыграк дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрен җәлеп итәргә планлаштыра. Димәк, чиновникларның грамоталылык һәм компетентлык дәрәҗәсе һаман арта бара, дигән сүз.

P.S. Сүз уңаеннан, «Резюмируя, кратко сообщим: предпринята очередная попытка скомпрометировать нашу организацию» җөмләсендә хата аның беренче өлешендә. «Резюмируя» – болай да «кратко сообщим» дигәнне аңлата.

PRESSA.RU

СТРАТЕГИК ӘҺӘМИЯТКӘ ИЯ БУЛГАН **ОБЪЕКТ**

Беренче сентябрьдә Тукай районының Иштирәк авыл җирлегендә стратегик әһәмияткә ия булган энергетика объектын – 220 кВлы «Бигеш» подстанциясен тантаналы төстә кулланылышка тапшырдылар.

Көмешсу металлдан эшләнгән челтәрле конструкцияләр үзара электрүткәргеч чыбыклар пәрәвезе үреп, табигать манзарасына галәм киңлекләрендәге кебек төс бирә. Конструкцияләр туп-туры идарә итү пунктына илтә. Менә ул безнең алда – «Бигеш» подстанциясе, аны Түбән Кама районында мичтән бәлеш көткән кебек көтеп алдылар.

Хикмәт шунда: биредә Кама аръягындагы нефть химиясе тармагы предприятиеләре һәм заводлары күпләп урнашкан. Алар – төп электр энергиясе кулланучылар, өстәвенә, үзенчәлекле кулланучылар да. Нефть химиясе җитештерүенең үзенчәлеге шунда: электр энергиясенең сыйфаты нормадан бик кыска вакытка гына тайпылса да, техноген аварияләр, хәтта ки экологик һәлакәтләргә китерү ихтималы бар.

Яңа станция төбәктәге нефть химиясе комплексын электр энергиясе белән тәэмин итүнең ышанычлылыгын арттырырга тиеш, ул электр энергиясе белән тәэмин итүдә тайпылышлар сәбәпле аварияләр ихтималлыгын шактый киметәчәк, дип көтелә. «Бигеш» подстанциясенең ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов күрсәтмәсенә ярашлы рәвештә төзелә башлавын да искә төшереп үтик. Төзелеш эшләре узган елның март аенда башланган иде. Нормативлар буенча эшләрне башкаруга егерме ике ай кирәк булса, подрядчыларның эшләрне төгәл һәм һөнәри яктан оста оештыруы аркасында, алга куелган бурыч ике тапкырга диярлек тизрәк вакыт эчендә үтәлде.

– Әлеге станция безнең стратегик объект булып санала. Төзелеш вакытында максималь дәрәҗәдә үзебезнең илнең технологияләре кулланылды, Россия подрядчылары эшләде, – дип басым ясады «Бигеш» подстанциясен ачу тантанасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов. – Проект шактый кыска вакыт эчендә кулланышка ашырылды, тулысынча замана таләпләренә җавап бирә. Бу безнең төзүчеләрнең һәм энергетикларның югары һөнәри осталыгы турында сөйли.

Рөстәм Миңнеханов шуны да искә төшерде: республиканың 2030 елга кадәрге Стратегиясендә икътисадның төп үсеш нокталары булып нефть химиясе комплексы һәм машина төзелеше тора. Безнең нефть химиясе кластерының тотрыклы үсешен аны электр энергиясе белән өзеклекләрсез тәэмин итү билгеләячәк. Күргәебезчә, Стратегияерактагы перспектива түгел, урыннарда аның максат-бурычлары бүген үк гамәлгә ашырыла, һәм Тукай районындагы яңа станция – моның ачык мисалы.

220 кВлы «Бигеш» подстанциясен кулланылышка кертү республиканың нефть химиясе предприятиеләре күпләп тупланган территориядә электр энергиясе кытлыгы проблемасын хәл итәргә ярдәм итәчәк. Бүген үк анда югары квалификацияле хезмәткәрләр эшли, технологик процесслар белән идарә итүнең автоматлаштырылган системасы һәм электр энергиясен коммерция ягыннан исәпләүнең автоматлаштырылган мәгълүмати-үлчәү системасы урнаштырылган.

Подстанция белән бер үк вакытта яңа «Щелоков – Бигеш», «Бигеш – ТАНЕКО», «Бигеш – Түбән Кама» югары вольтлы электрүткәргеч чыбыкларын сузу эшләре дә алып барылды. Әйтергә кирәк, «Бигеш» подстанциясе 220 кВлы «Түбән Кама» подстанциясе янәшәсендә урнашкан. Мондый күрешелек очраклы гына түгел. Яңа объектның урнашу урынын уйлап сайлау гамәлдәге челтәрләргә тоташу чыгымнарын киметү мөмкинлеге бирә.

Фото: www.prav.tatarstan.ru

ЭНЕРГИЯНЕ НӘТИҖӘЛЕ КУЛЛАНУ БЕРЕНЧЕ ЧИРАТТА

«СВЭЛ» Төркеме» АҖ лаеклы рәвештә Россиядә электр техникасы җиһазлары җитештерүчеләр арасында алдынгыларның берсе санала. Предприятие импортны алыштыру программасын гамәлгә куюга да саллы өлешен кертә. Модернизацияләү һәм энергияне сакчыл куллану буенча технологияләрне куллану СВЭЛ өчен төп өстенлекләр булып кала. Компания белгечләре уйлап чыгарган яңалыклар бүген үк предприятиеләрнең энергия өчен киткән чыгымнарын 45 процентка киметергә сәләтле җиһазлар чыгару мөмкинлеге бирә.

Республиканың 2030 елга кадәрге Стратегиясе кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә куела торган озак вакытлы программалар яңа предприятиеләр төзелешен һәм булганнарының тагын да югары мөмкинлекләргә ирешүен күздә тота. Шуңа бәйле энергия белән тәэмин ителешнең ышанычлы булуына таләпләрне арттыра, димәк ки, энергетика куәтләре төзлешеннән һәм аны яңартудан башка моңа ирешеп булмаячак, дигән сүз.

220 кВлы «Бигеш» подстанциясе төзелеше нефть эшкәртүче һәм нефть химиясе җитештерү комплекслары, Түбән Кама җылылык-энергия үзәге, автомобиль һәм тимер юллары, предприятиеләрнең инфраструктурасын тәэмин итүче инженерлык челтәрләре урнашкан Түбән Кама сәнәгать зонасындагы киңәя баручы «энергия территориясе» өчен кирәк. Электр энергиясен кулланучы яңа эре предприятиеләр дә барлыкка килә.

Татарстан Республикасы Түбән Кама районының электр белән тәэмин итүнең ышанычлылыгын күтәрүгә энергияне нәтиҗәле куллану мәсьәләләрендә төп партнер – «СВЭЛ» Төркеме дә үз өлешен кертә. 2014 елның октябрендә башланган «Бигеш» подстанциясе төзелеше өчен СВЭЛ энергияне нәтиҗәле куллану буенча җиһазларның тулы бер исемлеген тәкъдим итә. Аерым алганда, АТДЦТН-125000/220/110У1 тибындагы майга эшләүче, СВЭЛның ике көч трансформаторы. Әлеге җиһазның конструктив үзенчәлеге кулланылышта аны экономияле итә: заманча материаллар һәм технологияләр аркасында «бушка эшләүче» югалтулар ГОСТ таләпләреннән 40 проценттан артыгракка кимрәк.

Җиһазларның торышы мониторингының алдынгы системаларын куллану һәм югары сыйфатлы комплектлаучы детальләр трансформаторларның югары ышанычлылыгын тәэмин итә. Моннан тыш, объектка ТСЗ-630/10,5 УЗ тибындагы коры көч трансформаторлары һәм РТСТГ 10-630-0.25 У1 реакторы урнаштырылган. «Бигеш» подстанциясенә җиһазлар «СВЭЛ» Төркеменә керүче һәм Россиянең сәнәгать башкаласы – Екатеринбургта урнашкан өч заводта җитештерелгән: «СВЭЛ – Көчәнеш трансформаторлары», «СВЭЛ – РосЭнергоТранс» и «СВЭЛ – НИЗМК».

«Бигеш» подстанциясе өчен «СВЭЛ» Төркеме җиһазлары проектның башлангыч этабында ук «КЭР-Холдинг» компаниясе тарафыннан иң югары сыйфатлы көнбатыш электр техникасының үзебезнең илдә җитештерелгән аналогы буларак сайлап алына.

Челтәр компаниясе белән СВЭЛнең хезмәттәшлеге төзелүче станциягә җиһазлар эшләү белән генә чикләнми. Житештерүче компаниянең белгечләре турыдан-туры объектның үзендә җиһазлауларны монтажлау эшләрен башкаралар һәм персоналны трансформаторларны ничек итеп дөрес кулланырга өйрәтәләр.

«СВЭЛ» Төркеме өчен әлеге объект – Татарстанда гамәлгә ашырылган беренче генә проект түгел. Агымдагы елда СВЭЛның көчәнеш трансформаторлары республика территориясендә нефть чыгару, эшкәртү һәм сәнәгать объектларына урнаштырыла. Шулай ук күптән түгел генә СВЭЛның бөтен номенклатуралы продуктлары белән җиһазландырылган блоклы типтагы комплектлы трансформаторлы кече станцияләре кулланылышка тапшырылды.

– Безнең компаниянең Татарстан Республикасы белән тыгыз хезмәттәшлеге берничә ел дәвам итә, – ди «СВЭЛ» Төркеменең май трансформаторларын сату департаментының проект җитәкчесе Леонид Коган. – Безнең әлеге ныклы адымнар белән үсештә булган төбәк белән эшлекле мөнәсәбәтләр алга таба ныгыр гына, дип ышанабыз. Без Татарстан объектларына аерым җаваплылык белән карыйбыз һәм республиканың энергетика системасы үсешенә тагын да зуррак өлеш кертербез, дип өметләнәбез.

Реклама

PRESSA.RU

КИЛӘЧӘККӘ ОМТЫЛУЧЫ ЭНЕРГИЯ

1931 елда «Татэлектро» (аннан соң «Татэнерго») ТАССР Дәүләт электр станцияләренең район идарәсе учреждениесеннән башланып киткән Татарстан энергетика системасына – 85 ел! Шушы еллар дәвамында энергияне ташучы ышанычлы «транспорт» чарасы булып электрүткәргеч чыбыклары кала. Аларны проектлау һәм төзү белән бүген «Татэнергострой» Проект-төзелеш компаниясе шөгыльләнә.

2004 елның августыннан «Татэнергострой» ПТК ЖЧҖ «Челтәр компаниясе» ААҖнең генераль подрядчысы булып тора һәм төп эшләрен стратегик заказчының тугыз филиалында алып бара.

2014 ел башыннан «Татэнергострой» ПТК ЖЧҖнә Халит Гарифуллин җитәкчелек итә, ул шулай ук «Энергостройсервис» ЖЧҖнең җитәкчесе дә булып тора. Әлеге компания республика муниципалитетларының, «Татнефть» ГАҖнең, «Кызыл Шәрык» АҖнең, «Нефтегаз» СМПның, «Татех» Россия-Америка компаниясенең, «ТатРитекНефть» ГАҖнең заказларын үти.

Күрше төбәкләрдә дә эш табылып тора – Самара өлкәсендә «Самара-Нафта» ЯАҖ, «Санеко» ЯАҖ һәм «РИТЭК» ГАҖ объектларында эшләр башкарылган.

Җитәкче турында: Халит Мәхмүт улы Гарифуллин 1960 елның 11 гыйнварында Пермь өлкәсенең Кизел шәһәрендә туган. Мәктәпне Чистайда тәмамлый, хезмәт юлын 1977 елның июлендә сәгать заводында көйләүче булып башлый. Һава десанты гаскәрләрендә армия хезмәтен үтеп, эшен сәгать заводында дәвам иттерә: аппаратчы, җыючы, өлкән мастер, цех башлыгы урынбасары була. Мәскәү приборлар төзү техникумының кичке бүлеген тәмамлый. Унөч ел Чистай электр челтәрләренең матди-техник тәэминат бүлегенә җитәкчелек итә. 1999 елда «менеджмент» белгечлеге буенча КДУның икътисад факультетын тәмамлый. 2004 елда өр-яңадан «Энергостройсервис» ЖЧҖ компаниясен булдырып, аны төзелеш хезмәтләре күрсәтү базарында лидерлыкка алып чыга.

Ике компанияне бер башлангыч астына берләштеру аркасында, «Татэнергострой» ЖЧҖ үз ел эчендә энергетика буенча эшләрнең тулы комплексын үзләштерә.

– Ике предприятие дә 2004 елдан башлап «Челтәр компаниясе» ААҖ белән хезмәттәшлек итә, – дип аңлата Халит Мәхмүт улы. – Безнең белгечләр карамагында 0,4 тән 10 кВка кадәрге көчәнешкә ия электрүткәргеч чыбыкларын, 10нан 0,4 кВка кадәрге, ЛЭП 35-220 кВ комплектлы трансформатор подстанцияләрен, 35-220 кВлы подстанцияләрне техник яктан хезмәтләндерү, капиталь ремонтлау һәм төзү. Биналар һәм корылмалар төзү, аларга капиталь ремонт ясау, 35 кВка кадәрге көчәнешле электрүткәргеч һава һәм кабель чыбыкларын проектлау буенча тулаем бөтен төр эшләрне башкарабыз, эре габаритлы йөкләр ташу буенча хезмәтләр күрсәтәбез.

Предприятиеләр Иннополисны электр энергисе белән тәэмин итү өчен һавадан 40 чакрым озынлыкта 110 кВлы ике чылбырлы электрүткәргеч чыбык сузу эшендә дә катнашкан – Зөя елгасы аша узучы катлаулы участок булган. Яр Чаллыда синтетик сапфир җитештерү өчен электр энергиясе белән тәэмин итүче кабель чыбыклары төзелешен алып барган һәм аның җиһазларын монтажлаган, шулай ук Казанда «Салават күпере» торак комплексын электр энергиясе белән тәэмин итү өчен 10 кВлы кабель чыбыгы сузган.

Хәзерге вакытта «Татэнергострой» 220 киловольтка «Бигеш» подстанциясе төзелешен алып бара. Быел аны кулланылышка кертү Түбән Кама районын электр энергиясе белән тәэмин итүнең сыйфатын һәм ышанычлылыгын арттырачак, бу якын киләчәктә җитештерү күләмнәре шактый артырга тиешле нефть химиясе предприятиеләре өчен аеруча мөһим. Проектны тормышка ашыру өчен, «Челтәр компаниясе» үз хисабыннан өч миллиард сумга якын акча тоткан. ТР Министрлар Кабинеты каршындагы Икътисадый совет утырышында «Бигеш» подстанциясен кулланылышка кертүнең әһәмияте энегетика челтәре үсеше өчен, Татарстанның иң эреләрдән саналган «Бөгелмә» һәм «Киндери»

Реклама

кече станцияләре белән беррәттән аерып ассызыклап әйтелүе очраклы түгел иде.

Шундый ук киң масштаблы икенче бер проект – төзелеш эшләре 2017 елның ноябренә төгәлләнергә тиешле 220 киловольт көчәнешле «Щелоков – Үзәк» һавадан үтүче стратегик чыбыклары.

500 киловольтлы «Щелоков» подстанциясе күптән түгел генә «Алабуга» махсус икътисадый зонасында эшли башлаган иде. Кама кластеры куәтле генерацияләр – Түбән Кама ГЭСы, Зәй ГРЭСы, Яр Чаллы һәм Түбән Кама җылылык энергетика үзәкләре тупланган урын. Шуның өчен дә «Щелоков» подстанциясе – Үзәк (Казан) подстанциясе һава чыбыклары сузу эше башланган иде – ул республика башкаласының үсә баручы итыяҗларын өстәмә электр энергиясе белән тәэмин итү мөмкинлеге бирә.

Компаниягә өр-яңа технологияләрне кулланып эшләү хас. Һава чыбыклары сузганда, заказ бирүчеләр коммерция ягыннан югалтуларсыз эшләү мөмкинлеге бирә һәм электр энергиясе белән тәэмин итүнең ышанычлылыгын арттыра торган изоляцияле үткәргечләрне сайларга тырыша.

«Татэнергострой» белгечләрен «Niled» (Нилед) һәм «Ensto» (Энсто) технологияләре буенча эшләргә өйрәткән.

«Челтәр компаниясе» ААҖ үзенең эшендә «акыллы» челтәрләрне торган саен ешрак куллана: санлы

Компаниягә өр-яңа технологияләрне кулланып эшләү хас. Һава чыбыклары сузганда, заказ бирүчеләр коммерция ягыннан югалтуларсыз эшләү мөмкинлеге бирә һәм электр энергиясе белән тәэмин итүнең ышанычлылыгын арттыра торган изоляцияле үткәргечләрне сайларга тырыша.

подстанцияләр, бүлү челтәрләрен автоматлаштыру системалары. Мәсәлән, реклоузерлар – электрүткәргеч чыбыкларының аерым бер участокларын секцияләргә бүлгәли һәм, авария була калса, электрүткәргеч чыбыкларны автомат рәвештә аера торган җайланмалар. Авыллардагы еракка сузылган электрүткәргеч чыбыкларын подстанцияләрдә челтәрнең зыян килгән участокларын автомат рәвештә локальләштерү мөмкинлеге бирә торган элегаз аергычлары урнаштыру юлы белән модернизацияли.

Подрядчыга вакытлар узу белән тагын да арта баручы таләпләргә җавап бирергә кирәк.

Халит Мәхмүт улы техниканы яңартуга, хезмәткәрләрнең тиешле белемнәр алуына һәм эшкә рөхсәт ителүенә зур игътибар бирә.

Ел саен миллионнарча сумлык яңа махсус техника һәм җиһазлар сатып алына.

Компаниянең үзенең склад һәм җитештерү мәйданнары бар, 70 берәмлек техникасы булган автопаркка ия – алар теләсә кайсы һава торышы шартларында һәм җирлекнең теләсә кайсы рельефында эшли ала.

Хезмәткәрләр ел саен Ростехнадзорның Идел буе идарәсе Түбән Кама территориаль бүлегендә аттестация үтә. Электр техникасы буенча хезмәткәрләр «Лаборатор анализ һәм техник исәпләүләр үзәге» федераль дәүләт идарәсенең Татарстан бүлекчәсендә әзерлек үтә һәм аттестацияләнә. Җитештерү буенча хезмәткәрләр квалификациясен кадрлар әзерләүче «Энергетик» Идел буе төбәк үзәгендә күтәрә.

«Татарстан Республикасы төзүчеләре берлеге» төбәк коммерция нигезендә булмаган партнерлыгы үзкөйләнүче оешмасында әгъза булып тору компаниягә утыздан артыграк эш төрен башкару хокукы бирә. «Идел – Кама» архитекторлары һәм проектлаучылары берлеге» үзкөйләнүче оешмасына кереп проект эшләре башкару таныклыгын алалар. «ВолгаКамИзыскания» үзкөйләнүче оешмасына керү инженерлык-геодезия эшләре алып бару хокукы бирә. Электр җиһазларын сынау һәм кабызу-көйләү эшләре башкару хокукы булган электр лабораторияләре бар. Компаниянең эш сыйфаты ISO 9001 стандарты буенча сертификацияләнгән.

Нинди генә катлаулы энергетика объектларын да ерып чыккан эшчәнлек барышында «Татэнергострой» проект-төзелеш компаниясе ҖЧҖ һәм «Энергостройсервис» ҖЧҖ заказны төгәл вакытында һәм иң югары сыйфатлы итеп башкара торган ышанычлы подрядчы дигән дан алды. Алар белән озак елларга сузылган хезмәттәшлеккә төп заказчының биргән бәясе үк күп нәрсә турында сөйли: 2014 елда «Челтәр компаниясе» ААҖнең җитәкчесе Илшат Шәех улы Фәрдиев шәхсән үзе Халит Мәхмүт улы Гарифуллинга «РФ Төзүче даны» Мактау билгесен тапшырды.

PRESSA.RU

2015 елның апреле

2015 елның июне

«БИГЕШ»: ЫШАНЫЧЛЫЛЫК ҺӘМ ЗАМАНЧА ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

2015 елның ноябре

2015 елның ноябре

220 кВлы «Бигеш» подстанциясе – Кама аръягы предприятиеләрен ышанычлы рәвештә электр энергиясе белән тәэмин итүнең яңа үзәге. Аның төзелешендә «КЭР ХОЛДИНГ» идарәче компаниясе катнашты һәм «Гидроэлектромонтаж» ҖЧҖ белгечләре үз эшләрен тиешле югарылыкта башкарды.

2016 елның июле

Түбән Кама сәнәгать кластеры өчен әлеге станциянең әһәмиятен бәяләп бетерү мөмкин дә түгел. Бу төбәктә электр энергиясен күпләп кулланучылар саны яңгырдан соңгы гөмбәләр кебек арта бара. Соңгы елларда гына да биредә «ТАНЕКО» нефть эшкәртү заводлары комплексы кебек гигантлар, эре нефть химиясе җитештерүчеләре калкып чыкты, алдагы елларда да сәнәгать куәтләренең үсеше көтелә әле. Билгеле ки, кулланучыларны электр энергиясе белән тәэмин итүнең сыйфатын күтәрү һәм ышанычлылыгын арттыру – кичектергесез рәвештә хәл ителергә тиешле бурыч санала иде.

Шуның өчен дә узган елның җәендә «Гидроэлектромонтаж» белгечләре булачак станция урынында – Иштирәк авыл җирлеге территориясендәге Мартыш елгасы янында эшкә тотынды, ә «Челтәр компаниясе» ААҖнең җитәкчелеге процессны тизләтеп, 220 кВлы «Бигеш» подстанциясен 2016 елда ук кулланылышка кертергә дигән карар кабул итте. Гәрчә мондый объектны төзү өчен норматив буенча егерме ике ай вакыт кирәк булса да.

Шуңа карамастан, «Гидроэлектромонтаж» бурычны мөмкин булганча үрнәкле итеп үтәде: станция бер ел эчендә диярлек төзелеп бетте. Предприятиенең белгечләре бик зур эш башкарды, гәрчә шартлар бик уңай килеп тормаса да. Ә бит бүген 220 кВлы «Бигеш» подстанциясе торган урында элек япа-ялан кыр иде. Юллар да, электр энергиясе белән тәэмин итү челтәрләре дә, кирәкле коммуникацияләр дә юк иде.

Бер елдан аз гына артыграк вакыт эчендә «Гидроэлектромонтаж» белгечләре гомуми станция белән идарә итү пункты бинасы һәм ачык бүлгәләү җайланмалары төзеделәр, кирәк булган монтажлау, электр монтажлау һәм эшләтеп җибәрүкөйләү эшләре, шул исәптән ике автотрансформаторны монтажлау буенча эшләрнең тулы комплексын башкардылар. Август ахырына «Бигеш» подстанциясе заказчыга – «Челтәр компаниясе» ААҖнә тапшыру өчен тулысынча әзер иде.

– Инженерия күзлегеннән бик кызыклы объект булды ул. 220 кВлы «Бигеш» подстанциясе – яңа буын станция, андыйлар Татарстанда нибары дүртәү генә, – дип сөйли «Гидроэлектромонтаж» ҖЧҖнең төзелеш буенча директоры урынбасары Руслан Ильясов. – Биредә электр энергиясе белән тәэмин итүнең диспетчер аша идарә итү системасы кулланылды. Ул, аерым алганда, электр энергиясен электр челтәрендә бүлгәләү процесслары белән идарә итүне тизләтә, авария очракларында кулланучыларны электр энергиясе белән тәэмин итүне торгызу вакытын кыскарту мөмкинлеге бирә.

Василий Глухов, «Гидроэлектромонтаж» ҖЧҖ директоры

220 кВлы «Бигеш» подстанциясенең тагын бер өстенлекле ягы бар. Проектка потенциал, ягъни резерв ячейкалары салып калдырылган. Бу исә киләчәктә челтәрләргә яңа кулланучыларны бернинди каршылыксыз кушу мөмкинлеге бирә. Алай гына да түгел, перспективалы үсешне исәпкә алып, өстәмә резерв ячейкаларына да урыннар калдырылган. Шул рәвешле станцияне чын мәгънәсендә территориянең икътисадый үсеш катализаторы дип атарга да була.

Руслан Ильясов сүзләренә караганда, 220 кВлы «Бигеш» подстанциясендә эшләр август уртасына тәгәлләнгән, объект көчәнеш астында инде. Сентябрьдә аны «ТАИФ-НК» ААҖнең авыр калдыкларны тирән эшкәртү комплексына кушу планлаштырыла.

220 кВлы «Бигеш» подстанциясенә энергияне нәтиҗәле итеп кулланучы һәм югары технологияле җиһазлар урнаштырылган. Биредә идарә итү процессын һәм җайланмаларның торышы мониторингын автоматлаштыру мөмкинлеге бирә торган заманча технологияләр кулланыла.

«Бигеш» подстанциясенә яңа юл

Реклама

«Бигеш» подстанциясе

Василий Желтухин, көйләү һәм сынаулар буенча әйдәп баручы инженер

ЯҢА ПОДСТАНЦИЯ – ЯҢА МӨМКИНЛЕКЛӘР

Кама аръягы предприятиеләренең электр энергиясенә булган ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен төзелгән «Бигеш» подстанциясе энергетика инфраструктурасында чираттагы объект кына түгел. Аны проектлауда һәм төзүдә иң алдынгы технологияләр һәм җиһазлар кулланылды. Күп яклары буенча уникаль саналган объектны эшкә кушу һәм көйләп җибәрүне «Наладка ГЭМ» ҖЧҖ белгечләре искиткеч төгәллек белән башкарып чыктылар.

Электр энергиясе белән тәэмин итүне диспетчер аша башкаруның заманча системасы, электр җиһазларын зур toklardan һәм көч килүдән саклау өчен микропроцессор җайланмалары, 125 МВА куәтле автотрансформаторлар, 220 кВлы ачык бүлгәләү җайланмаларының җиде ячейкасының электр җиһазлары һәм 110 кВлы ике ячейка… Бу «Наладка ГЭМ» ҖЧҖ белгечләре кыска вакыт аралыгында «эшләргә өйрәтергә» тиешле җиһазларның һәм системаларның бер өлеше генә әле. Хәер, компания коллективының мондый катлаулы бурычларны беренче генә хәл итүе түгел – Татарстанда һәм аннан читтә бик күп энергетика объектларын көйләү-кабызу эшләре алар кулыннан үткән.

«Бигеш» подстанциясе җиһазларын көйләү өчен компания белгечләре көн таләпләренә җавап бирүче приборлар һәм җайланмалар кулланган. Аерым алганда, РЕТОМ 21,51,61, миллиомметр МИКО-8 программалы-техник үлчәгеч комплекслар, РЕТОМ 6000 электр ныклыгын һәм изоляция каршылыгын үлчәү җайланмасы, СКАТ-70 М югары вольтлы сынау аппараты.

Шулай да иң заманча приборлар да – эшнең бер өлеше генә әле. Уңыш яисә уңышсызлык беренче чиратта кадрлар, аларның квалификациясе, тәҗрибәсе, осталык дәрәҗәсеннән тора. Бу җәһәттән «Наладка ГЭМ» – үрнәк коллектив. Биредәге кадрларның әзерлегенә, белемнәренә көнләшерлек. «Бигеш» подстанциясен көйләү-эшләтеп җибәрүдә турыдан-туры катнашкан командага килгәндә, аларны иң яхшылар арасыннан сайлап алганнар. Гаять мөһим объектны эшләтеп җибәрү, көйләү белән Василий Желтухинның җитәкчелек итүен әйтү дә җитә.

Василий Иванович – компаниянең ветераны, көйләү һәм сынаулар буенча әйдәп баручы инженер. Аның хезмәт тәҗрибәсе Татарстанның электр энергетикасында эшләгән еллар һәм белем-күнекмәләрдән торган тәҗрибә белән исәпләнә. Аның һәм иптәшләренең һөнәри осталыгы «Бигеш» подстанциясен эшләтеп җибәргәндә бик кирәк булды. Алга куелган бурычны сыйфатлы итеп үтәү бер нәрсә, вакыт та кыса – куелган вакытка өлгерергә кирәк иде (норматив буенча мондый корылма егерме ике ай эчендә төзелергә тиеш, бер ел эчендә төзелде **– ред. иск.**).

Ахыр чиктә һөнәр осталарыннан торган команданың бер сүздә булып эшләвенең нәтиҗәсе уңай булды – объектны билгеләнгән вакытка кулланылышка тапшырдылар. «Наладка ГЭМ» компаниясенең белгечләре эшләрнең аерым бер этапларын Германиядән кайтартылган электр җиһазлары тәэминат вәкилләре белән берлектә башкаруын да билгеләп китик. Немец хезмәттәшләре беравыздан Татарстан көйләүчеләренең әзерлек дәрәҗәсен, эш барышында дөрес, еш кына гадәти булмаган карарлар кабул итүләрен мактап телгә алганнар.

Реклама

ЭЛЕК

ХӘЗЕР

БӘХЕТ КҮЛЕ ӨСТЕНДӘГЕ МАЯК

Лениногорскида «бәхет күле» пәйда булды – аның ярлары заманча эшләнгән, комлыгы бик чиста, күзәтү мәйданчыклары, уен зоналары һәм хәтта чып-чын маягы да бар.

ЭЛЕК ҺӘМ ХӘЗЕР

Халыкта бу оҗмахка тиң мәдәният һәм ял почмагын «Түбән күл» дип йөртәләр. Әмма 5 августта, яңартылган яр буйларын тантаналы ачу көнендә, ТР Премьер-министры Илдар Халиков, искиткеч манзара белән хозурланып, аны матуррак исем белән атады:

– Президентыбыз Рөстәм Нургали улы Миңнехановның һәм шәхсән үз исемемнән бу сокландыргыч гүзәллекне тудырган кешеләргә рәхмәт әйтәсем килә. Бу сулык чыннан да «бәхет күле» булып чыккан.

Аңлатып китик: Лениногорск үзәгендә буалар каскады да, яр буе да элек үк бар иде. Әмма шәһәрнең «визит карточкасы» саналырга тиешле җирләрнең күренеше бер дә күзне иркәләрлек булмаган: яртылаш җимерелгән боек тротуарлар, җиһазландырылмаган комлык, күзәтү мәйданчыклары һәм суга төшү урыннары юк... ТР Президенты игълан иткән Сулыкларны саклау елы чып-чын революцион үзгәрешләргә этәргеч биргән.



Барысы да Лениногорскиның баш архитекторы Алексей Карасев эшләгән проекттан башлана. Тикшерү процессында гражданнар аңа берничә тәкъдим кертә. Бары шуннан соң гына Лениногорскида идеяне гамәлгә кертүгә керешәләр. Иң мөһименнән башлыйлар – сулыкның төбен пычрак һәм ләмнән чистарталар, ярларына бик чиста елга комы сибәләр һәм табигый ташлар белән ныгыталар.

«Бәхет күлен» буш урында гына төзеп булмый. Мөгаен, шуңадыр, проект авторы элегрәк буаның бизәге булган элементларга аеруча сак карый. Мәсәлән, Никах сарае янындагы төсле мозаикадан җыелган сигезаяк, крокодил һәм кит сыннарын сакларга карар кылалар. Тузган фигураларны реставрацияләләр, ә менә алар янындагы территорияне тулысынча үзгәртәләр. Биредә ике зур диңгез йолдызы формасындагы балалар мәйданчыгы пәйда була, аларны вакланган резинадан җәяләр. Мәйданчык үзәгендә – коры ут-динамика фонтаны. Шәһәр халкы йөрәгенә якын күптәнге скульптуралар янәшәсенә яңалары да – һәркемгә таныш мультфильм персонажлары куела.

Никах сарае янындагы күзәтү мәйданчыгы да танымаслык булып үзгәргән. Хәзер ул нәрсәсе беләндер шәһәр һәм күлгә бик матур күренеш ачылган лайнер палубасын хәтерләтә. Урта террасада хәзер күлгә карап торган җәйге кафе урнашкан, нәкъ кафе каршында – пирс. Биредә көймә һәм катамараннарны прокатка алырга мөмкин булачак. Төп күзәтү мәйданчыгыннан тыш, шәһәрнең яр буенда Набережная урамы ягыннан тагын икесе пәйда булган.

Яр буеның түбәнге баскычы буенча исә сәйран кылып йөрергә яратучылар өчен уңайлы юл салынган. Билгеле инде, су һәм кояш процедураларын яратучыларны да онытмаганнар: бик чиста елга комлы, ятаклар һәм кояштан саклаучы чатырлар куелган пляж балалар мәйданчыгы янәшәсендә урнашкан. Саф һавада спорт белән шөгыльләнүне бар нәрсәдән өстенрәк күргәннәрнең исә үзләренең яраткан урыны бар. Пляждан ерак түгел – воркаут өчен мәйданчык, тренажерлар, волейбол уйнау урыны.

Хәзер яр буенда шәһәр бәйрәмнәре үткәрү, концертлар кую, кинолар күрсәтү урыны да бар – махсус шуның өчен амфитеатр төзелгән.

Лениногорск яр буеның төп бизәкләреннән берсе исә – маяк. Шәһәр халкы күптән үз иткән, әллә кайчангы. Шул ук та, шул да түгел. Дөресен әйткәндә, лениногорскиларның берничә буынына таныш бу корылманы өр-яңадан төзегәннәр. Маякның нигезен таш белән матурайтканнар. Карау бүлмәсе булган өске өлешен сүтеп, аның урынына яңасын куйганнар. Хәзер бәхет күленә юлны теләсә нинди һавада, хәтта төнлә дә табып була – маяк яктысы һәрвакыт төгәл юнәлешне күрсәтәчәк.

Реклама

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

«Чүл патшасы» орденны **НИНДИ** казанышлары өчен алган

«Кече ватан патриотлары» Туфан Миңнуллинның туган көнен **НИЧЕК** билгеләп үтте

Ташкент пәхләвәсен **КЕМНӘР** тәмле итеп пешерә

PRESSA.RU

Владимир Чагин – КАМАЗ-мастер командасының легендар пилоты, күпсанлы ралли-марафоннар призёры, шул исәптән «Дакар» супермарафонында йөк машиналары классында җиде тапкыр җиңүче. Россиянең атказанган спорт мастеры. Россиянең атказанган тренеры. Спорт карьерасын төгәлләгәннән соң, 2012 елдан – «КАМАЗ-Автоспорт» ФП директоры, «КАМАЗ-мастер» командасы җитәкчесе. Батырлык, Дан, IV дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлар өчен» орденнары кавалеры. Татарстанның иң югары бүләге – «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены белән бүләкләнгән.

ЧҮЛ ПАТШАСЫ КОМАНДАСЫ

«Дакар» супермарофонында җиде тапкыр җиңүче булган Владимир Чагинга күптән инде «Чүл патшасы» дигән исем ябышып калды. Раллиның бөтен тарихы дәвамында абсолют рекорд куеп, ул пилот карьерасын төгәлләде, әмма пьедесталдан китмәде: бүген аның җитәкчелегендәге «КАМАЗ-мастер» командасы катлаулылыгы буенча тиңе булмаган трансконтиненталь узышта призлы урыннар алуын дәвам итә.

КИРЕБЕТКӘННЕ БУЙСЫНДЫРУ

Бу «Дакар-2003» иде, без чүл буйлап 160 км/сәгать тизлектә «очабыз». Бер-беребезнең күз уңында – Tatra, DAF… Кинәт шартлаган тавыш – безнең алгы тәгәрмәчебез шартлады. Машинаны ике йөз метрлап читкә бәрде, анда-монда чайкый башлады… Мин шуны гына уйлап өлгердем: хәзер һавада әйләндерә башласа, ким дигәндә, уннан да аз булмас. Ничек тәгәрмәчтә калып булгандыр – белмим. Машинадан чыксак, сул тәгәрмәчтән берни дә калмаганын күрдек. Хәтта покрышкасы да. Уңы да шартлау дәрәҗәсендә. Икесен дә алыштырдык һәм ары киттек… Ул чакта раллины ота алдык. Алдында җиңәргә дигән максат тора икән, мөмкинлекләрнең чигендә хәрәкәт итәсең – үзеңнең һәм автомобилеңнең. Һәм монда акылыңны югалтмау мөһим – синең белән кабинада тагын ике кеше булуын онытмаска кирәк. Ә бит «Дакар»да фаҗигаләр булгалады, раллиның бөтен тарихында җитмешкә якын кеше һәлак булды.

«Дакар»да беренче тапкыр рульгә 1991 елда утырырга туры килде. Мин ул чакта «тиз йөрешле техничка» экипажының механигы идем. Узышның кызган чагында пилотыбыз Евгений Доронин кулын сындырды – ком чүлендә машинаның руле эштән чыкты. Кагыйдә буенча экипаж әгъзаларын алыштырырга ярамый. Мондый очракта дистанциядән чыгарга яки, рольләрне бер-береңә күчереп, узышны дәвам итәргә тырышырга була. Икенчесен сайладык. Миңа

ул чакта егерме генә яшь, һәм чиктән тыш дулкынланам. Мөгаен, минем өстемә ишелеп төшкән ул җаваплылык тавы үземдә ниндидер яшерен резервларны эзләп табарга булышкандыр. Без финишка җитеп кенә калмадык, йөзгә якын катнашучы автомобильләр арасында уникенче урынны алдык. Ул елда «КАМАЗ-мастер» спортчылары беренче тапкыр Дакар подиумына күтәрелделәр – икенче һәм өченче урыннар безнеке иде. Мин үземнең билгеләнүне тагын дүрт ел көттем әле, пилот булу хыялы белән яшәдем. Һәм менә безнең команда җитәкчесе Семён Семёнович Якубов миңа пилот урынын ышанып тапшыра, ә үзе экипажга штурман булып утыра! Ул чакта безнең механик Сергей Савостин иде. Шул составта без «Дакар»ның биш раллиен оттык. Ә Сергей белән – җидене.

КАМАЗ БАЛАЛАРЫ

Күптән түгел мин раллида үзебезнең көндәш булган MAN командасы җитәкчесе белән очраштым. Сүзебез пилотларга барып тоташты. «Әлбәттә, сездә бик тә көчле егетләр. Сәләтле, булдыклы, көчле узышчылар!» – ди ул. «Ә сезгә нәрсә комачаулый? – дип сорыйм. – Алыгыз бүген мәктәптән чыккан бер малайны, шөгыльләнегез аның белән, ә ун елдан аның «Дакар»да җиңәргә бөтен мөмкинлеге булачак». Әлбәттә, бу зур хезмәт, әмма без үзебез өчен нәкъ шул юлны сайладык. Ник «сатып алынган» уенчылардан команда тупларга, безнең республикада талантлы яшьләр шундый күп бит! Сәләтле егетләрне эзлибез, үзебезгә чакырабыз. Әйе, аларның тәҗрибәсе юк, әмма иң мөһиме – эшләргә теләкләре, дәртләре, үсәргә омтылышлары, тыңлый белүләре бар... Әнә шундыйлардан үз эшләренә бирелгән кешеләр, җиңәргә сәләтле чын спортчылар килеп чыга да инде. Безнең бөтен пилотларыбыз да – Чаллы картодромында үскән малайлар. Бүген алар халыкара ярышларда класс күрсәтә.

ТАГЫН «ИКЕЛЕ»!

Күптән түгел миңа дусларым ВАЗ-2102 бүләк итте. Ак «икеле» – күңелгә якын тавышы балачакның якты хатирәләрен уята. Беренче тапкыр мин рульгә алты яшемдә утырган идем. Аякларым әле педальгә җитми, әмма әти инде мине зур түземлелек белән машина йөртергә өйрәтә. Табигатькә чыккан саен, ул моңа вакыт таба иде, һәм аның өчен мин аңа бик тә рәхмәтле.

Бөтенсоюз комсомол төзелешенә килгән чакта миңа бер генә яшь булган. Без Кама буендагы вагонда яшәгәнбез, плотина янында әти-әниләр яңа автозавод төзегән. Әти гомере буе КАМАЗда эшләде, үз язмышымны сайлаганда, мин дә анда-монда чайкалмадым. Балачакта ук хыялым булуыннан мин бик канәгать. Ул тормышка ашты. Узышчы булырга, иң югары титулларга ирешергә – мин моңа җиде яшемнән үк килдем. Югыйсә, тормышымда икенче кызыксынуым да бар иде: урта мәктәптә хоккей белән бик җитди мавыгып киттем. Көн дә уйныйм, аның тарихын өйрәнә идем – бөтен командаларны, танылган хоккейчыларның биографияләрен белдем... Мин бүген дә бозга чыгам һәм үзебезнең «Ак Барс» командасы өчен ихластан җан атам. Шулай да ул вакытта, балачагымда, мине автомобиль «каны» җиңүе бик яхшы булган.

«ТАТАРСТАН, КАМАЗ. БЕЛӘБЕЗ!»

Безнең команда оешканда аны беркем дә КАМАЗны «таныту инструменты» буларак кабул итмәде. Чөнки үз эшебездә нинди нәтиҗәләргә ирешәчәгебезне беркем дә күз алдына китерми иде. Бу 1988 ел иде. Безне – «Дакар» раллиена бару хыялы белән янган унлап кешене – КАМАЗ фәнни-техник үзәге директоры Семён Семёнович Якубов җыеп алды. Мин беренче энтузиастлар төркеменә эләгүемә бик шат. Ул вакыт эчендә без үзебез конкурент техника булдырырга, аның белән идарә итәргә, марафон дистанцияләрен үтәргә, командада эшләргә өйрәндек.

Беренче тапкыр Европага чыккан чакларыбыз хәтердә. Ул чакта КАМАЗ турында беркем дә ишетмәгән диярлек, «ка-м-а-з» сүзен көчкә тел әйләндереп әйтәләр иде. Әмма елдан-ел, безнең һәр җиңүебез саен, аны ешрак кабатларга керештеләр: «О! Татарстан! КАМАЗ. Беләбез!» Һичшиксез, бу заводка гына уңыш китереп калмады, республиканы да танытты. Бу үзең шөгыльләнгән эштән чын канәгатьләнү алырга мөмкинлек бирә. Бүген планетаның иң ерак почмакларында да безнең хакта сөйлиләр. Бу брендка танылу китерә, бөтен планетада Татарстан автомобильләрен сатып алучылар табарга мөмкинлек бирә.

Әмма безнең эшебезнең тагын бер нәтиҗәсе бар әле: спорт машиналарында кулланыла һәм ярышларда үзләрен яхшы яктан күрсәтә, соңыннан серияле автомобильләрдә дә уңышлы кулланыла торган техник эшкәртмәләр, яңа конструкторлык табышлары ул. «Дакар» шартларында сынатмаганны, «сериядә» алар тотрыклы һәм мәңгелек булачак.

«ДАКАР»НЫҢ БӨТЕН ПОДИУМЫ

Пилот карьерасын төгәлләргә җыенуым турында старт алдыннан мин беркемгә дә әйтмәдем – әле «Дакар-2011»не үтәсе бар иде. Ул вакытка безнең яшь егетләр күнегү җыеннарында, Россия чемпионаты этапларында яхшы нәтиҗәләр күрсәтә башлаган иде инде. Әмма алда Мәрдиев, Кәбиров, Чагин булганда, командада икенче яки өченче булу – беренче булудан нык аерыла. Нәтиҗәнең синнән торуы, бөтен ышаныч синдә булуны аңлау – шулай гына җиңәргә өйрәнеп була. Мин үзем моны 1999 елда, командадан Виктор Московских (Дакарның 1996 елдагы җиңүчесе) киткәч аңладым. Һәм 2011 елда миңа, тизрәк үссеннәр өчен, юлны яшьләргә бирергә кирәк иде.

Минем карарыма беренче мөнәсәбәт тискәре булды. Әмма командадан түгел, пилот урыныннан гына китүемә ышандырдым. Тәҗрибәм бар – аны тапшырачакмын. Тырышып шөгыльләндек: егетләргә төрле траекторияләрдә ничек йөрергә, чокырларны ничек узарга иканен өйрәтәм, узыш тактикасын, стратегиясен ничек төзергә кирәклеген аңлатам. 2012 ел узышларында, кызганычка каршы, җиңелдек. Ә инде бер елдан соң безнең егетләр «Дакар»ның бөтен подиумын яулады.

ПИЛОТМЫ? КОНСТРУКТОР!

Телевизордан сез раллины ике генә атна күрәсез. Ә безнең өчен «Дакар» – ел буена сузылган эш. Егетләр һичшиксез автомобильне эшләү һәм әзерләүдә, аны җитештерүдә, сынауларда катнаша. Аларның күбесе фәнни-техник үзәктә шөгыльләнгән. Бу машинаның конструкциясен бик яхшы белергә, аның техник мөмкинлекләреннән максималь файдаланырга, аңа сакчыл карарга мөмкинлек бирә. Минемчә, бу «КАМАЗ-мастер»ның булуында һәм безнең уңышларга ирешүебездә бик мөһим аспект. Әлбәттә, охшаш схемада эшләүче командалар бар, әмма төп дөнья практикасында пилотлар үз әзерлекләре белән генә шөгыльләнә, ә ярышларда инде әзер спорт автомобильләренә утыра.

2014 ел ахырында евро курсы ике тапкырга диярлек арткач, «КАМАЗ-мастер»да финанс кыенлыклары башланды. Техниканы камилләштерү, дөнья автоҗитештерүчеләренең яңалыкларына тест үткәрү, ниндидер яңалыклар уйлап табу һәм иң яхшы карарларга килү – болар барысы да акча таләп итә. Икенче бәла инде быел тез астына китереп сукты – безнең партнёр Тышкы икътисадый банк бөтен спорт юнәлешләренә, шул исәптән безнең командага да спонсорлык ярдәме күрсәтүдән туктады. Бәхеткә, «Ефәк юлы» раллие алдыннан гына «Ростех» дәүләт корпорациясе белән килешүгә кул куя алдык. Әлбәттә, бу тулы күләмдә финанслауны хәл итмәде, шулай да сулыш алу бераз җиңеләйде. Финанслауны торгызу мәсьәләсе әлегәчә ачык кала. Кызганыч, ел башында уйланылганнарның күбесен эшли алмадык, әмма без «Дакар»га әзерләнәбез һәм җанатарларыбызның кәефен төшермәбез, дип өметләнәбез.

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены белән ТР дәүләтчелеген үстерүдә, гражданнарның хокукларын һәм азатлыгын тәэмин итүдә, икътисад, мәдәният, фән, мәгариф, сәламәтлек саклау, сәнгать һәм спортны үстерүдәге зур казанышлар, шулай ук җәмәгать тәртибен саклауда күрсәткән кыюлык һәм батырлык өчен бүләкләнәләр. Әлеге билге 925нче пробалы көмештән эшләнгән.

Ольга Туманская
әзерләде

«ГОМЕРЕҢ ОЗЫН, КАРТЛЫГЫҢ КЫСКА БУЛСЫН»

«Әлдермештән Әлмәндәр» спектакле чагылыш тапкан почмак

Күренекле драматург, прозаик һәм җәмәгать эшлеклесе Туфан Миңнуллинның кече ватаны – Кама Тамагы районы Олы Мәрәтхуҗа авылында. Хәер, туган якны олысына яки кечесенә бүлеп тә булмый торгандыр, Мәрәтхуҗа – әдипнең бердәнбер ватаны.

Автор:
Линар Закиров

«ҖАНЫ КАЙТМАДЫМЫ ИКӘН?»

– Бу арбаны Туфан Миңнулинның дачасыннан алып кайттылар. Ул шунда кереп ятып, илһамланам, дип әйтә торган иде, – дип, әдипнең Кама Тамагы бистәсендәге музейның ишегалдына керә-керешкә сөйли башлады районның туган якны өйрәнү музее директоры Рәсимә Идиятова.

Туфан Миңнуллин ике катлы агач корылманы салуда үзе башлап йөргән: беренче катын – музей, ә икенчесен иҗат йорты итеп күзаллаган. Йортны 2009 елда сала башлаганнар. Экспонатларның күбесен әдип үзе китергән: монда аның кулъязмаларыннан башлап кесә телефоны белән джинс курткасына кадәр бар. Йорт эченә кергәч, бер мәлгә нарат исенә исердек.

– Туфан абый олпат гәүдәсе белән шушында кереп: «Эх-х, агач исе-е-е!» – дип горурланып әйтер иде. Йортны елга ике тапкыр юабыз. Тәрәзәне ачып куйсаң, тирә-якка агач исе тарала. Кайбер кешеләр авылда үсеп, шәһәргә китә дә икенче төрлегә әйләнә. Ә Туфан абый үзгәрмәде – җаны-тәне белән авыл кешесе булып калды, – диде Рәсимә Идиятова.

Бер почмакта легендар «Әлдермештән Әлмәндәр» спектакленнән фотокүренеш һәм Туфан Миңнуллинның хатыны Нәҗибә Ихсанованың Өммияне уйнаган күлмәге тора. Г. Камал театры аны вакытлыча гына биреп торган. Сораганнары юк әле, бәлки, үзебезгә дә калыр, дип өметен белдерде әңгәмәдәшебез.

– Музейга нигез салынганнан соң, Туфан абый язылып беткән ручкаларын җыя башлады. Йорт төзелеп беткәнчегә кадәр, алар 46 данәгә җитте. Туфан абый: «Машинкада басарга яратмыйм, миңа каләм белән кәгазь генә булсын», – дия иде. Шуңа да карамастан, биредә аның текст басу җайланмасы да урын алды, – дип, витринага ымлады Рәсимә ханым.

Габдулла Тукай, Муса Җәлил исемендәге премияләргә ия булган, халык язучысы исемен алган Туфан Миңнуллин 2012 елның 2 маенда якты дөньядан китеп барды. Музей шул елны аның туган көнендә – 25 августында ачылды.

– 28 апрель көнне, үләренә берничә көн кала ул, монда кереп, эшләнеп бетмәгән эшләрне барлап чыкты. Вафатыннан соң дача йортыннан бергә аның агач караваты, көзгесе һәм журнал өстәле кайтарылды, – дип сөйләде әңгәмәдәшебез. Игътибар белән карасак, караватта ир башы сурәтләнгән. Без аны Тукайга охшаттык. Музей хезмәткәрләре дә шул ук фикердә.

Икенче катка менәбез. Диварда драматургның әсәрләре буенча куелган дистәләгән спектакль афишасы эленгән. Г. Камал театры

Луиза Шарова фотолары

Айрат абый, Салават һәм «Туфан» чишмәсе.

ел саен Мәрәтхуҗага кайтып, авыл халкына бушлай спектакль күрсәтә. Ә дүрт ел элек Туфан Миңнуллин исеме бирелгән Түбән Кама театры шулай ук ел да август ахырында Кама Тамагы авыллары буйлап атна буена гастрольгә чыга.

– Монда, икенче катта, зур телевизорыбыз бар, балалар белән ачык дәресләр үткәргәндә, Туфан Миңнуллин спектакльләрен карыйбыз. Музейда мәктәп укучылары үзләрен экскурсовод буларак та сыный. Нинди генә сорау бирсәң дә, Туфан абый авызыңа каратып, тәмләп сөйләр иде. Зур кеше булса да, аның белән сөйләшкәндә бернинди тартыну юк иде. Аңардан җан азыгын күп ала идек, – дип сөйләде Рәсимә Идиятова.

Былтыр Туфан Миңнуллинның 80 яшьлек юбилеена музейга язучылар, артистлар кайткан. Шулчак каяндыр сары песи килеп чыккан да әдипнең агач караватына менеп яткан.

– Мин барам да мәчене сүрәп, чыгарып җибәрәм. Ул тагын керә. Бу хәл ике-өч мәртәбә кабатланды. Аннан соң бер өлкәнрәк апа: «Туктале, җаны кайтмадымы икән?» – диде. Әллә нишләп киттем – бүтән орынмадым. Кеше чыгып китмичә, песи караваттан төшмәде. Бик гаҗәпсендек, – диде әңгәмәдәшебез.

«КЕЧКЕНӘ АВЫЛ ДА ГӨРЛӘП ЯШИ АЛА»

Кама Тамагы белән Олы Мәрәтхуҗаны 15 минутлык юл аерып тора. Биредә 80гә якын кеше яши. Чат саен Туфан Миңнуллин музей-йортының кайда урнашканын искәртә торган юл күрсәткечләре беркетелгән. Безне клуб директоры Айрат Кадыйров һәм аның улы Салават каршы алды.

– Туфан абыйның үзе салган авыл ызбасы бу. Ул җәй көне безнең кебек егетләрне җыеп, чәйләр эчертеп, киңәшләрен бирә, шушында кайтып яза да иде, – дип сөйли башлады Айрат әфәнде.

Ишегалдында бер тамырдан үсеп чыккан ике каенга күзебез төште.

– Туфан абый аны махсус утыртмаган, каен идән астыннан үзе тишелеп чыккан, диләр. Килгән һәр кеше аның янында фотога төшә. Йорт каршындагы алмагачларны да, баланнарны да язу_ чы үзе утыртты. Соңгы вакытта йөрәге җәфалагач, Туфан абый балан суы эчә иде, – дип аңлатты әңгәмәдәшебез.

Әдип йортны төзеп кенә калмыйча, мичен дә үзе чыгарган, диләр. Өй эчендәге зур шкаф киштәләрендә китаплар тезелгән.

– Мин 90нчы елларда армиядән кайттым. Авылда йорт салган чагыбыз. Төзелеш материаллары алырга акча җитми. Нишләргә? Төнге унбердә акча сорарга Туфан абыйга киттем, ни дисәң дә, хәлле кеше иде бит ул. Тәрәзәне чиерттем. Хатыным: «Нишләп шулай итәсең? Туфан абый сезгә генә Туфан абый. Ул бит зур кеше», – дип шелтә белдерде. Язучы тәрәзәсен ачты да, егетләр мине клубка алырга килгән икән әле, диде. Мин инде шул вакыттан бирле клуб мөдире булып эшлим. «Ни йомыш?» – диде ул. «Стропиллар алырга акча җитми», – дим. «Бер үк төзелешне туктата күрмә. Йорт салу бер туктаса, эшләр харап. Күпме кирәк?» – дип сорады да кирәкле сумманы бирде, – дип сөйләде Айрат Кадыйров.

Бу йортта ел саен, авыл халкын җыеп, аш уздыралар. Уң яктарак Туфан Миңнуллинның туган нигезе янында кирпечтән төзелгән кечкенә йорт тора. Мәрәтхуҗада мәктәп юк. Белем йорты ачарга кирәк, дип йөри торгач, ахыр чиктә, әдип туган нигезендәге йортны башлангыч мәктәп итеп файдалануга биргән. Янәшәдә тагын бер корылма – язучының 60 яшьлегенә бүләк ителгән йорт калкып тора. Өч ел элек, янгын чыгып, туган нигезенең дә, бүләкле йортның да диварлары гына утырып калган. «Кызыл әтәч»нең каян килеп чыкканын ачыклый алмаганнар.

Туган туфрак салынган капчык.

PRESSA.RU



Былтыр республиканың элемтә оешмасы әдипнең йортларын төзекләндерү эшенә алынган: эчен дә, тышын да буяганнар, коймаларны алыштырганнар, музей-йорттагы мичне аклаганнар, җылыткычлар урнаштырганнар.

Мәктәп бетерелсә дә, бүген шул бинада авыл халкыннан җыелган борынгы көнкүреш җиһазлары һәм Туфан Миңнуллин иҗатына кагылышлы экспонатлар саклана.

Эчкә кергәч, уң якта – магнитофон, аннан әдипнең вафаты алдыннан ясаган соңгы чыгышы яңгырый. Диварда – күкеле сәгать, экспонатны язучының күршесе – аның белән бер елны туган Дания апа бүләк иткән.

– Ә монысы – капчыкка тутырылган Мәрәтхуҗа туфрагы. Авылыбыздан Ринат исемле егет армиягә китеп, Эстониядә хезмәт итте. Туган якны сагынам дигәч, колхоз председателе аңа авыл туфрагын алып барды. Ринат туфрак белән бергә туган ягына исән-имин генә кайтып җитте. Аның энекәше дә армиягә үзе белән Мәрәтхуҗа туфрагын алып барып, хәвеф-хәтәрсез генә хезмәт итеп бетерде. Әниләре шуны гомер буе саклап, музеебызга тапшырды, – диде Айрат Кадыйров.

Аның олы улы Айнур да, кечкенәсе Салават та башлангыч белемне шушында алган.

– Абыем 1993 елда туган. Ул укучы булган чакта мәктәптә 13 бала белем ала иде. Ничек укыганыгызны күрсәтегез әле, дип берсендә мин дә аңа ияреп бардым. Ул вакытта почмакта мич тора, бинаны утын ягып җылыталар иде, – дип хатирәләргә бирелеп алды 10нчы класста укучы Салават.

– Баланың белем дәрәҗәсе мәктәпнең зур яки кечкенә булуыннан тормый. Авыл белән дә шулай ук. Тотып тора торган, юньле кеше булмаса, зур сала да бетәргә мөмкин, дия иде Туфан абый. Күршедәге авылда кеше күп яшәсә дә, алар безнең Мәрәтхуҗадан көнләшә: сездә гел спектакль-концерт куялар, музейга да кеше килә, диләр. Кечкенә авылда да матур итеп яшәргә мөмкин. Чишмә өстендә авыл бәйрәмнәре уздырабыз, – дип сөйләде клуб мөдире.

ТОРНАЛАР КАЙТКАН ҖИРДӘ

Мәрәтхуҗада Романовлар династиясенең Россия белән идарә итүенә 300 ел тулу уңаеннан чишмә ясалган була. Әдипнең 70 яшьлегенә аны яңартып, шундагы корылмага «Туфан 70» дип язып куялар. Еллар узу белән, чишмә ташландык хәлгә килә, киң күңелле хәйрияче – югарыда телгә алынган элемтә оешмасы аны тулысынча яңарта. Безнең районда күз явын алырлык андый чишмә бүтән юк, ди авыл халкы. Янәшәдә күл дә җәйрәп ята. Без килгәндә анда бер көтү каз каңгылдашып йөзә һәм өч торна утыра иде.

– Карале, торналарның монда күптән күренгәне юк иде. Чишмә суы нык кимегән, күле дә пычранып беткән иде. Тирә-якны тәртипкә китергәч, торналар да кайткан икән, – дип тел шартлатты Айрат әфәнде.

«Туфан» чишмәсенә килгән берәүнең дә сихәтле судан авыз итми киткәне юк дигәч, без дә күркәм гадәтне бозмаска булдык.

КЫЧЫТКАН АРАСЫНДАГЫ СПЕКТАКЛЬ

Туфан Миңнуллинның кече ватанында аның берничә туганы яши, шуларның берсе – Динә Ганиева – әдипнең туганнан туганының хатыны.

– Дүртенче класста укыганда кызамык белән авырый идем. Шул килеш мәктәпкә баргач, Туфанның: «Мин синең авырганыңны беләм, күз төпләрең каралган», – дип әйткәне хәтеремдә, – дип көлә Динә апа.

Ул 1953 елда Казанга китеп, 1959 елда кияүгә чыга. Мәскәүнең Щепкин училищесыннан укып кайткан Туфан белән Нәҗибә Динә апаларда еш кунак була.

– Кыстыбый әзерләсәк тә, бәлеш пешерсәк тә, аларга алып бара идек. Мәскәүдән кайткач, Туфаннарның акчасы юк иде. Тулай торактагы кызлар акчаларын безгә куеп тора иде. Кызларның акчалары юкмы, дип Туфан кызы Әлфия белән бергә килә иде. Без аңа биреп тора, ул вакытында кайтара иде. Туфан авылдан алып кайткан бәрәңгене промбазадагы туганнарының базына сала иде. Кышын аны шуннан өенә чана белән алып кайта. «Ник такси алмыйсың?», дисәң, «Миңа бәрәңгене бушка алып килделәр. Базадан такси түләп алып кайту – кызык түгел бит», дия иде.

Аның безгә булышкан чаклары күп булды. Берсендә бакча алдык та, ә «Запорожец» юнәтергә акча җитми. Туфан биреп торам, диде. «Акчаны, ваклап, Альбертка (Т. Миңнуллинның энесе – **авт.**) кайтарырсыз», диде, – дип хатирәләре белән бүлеште әңгәмәдәшебез.

1991 елда Динә апа пенсиягә чыгып, ире белән авылга кайта.

– Бу – Туфанның әнисенең туган нигезе. Мин монда килен булып төштем, шуннан бирле нигезне саклап торам, – диде ул.

Әңгәмәдәшебез сөйләвенчә, Туфан абый үз әсәре буенча куелган һәр премьера спектакленә бөтен туганнарын җыеп алып бара торган булган. Камал артистлары да, Мәрәтхуҗага кайтып, халыкның күңелен күргән.

Луиза Шарова фотолары



Динә апа һәм Салават.

– Элек авылыбыз клубы бик кечкенә иде (Мәрәтхуҗада хәзер республика программасы буенча төзелгән өр-яңа мәдәният сарае балкып тора **– авт.**). Шуңа да, сәхнә, эскәмияләр корып, артистлар спектакльләрне ачык һавада күрсәтә иде. «Гөргөри кияүләрен» куярга килгәч, артистлар тамаша залына төшеп уйнады, ә халык сәхнәгә менеп карады. Шагыйрь Гәрәй Рәхим: «Камал артистларының кычыткан арасында спектакль куйганнары юк иде әле», дип көлдерде, – диде Динә апа.

– Туфан абый нәрсә ашарга ярата иде? – дип, икенче бер өлкәдән сорау бирдем әңгәмәдәшемә.

– Бервакыт авылда чакта Нәҗибә, пилмән пешереп, безне дә чакырды. Ул, Туфан, ничә пилмән ашыйсың, дип сорады. Миңа 33 җитә, ди тегесе. Аннары оныгы Даниярдан сорады. Ул, дәү әти 33не ашагач, миңа да 33не инде, дигәч, барыбыз да көлештек. Туфан талымсыз иде. «Берәүнең дә токмачы Нәҗибәнекенә җитми. Кешенеке нәзек, минем теш арасыннан йөри, ә Нәҗибәнекен рәхәтләнеп чәйнисең», – дип әйтә иде.

Динә апа сөйләвенчә, Туфан абый якты дөнья белән хушлашкач, аның туган нигезе дә көлгә әйләнгәч, Мәрәтхуҗа моңсуланып калган. Кемгә барып сыенырга белмичә, югалып калдык, ди.

– Авылдагы ут баганаларын алыштыру, газ кертү, күпер салдыруда Туфанның өлеше әйтеп бетергесез зур булды. Аның аркасында гына кеше булып калдык.

ЯКЫННАРЫ ИСТӘЛЕГЕННӘН

Мәңге яшь булып калучы

– 2012 елның 28 апрелендә иртәнге якта Туфан абый районга кайтты. Көне буе табигатькә хозурланып, озак сөйләштек. Бик күп китаплар алып кайтты, монысын – музейга, монысын мәктәпкә тапшырырсыз, диде.

Кич кайтырга уйлагач, бездән озак аерыла алмады. Машина кузгалып киткәч, яңадан артка биреп: «Безнең авыл егете Рамил Сәлимовка фермерлык эшен җайга салу өчен җирне рәсмиләштерүдә ярдәм итегез әле. Булдыклы егет», – диде. Бу аның соңгы кайтуы иде.

Туфан абыйның яратып әйтә торган теләге: «Гомерең озын, картлыгың кыска булсын!» Аның картлыгы булмады да, ул безнең күңелләрдә яшь булып калыр.

Зөфәр Гарәфиев,
Кама Тамагы районының
элеккеге башлыгы.

Каймак ашаучы

Әнисе Халисә апа бервакыт каймакны базга төшереп куя. Моны белеп, Туфан базга төшә. Каймактан авыз итә дә аның өстенә оста итеп мәче тәпие эзен төшерә. Көннәрдән бер көнне Халисә апа кызы Өммиягә: «Баздагы каймакка мәче тигән, әрәм иткән» дип, өстен сыпырып алган да кызына «Чирканмасаң, аша» дигән. Өммия апа: «Юк, ашый алмыйм, мәчедән бик җирәнәм» дигән. Моны тыңлап торган Туфан: «Бир, әни, мин чирканмыйм» дип, каймактан тагын бер кат авыз иткән.

Күршесе Дания апа.

Битарафлыктан уятучы

Гаиләбезгә тетрәндергеч фаҗига килгәннән соң да, күңелем үзеннән-үзе Туфан абый әсәрләренә тартылды, чөнки анда йөрәккә юаныч табасың, аның белән сөйләшәсең, киңәш сорыйсың. Менә шундый тирән фикерле олуг затны югалттык. Бу югалту һәр милли җанлы татар кешесенә авыр булды, чөнки Туфан абый, Тукай әйтмешли, коеп куйган язучы гына түгел, бәлки, татарның алтын баганасы, безне битарафлыктан уятучы иде.

Миләүшә Галәвиева,
пенсионер укытучы.

PRESSA.RU

«ТАТАРСТАН»
МАХСУС
журналы өчен
Журнал
ТАТАРСТАН
Редакционная Кухня

Патшалар сые, ЯКИ ТАШКЕНТ ПӘХЛӘВӘСЕ

Без сезне һәр сан саен тәмледән-тәмле ризыклар белән таныштырып киләбез. Нинди генә сый юк безнең халыкта. Әмма бу юлы бераз экзотиграк ризык рецепты тәкъдим итәргә булдык. Әнвәрия апа һәм Рәҗия апа белән мине әнә шул экзотика таныштырды да инде. Сүз пәхләвә турында бара. Ташкенттан Казанга кунакка кайткан арада, Рәҗия апаны «тотып алып» пешертеп карамасак, гөнаһ булыр иде.

Автор:
Луиза Янсуар

Төрек кафеларында пәхләвәнең катлы-катлы камырдан пешерелгән вариантларын еш авыз итәбез, бу сый безнең өчен шактый традицион, үз булып әверелде инде. Ә менә Рәҗия апа пешергәне аларга охшамаган булып чыкты. Үзбәк пәхләвәсе үзенә бер төрле икән. «Ташкентта да пешерәләр үзе катлы камырдан, – ди Рәҗия апа, – әмма без менә шушындыена ияләшкән инде, сеңлем. Аны бездә «патшалар сые» дип йөртәләр».

Озын-озакка сузмыйча, патша сыен бергәләп әзерләргә керештек. Мин, әлбәттә, фотоаппаратымны көйләп, ә Рәҗия апа белән Әнвәрия апа – билләренә алъяпкыч буып һәм кулларын онга манып...

«КҮК КҮКРӘМӘГӘН ҖИРДӘ ЯШӘСӘМ ИДЕ...»

– 1966нчы елда Биләр районында әнине калдырып, Үзбәкстанга киттем, – дип башлады сүзен Рәҗия апа. – 70нче елга кадәр анда эшләдем. Олы апабыз шунда яши иде. Аны күрергә дип кенә бардым да калдым. Кечкенәдән күк күкрәүләрдән курка идем, кайда күк күкрәми, шунда яшәргә китәр идем, дигән ниятем бар иде. Барсам Үзбәкстанга, күк тә күкрәми, бездәге кебек дөбер-шатыр килгән яңгырлар да юк, җитмәсә, кыш та – яз шикелле килеп кенә китә. Бик әйбәт булды бу миңа, дип уйладым.

Дөрес, мин анда барган 66нчы ел үзе җир тетрәгән ел булган икән. Авыл җирендә телевизорлар юк диярлек иде бит ул чакта, без аны белми дә калганбыз инде. Миңа Үзбәкстанда әйтәләр: «Нигә монда килдең, күк күкрәмәсә, җир селкенде монда яхшы гына», – диләр. Менә шулай, һәр яхшылыкның бер яманы була дөньяда. Бер нәрсә дә идеаль гына булып бетми.

Рәҗия апа эшен эшләгән арада Ташкентта ничек бөтенләйгә калу тарихына да күчә. Ара-тирә аны төзәткәләп, һәр мәсьәләгә ачыклык кертеп, һәр детальне җөпләп, апаларча, сүзгә Әнвәрия апа кушылгалый. Гомумән, алар икесе бер организмның дәвамы кебек. Юкса, ут белән су диярсең, капма-каршылык үзләрендә – Әнвәрия апа җегетләрчә нык, кискен, кырыс, җитез, тынгысыз, ә Рәҗия апа – йомшак, сабыр, ягымлы, тыныч...

– 70нче елда Ташкентта кияүгә чыктым, – дип сөйләп китә Рәҗия апа. – Шунда туып-үскән Хәмзә исемле татар егетенә. Ташкент дигәч тә, без шәһәрнең үзәгендә түгел, ә аның читендәге Урта Чирчек районында яшәдек. Мин шунда бухгалтер булып эшләдем. Хәмзәнең апасы минем белән бергә эшли иде. Хәмзә аның янына Ташкенттан килеп йөри инде. Менә шулай таныштык. Ул миңа тәкъдим ясагач, юк, кайтып китәм, анда әнием ялгыз кала, дигән идем, бу утырып елады. Аны кызганып чыктым инде, сеңлем. Шунда кистереп әйтте дә Хәмзәм: безнең йортлар «под снос» эләгә, безгә яңа йорт бирәчәкләр, йорт биргәч, әниеңне монда яныбызга алдырачакбыз. Шулай иттек тә. Кечкенә кыз булгач, әнине мин карарга тиеш, дип киртләп куйган идем үземә. Дөнья булгач, апа белән икебез төрле якта яшәдек – аны эшкә распределение буенча Питрәч районына җибәргәннәр, мин – Ташкентта...

Ул арада, терекөмеш кебек, һич тиктормас Әнвәрия апа тел шартлата:

– Кара, Рәҗия, санап утырам, син киткәнгә октябрьдә 50 ел тула икән бит! Кай арада үткән дә киткән соң бу гомер?!

БӘРӘН БУЛМАСА, СУЫТКЫЧ, ЙӘ ГАРНИТУР!

Ишеткәнем бар: үзбәк туйларына бөтен шәһәр диярлек җыела. Урамның буеннан-буена өстәл сузып, үткән-сүткәннең барысын чакырып, урам тулы бала-чаганы сыйлый-сыйлый, атна буе бәйрәм итәбез, дип сөйләгән иде шуннан кайткан танышларым. Мин әле ул чакта көлгән идем: нәкъ безнең керәшен туйларыдай икән, дип.

Рәҗия апа да бу сүзне җөпләде. Әмма үз туйлары күпкә тыйнаграк булган икән.

– И, ул чакта андый купшы туйлар юк иде әле ул, сеңлем, – дип, ирен читләре белән генә елмайды ул. – Әйбере дә юк иде бит аның. Хәзер, әнә, зурдан кубып, рестораннарда гына уздыралар мәҗлесләрне.

Ул арада Әнвәрия апа сүзгә кушыла:

– Алай димә! Үзбәкстанда туйны урамда уздыралар иде бит теге вакытларда, җылы бит анда, кыш булмый диярлек. Син әйтмешли, сеңлем, үткән-сүткән халык, килеп ашамаса да, тамаша кылып китә. Ә инде туган-тумача, күрше-күлән өерелеп килә. Һәркем үзеннән өлеш тә чыгара, сый-нигъмәтсез килми... Анда бит җыр-биюләр бик матур...

– Йолалар, гореф-гадәтләр буенча аерма зурмы? – дип кызыксынам.

– Бар бераз, – ди, Рәҗия апа. – Анда кыз биргән кешегә бик читен, ул кызга өстәмә бирнә – калым да бирергә тиеш. Элегрәк бәрән биреп, йорт кирәк-яраклары, әйтик, сервант, шифоньер, келәм һ.б. белән котылсалар, хәзер инде телевизор, суыткыч ише бүләкләрсез булмый. Кайбер кайнаналар Ташкент гарнитурларына гына да риза түгел хәзер, импортныйга гына! Гает җиттеме, башка бәйрәмме – кыз ягы буш кул белән бара алмый...

Фотолар: Луиза Янсуар

PRESSA.RU

ПӘХЛӘВӘ ӨЧЕН КИРӘК:
1. 1 табага – 250 г маргарин
2. 2 ярым стакан – он
3. 4 йомырка
4. 300 г – әстерхан чикләвеге
5. 150 г – йөзем яки өрек
6. Шикәр комы яки пудрасы – стакан, стакан ярым
7. Куертылган сөт – чама белән

«КАЛАЙЛАРЫГЫЗНЫ ГЫНА МАЙЛАП ТОРЫЙМ ӘЛЕ...»

Ул арада камырны икегә аерып, целлофан пакетларга салып, суыткычка алып куйдык та, йомырка агын туглап, безе ясарга керештек.

Мин Рәҗия апа килен булып төшкән йорт, андагы традицияләр турында сораштырырга керештем.

– Килен булып төшкәндә, бернәрсә дә пешерә белми идем, – дип көлеп җибәрде Рәҗия апа. – Әмма кайнанам Әшрәфҗамал аш-суга гаҗәеп оста кеше иде, аннан өйрәндем. Берсендә килендәшем Гөлсинә белән пәрәмәч пешерергә булдык... Шуны да әйтеп үтим әле: аның белән бергә 40 елдан артык чөкердәшеп яшибез, Ходайның биргәненә шөкер. Бергә эшләдек, гомер буена безне «апа-сеңел» дип йөрттеләр. Килендәшләр мондый булмый, туганнар гына шулай якын була ала, диләр иде. Әле бер мәртәбә дә орышышканыбыз, сүзгә килгәнебез юк, күз генә тимәсен! (Бу урында Әнвәрия апа: «Бөгелмә ягыннан аның килендәше», – дип җөпләп куярга өлгерә).

– Әй, сүзем бит пәрәмәч турында иде... – дип, дәвам итә Рәҗия апа. – Боздык без бу пәрәмәчне! Кайнанабыз әйтә: «Йөрмәгез, үзем пешерәм», – ди. Гөлсинә: «Ярар, без пешкәнне ашарбыз», – диде. Ә минем бит үҗәтлегем үзенекен куймый, өйрәнәсе килә. Бөтереләм инде әнкәй тирәсендә: «Әни, – дим, сез пешергәндә, калайларыгызны гына булса да майлап торыйм әле...» «Ярар, майлап тор», – диде. Шулай итә-итә өйрәндем менә. Аннары кайнанам: «Әй, Рәҗия, пәрәмәч пешерүдә миннән дә остаргансың икән», – дип мактый иде.

ПЫЛАУ – ПЫЛАУ ГЫНА ТҮГЕЛ

Кош теле, чәкчәк пешергәндә, Термездан килгән туганыбыз бик күп нәрсәгә өйрәтте. Эченә шикәр комы салмаска куша иде, алай итсәң, камыр катып китә, дип. Өстенә генә сибәргә куша иде...

Пәхләвәне әзерләргә күршедәге үзбәк килененнән өйрәндек. Ул балалар бакчасында эшли иде. Мин аларга, үз чиратымда, эремчектән ризык пешерергә өйрәттем. Шулай итеп, Гаетләргә хәзер дә матур итеп ризык пешереп, бер-беребезне сыйлашып йөрибез, шөкер.

– Ә үзбәкләр пәхләвәне еш пешерәме? – дип төпченәм.

– Юк, – ди Рәҗия апа. – Ул гомер-гомергә кунак сые исәпләнә, Гаеткә пешерәбез, туйларга. Аның кирәк-яраклары күп бит. Менә бер елны чикләвек булмады, өрек-йөземгә кытлык чаклар да булгалады. Ә базардан сатып ала башласаң – кыйбат. Без йортның аскы катында яшибез, каршыбызда кечкенә генә бакча бар. Шунда үстерәбез барысын да. Иске шәһәрдә яшәдек башта, аннары Юнысабад дигән җирдә йорт бирделәр, инде 42 ел шунда яшибез.

– Өрекне тәрәзәдән үрелеп өзеп алып кына ашыйбыз, кунакка баргач, – дип мактанып алырга өлгерә Әнвәрия апа.

– Ә үзбәк йортында иң еш пешерелә торган ризык нинди? – дип сорыйм алардан.

– Самсаны гел пешерәләр, – ди Рәҗия апа. – Ул шул бездәге пилмән кебек инде. Бавырсакны еш әзерлиләр. Пәрәмәчне, коймакларны үзбәкләр элек әзерләми иделәр, бездән өйрәнделәр. Алар, беләсез инде, пылау осталары бит. Һәр атна кичне, әрвахлар килә дип, йортта пылау әзерлиләр. Анда йортта мәет булса, урамга, подъезд алдына эскәмияләр чыгарып куялар, иртәнге намаздан кайтучы ир-атлар, белгәннәрме бу кешене, юкмы, эскәмиягә утырып, рухына дога укып китә. Хатыннар өйгә кереп укып чыгалар.

Шулай сөйләшә-сөйләшә, Үзбәкстандагы татар диаспорасы турында да сүз чыкты. Баксаң, аларда татар бәйрәмнәрен зурдан кубып уздыралар икән. Сабантуйларны – бигрәк тә. Һәр елны Татарстаннан кем дә булса бәйрәмгә килә, ди.

– Үзебездәгеләр дә бик оста, – ди Рәҗия апа. – «Брановские бабушки» кебек, безнекеләр, җыелышып, «Татарские бабушки» дигән ансамбль оештырырга йөриләр әле менә...

ИКЕ ҮЗБӘК СӨЙЛӘШСӘ...

– Үзбәкләр гаҗәеп кунакчыл, кешелекле халык, – ди Рәҗия апа. – Гомер иттем Ташкентта, килмешәк итеп хис иткән бер генә көнем дә булмады үземне, – ди ул.

– Ә телне ничек өйрәндегез соң? – дим.

– Безнең телләр якын ич, кызым, – дип элдереп ала Әнвәрия апа, – кирәк булгач, башыңа төшкәч, ничек өйрәнмисең инде! Тырыш кешегә тел өйрәнү – нәрсә ул!

– Анда тел бик төрле, – ди Рәҗия апа. – Ташкент сөйләше бер, Сәмәркандныкы – икенче. Фирганә сөйләше – тагын өченче. Ике үзбәк сөйләшкәндә тыңлап торсаң, кайчак аңлый да алмыйсың...

Сүзгә Әнвәрия апаның кызы Миләүшә апа кушыла:

– Анда барганда, гаҗәпләнеп кайтам, – ди ул. – Ташкенттагы татарлар рәхәтләнеп үзбәкчә сөйләшә, үз татар телләрен онытмыйлар, ә Татарстан эчендә яшәүче, бигрәк тә Казандагы татарлар, рус мохитендә яшибез дип, татарчасын белми башлый.

– Ул, кызым, – дип кызып китә Әнвәрия апа, – телнең кирәк булмавыннан килә. Ничек ул үзбәкчә сөйләшмәсен, яши алмый ич ул анда юкса. Ә бездә татарча белмәсәң дә яшәп була...

Тел дискуссиясенә ноктаны Рәҗия апа куя:

– Шулайдыр, сеңлем, – ди ул сабыр гына елмаеп, – оныгым Самир дүртенче класска барды быел, мәктәптә русча укый, үзбәк малайлары белән урамда теттереп үзбәкчә сөйләшә, өйгә керүгә, татарчага күчә. Киявебез дә, киленем дә татарлар, шөкер. Төрле телдә сөйләшкәнгә карап, үзебезнеке онытылмый, анысы безнең үзебездән тора лабаса...

ПӘХЛӘВӘ ЯНЫНА – ЮМОР ҺӘМ ШИГЫРЬ!

Ул арада пәхләвәбез пешеп өлгерде дә, сүзебезне өстәл артында, чәй янында дәвам иттек. Авызда эреп торган баллы-татлы телемнәр янына Гамил Афзалның сатирик шигырьләре дә өстәлде. Өстәл артында беренчелекне үз кулына инде Әнвәрия апа алды. Һушы китеп шигырь ярата икән бу гомере буена фельдшер булып эшләгән апа.

Менә шулай бер Питрәч районында яшәп, бер-беребезне очратып белмәгән булсак та, пәхләвә безне берләштерде. Ә инде янына юмор белән шигырь дә өстәлгәч, күңелләр бөтенләй эреде.

– Фельдшер-акушер белеме алып чыккач, мине шушы Питрәч районына билгеләделәр, – дип сөйләп китте Әнвәрия апа. – Без гомумән ул чакта бөтен төркемебез белән Караганда өлкәсенә барабыз, дип сорап язган идек. Бунтарьлар, имеш! Татарстанга билгеләделәр шулай да, медицина хезмәткәрләре монда кирәк, диделәр. Бу 63нче ел иде. Миңа Шихазда авылы председателе әйтә район үзәгендә: «Ни уйлап барасың ул «глухомань»га, анда радио да юк, телевизор турында әйтәсе дә юк, әйдә, үзебезгә!» Юк инде, мин бит алай итә алмыйм, мин бит «честный народ»!

Анда киткәнче, мине медицина хезмәткәре булып эшләгән бер әбигә керттеләр. 30нчы март бу, буранлы, салкын. Моның өенә керерлек түгел, кар күмеп киткән. Карларын көрәдем, юлларны ачтым. Өе үзе аптека да икән. Иртән уянгач та, кырып-себереп чистарттым бу «аптек өйне». Аннары киномеханик малайның чанасына утырып киттем Кибәк иленә.

1963нче елның 1нче апреленнән башлаган идем «службаны», 1998нче елда гына тәмамладым. Шунда Нуретдин исемле җегеткә кияүгә чыктым. Клубта танышканбыздыр инде. Килгән кеше ич мин, медработник җитмәсә. Ул чакта безгә акча да түлиләр, эшебез дә колхоз эше түгел, чиста эш. Почетта йөрибез. Клубка килгәч, хәтерлим әле, җегетләр сөйләшә үзара, миңа ишетелеп тора инде – «Мин озатам», – ди берсе. Икенчесе аңа: «Юк, мин озатам, миңа быел өйләнергә кирәк», – дип, тегеңә каршы төшә. Менә шул җегетләрнең берсенә чыктым да куйдым инде, сеңлем!

«АЛГА» ГАЗЕТАСЫНЫҢ ПОДШИВКАСЫ

Шуннан соң бөтен гомерен шушы Кибәк иле халкына хезмәт күрсәтеп уздырган Әнвәрия апа. Клуб сәхнәләрендә шигырьләр укып йөргән активист та ул. Районыбызда чыгып килә торган «Алга» газетасының подшивкасы диярсең үзен, миңа кайсы елда нәрсәләр басылганын чытырдатып санап чыкты. Аннары шигырьләр укыштык, бераз гына моңсуланып та алдык.

– Укый алмавыма үкендем гомер буе! Югары белем аласым килгән иде бик тә, эшләп ярдәм итәсем килде әнигә...

Шуннан Әнвәрия апа үз һөнәренең кызыкларын сөйләргә күчте. Мин тагын бик матур җырлый торган дәү әниемнең гомере буена консерваториядә укыйсы килүе турында үзәге өзелеп сөйләгәнен искә төшереп, тарих киндерәнә язылган язмышларның нинди охшаш та, нинди төрле дә булуына гаҗәпләнеп, тыңлап утырдым. Әбиемне исән чагында китап язарга өнди идем. Уйларымны укыгандай, Әнвәрия апа азакта болай дип куймасынмы:

– Авыл җирендә фельдшер булып эшләүнең, безнең өлешебезгә тигән михнәтләрнең дә, хикмәтләрнең дә ни икәнен белсә-ә-әң, сеңлем, бер китап язарлык!

P.S. Рәҗия апаны әтиемнең әнисе – Кибәч әбиемә охшатып гәпләшсәм, Әнвәрия апаны исә Янсуардагы дәү әниемә охшатып үз иттем булса кирәк. Шулай итеп, бер килүдә, инде мәрхүм әбиемнәрдән соң калган бушлыкны тутырып, юанып, рухланып кайттым бу очрашудан. Пәхләвә – пәхләвә генә түгел ул, белсәгез! Сез дә, әзерли калсагыз, чәегез янына иң кадерле кешеләрне җыегыз!

НИЧЕК ӘЗЕРЛИБЕЗ:

1. 250 г маргарин белән онны кушып, валчык ясыйбыз.
2. 4 йомырканың агыннан сарысын аерабыз. Агын башта алып куябыз – ул безе ясар өчен кирәк булачак.
3. Сарысын валчыкка кушабыз да үзле итеп камыр хәстәрлибез.
4. Камырны икегә бүләбез. Аскы өлеше өчен күбрәк калдырабыз.
5. Целлофан пакетларга төреп, аны суыткычка, иң яхшысы, катыра торган камерага куябыз.
6. Ул арада йомыркаңың агын, шикәр комы яки шикәр пудрасы кушып, миксер ярдәмендә болгатабыз. Безены шулай ук суыткычка куеп алсак әйбәт.
7. Табаны аз гына майлыйбыз да катып өлгергән камырны угычтан уып, зуррак кисәген табага җәеп салабыз.
8. Өстенә әстерхан чикләвеге, йөзем белән өрек тезеп чыгабыз.
9. Шулар өстенә тигез итеп безе ягабыз.
10. Безе өстенә калган камырны шулай ук угычтан уып таратабыз.
11. 25 минутка 180 градуслы духовкага урнаштырабыз.
12. Духовкадан алгач, өстенә куертылган сөт ягып, 10 минутка калдырабыз.

Чәйләрегез тәмле булсын!

PRESSA.RU

АЛАР ӨЧЕН БАР ДА – МӨМКИН!

Тынлык. Ату. Тынлык. Судья тавышы. Ату. Тынлык. Судья тавышы. Нерв җепселләре соң чиккәчә тартылган. Һава тып-тыгыз. Менә бу ичмасам эмоцияләр, менә бу ичмасам көрәш!

Автор:
Искәндәр Хәбибуллин

Ихластан әйтүем. Футбол, хоккей, баскетбол, волейбол ярышларында дәррәү кубып кычкырып, шаулап җан аткан трибуналарны монда күрү мөмкин түгел. Беренчедән, пуля белән ату вакытында спортчыларның психологик халәте бик мөһим роль уйный, аларга концентрацияне югалту һич тә ярамый. Икенчедән, монда чыгыш ясаучы спортчылар җанатарларның шау-шу килеп хуплавын барыбер ишетмәячәк. Инде ачыклык кертергә вакыт: 8-14 сентябрьдә Казанда начар ишетүчеләр һәм бөтенләй ишетмәүчеләр арасында пуля белән ату буенча дөнья чемпионаты булып узды.

ҺИНД КЫЗЛАРЫ САЛКЫННАН КУРКА

Яңгырлы, салкын сентябрь көннәре. Казандагы Мирный бистәсеннән ерак түгел урнашкан «Динамо» спорт базасының ату үзәгенә юл тотабыз. Ярышларның бер өлеше ярымачык тирда үткәрелгәннән соң, башка дисциплиналарда көч сынашу түбә астына, ябык ату залына күчте. Монда инде спортчыларга сәләтләрен, осталыкларын, психологик ныклыкларын күрсәтергә берни дә комачаулый алмый. Һиндстан командасы остазлары әйтүенчә, урамда үткәрелгән ярышлар вакытында спортчы кызлар бик туңган, салкыннан дер-дер калтырап, көчкә атканнар.

Беренче дөнья чемпионатының нәкъ менә Казанда уздырылуы – республика өчен зур уңыш һәм башкалабызның спорт, иҗтимагый чаралар оештыру өлкәсендәге дәрәҗәсен, абруен күрсәтә торган вакыйга.

Ату үзәгендә соңгы елларда зур спорт чараларында кагыйдә булып киткән саклык пунктлары каршы ала. Хәтта спортчыларны алып килгән автобусны ук озаклап, җиренә җиткереп, махсус минаэзләгеч белән тикшерәләр.

Без килеп кергәндә, хатын-кызлар арасында 10 метрдан пневматик мылтыктан ату буенча ярышлар бара иде. Сүземне залдагы тулы тынлык турында сөйләүдән башлаган идем бит. Атмосферага бераз күнеккәч, очколар санау системасына күз ияләшкәч, сөйкемле кызларның кайсы кем булуын ачыклап бетергәч, менә, ниһаять, ярышны дикъкать вә игътибар белән күзәтә башлыйсың. Башлана эмоцияләр! Кычкырып, кул чабып, шаулап булмаганлыктан, кызлар өчен ыграк та борчыласың әле. Берәрсенең мишень читенәрәк тидерүе була, бар халык арасында, җил искән кебек, «Э-э-һ...» дигән уфтану ишетелә. Борынгы ау алиһәсе Дианаӊы күргәннәрмени, ату кырыннан күзләрен дә алмыйлар. Хәер, без белмәгән-күрмәгән Диана белән чагыштырып булмый... Кызлар булсалар да, әнә ничек төз аталар. Ир-атлардан бер дә калышмыйлар!

Фото: Александр Эшкинин

КИЛДЕМ, КАРАДЫМ, ОШАДЫ, КАЛДЫМ

Кайвакыт, берәрсенең кулы калтырап куя шулай да – әз генә читкә тайпылдымы мылтык көпшәсе, көндәшләрең узалар да китәләр. Ниләр кичерә икән спортчы, нинди уйлар белән ярышка әзерләнә? Бу сорау белән чемпионатта тулы комплект медальләр яулаган Украина спортчысы, яңа гына дөнья чемпионы титулына ия булган Сергей Фоминга мөрәҗәгать иттек. Сергей, инде шактый тәҗрибәле спортчы булуына карамастан, чемпионат алдыннан бик нык дулкынланган икән.

– Биш яшьтә начар ишетә башладым. Башта гади мәктәптә укыдым, аннары начар ишетүче балалар өчен махсус мәктәпкә күчтем, ике ел анда белем алдым. Мәктәптә укыганда йөзү һәм җиңел атлетика белән шөгыльләндем. Соңыннан, техникум бетереп, бер предприятиегә эшкә урнаштым. Шунда эшләп йөргәндә, директорыбыз янына пуля белән ату буенча тренер килеп, ату белән шөгыльләнергә теләүче яшь егетләрегез юкмы, дип, кызыктырып китте. Килдем, карадым, ошады, калдым.

Башта эш белән ату параллель рәвештә барды, тик 2011 елгы Европа чемпионатына эштән җибәрмәгәч (шундый яхшы цех мастерын кем инде Европа чемпионатына җибәрә ди! **– авт.**), предприятиедән китеп, ярышларга бардым. Ярты еллап беркайда да эшләмәдем, кыенга туры килде, билгеле. Шуннан ярты ставкага спортсмен-инструктор итеп эшкә кабул иттеләр мине. Узган Европа чемпионатына мин зур өметләр белән килмәгән идем болай үзе, көч сынау өчен генә. Һәм, көтмәгәндә-уйламаганда, беренче урынны яулап куйдым! Дөнья чемпионатына исә мин инде үземдә җиңәргә осталык, сәләт барлыгын белеп килдем, шуңа да психологик киеренкелек көчлерәк булды. Ярышлар да шактый катлаулы, авыр булды, ләкин, күрәсез, уңышка ирештек.

Тыйнак кына, тыенкы гына «уңыш» дип атады ул үзенең җиңүен. Аннары монда аларны берләштергән уртак чир турында сөйләргә керешә. Һәм, әйтергә кирәк, ул аның кимчелекләренә караганда, өстенлекләренә күбрәк басым ясады.

– Башкалар белән чагыштырганда, яхшырак ишеткәнгә күрә, мин үз командамда тәрҗемәче ролен дә башкарам – тренерларның әйткәннәрен спортчыларга җиткерәм, – дип сүзен дәвам итте Сергей. – Безне начар ишетүче балалар укый торган мәктәпләргә очрашуларга еш чакыралар. Йөзүчеләр, көрәшчеләр белән бергә йөрибез, балаларны спортка килергә өндибез, спорт ачкан киңлекләр, мөмкинлекләр турында сөйлибез. Балалар шактый күп килә, күбесе түзми, тиздән китә, әмма кайберләре секциядә кала, бик теләп, даими шөгыльләнә башлый. Көндәшләр шактый көчле иде, барысы белән дә танышуыма мин бик шат, шундый яхшы тәҗрибә һәм аралашу насыйп булды бу көннәрдә. Спортчылар белән социаль челтәрләрдә язышабыз, тренировкалардан фотолар җибәрешәбез, чит телләләре белән аралашуы кыенрак, чөнки халыкара ишарәләр телен мин начаррак беләм.

Казан бик ошады – чиста, пөхтә, матур ул. Кремльдә булдык, мәчетегезгә сокландык. Милли каһарманыгыз Му… Му… (бу урында аз гына сөрлегеп торды да көлеп җибәрде **– авт.**) Муса Җәлил турында кызыксынып тыңладык, шигырьләрен укырга кирәк, дигән фикергә килдем. Аның шигырьләре кешенең рухын ныгытадыр…

ЧИТ ИЛДӘ – ЧИКЛӘР ЮК

…Эһ, Сергей белән сөйләшеп торган арада безнең кызларыбыз төшеп калды: Дарья Булавина – сигезенче, Юлия Чурсина дүртенче урынны яуладылар. Трибуналар да минем белән бер көйләнештә: «Э-э-эһ…»

Ярый, болай да яхшы чыгыш ясадылар бит, 10 медаль, икесе – алтын. Россия – чемпион! Бәлки, остазлары башка фикердәдер, остазлар бит үз командаларының осталык дәрәҗәсен дә, әзерлек дәрәҗәсен дә безгә караганда яхшырак беләләр, дип уйлап кына бетергән идем, матбугат хезмәте җитәкчесе Азамат Мырзаев инде Россия җыелмасының өлкән тренерын яныма җитәкләп алып та килгән. Әллә уйларны укып йөри шунда?

Россия сурдлимпиада җыелмасының өлкән тренеры Сергей Михайлович Кривцов, инде бу чемпионаттагы традицияне дәвам итеп, башта оештыручыларны мактап китте:

– Беренче дөнья чемпионаты булуына карамастан, оештыру эшенең бернинди дә җитешсезлекләре булмады, барыбыз да ярышлардан бик канәгать калдык, проблемалар хакында әйтә алмыйм. Әлеге категория спортчылар өчен ярыш саннары шактый чикләнгән: Европа чемпионаты һәм Сурдлимпия уеннарыннан тыш, башка ярышлар юк. Бу дөнья чемпионатыннан соң берникадәр алга китү сизелер, дип уйлыйм.

Россия җыелмасының нәтиҗәләрен бәяләп, ул болай диде:

– Россия спортчыларының әзерлек дәрәҗәсен уңай бәяләр идем. Финалга барысы да диярлек үтте, медальләр өчен көрәштә дә бирешмәделәр. 10 медаль – бик яхшы күрсәткеч. Әлбәттә, алтыннары күбрәк булса, яхшырак булыр иде, димәк, алга таба эшләргә, тагын да җитдирәк максатлар куярга кирәк. Пуля белән ату – психологиягә бик нык бәйле спорт төре, кызганыч, аны бары күнегүләр ясап кына өйрәтеп булмый. Ярышлар кирәк, никадәр күбрәк булса, шулкадәр яхшы. Ярыш вакытындагы киеренкелек бөтенләй башка, тәҗрибә кирәк. Чит ил спортчыларына ул яктан җиңелрәк – чикләр юк, рәхәтләнеп бер илдән икенчесенә күчеп, ярышларда катнашалар, тулысынча сәламәт спортчылар белән ярышалар. Безнекеләргә ул яктан кыенрак, акча мәсьәләсе дә кысанрак. Халыкара ярышларда без ел әйләнәсендә катнаша алмыйбыз, әлеге дә баягы финансларга барып тоташа бу хәл. Спортчылар барысы да кайдадыр эшли бит, спорт белән генә шөгыльләнеп көн күреп, тамакны туйдырып булмый.

Без бик шат, алдагы Сурдлимпия уеннарына зур өмет баглыйбыз. Безнең кызларыбыз өчен монда килү – гомумән зур уңыш, алга таба яңа үрләр яулау өчен җитди әзерлек мәйданы. Оештыручылар бик тырышканнар: яхшы бүлмәләрдә яшәдек, ярыш шартлары да бик уңайлы. Көндәшләр дә бик хәерхаһлы, күп яңа дуслар таптык. Безнең өчен мондагы төп кыенлык – вегетариан ризыкның бик сирәк очравы. Кайда кермә, бөтен җирдә итле ризык. Гаеп итеп әйтү түгел, бу – мәдәниятләр, халыклар һәм алардагы традицияләрнең дә төрлелеге. Сәяхәт итү, яңа илләр күрү шуның белән кызыклы да – үз милли мәдәниятеңнән аермалы булган мәдәниятләр белән танышасың.

ВЕГАННАР ӨЧЕН – БРОНЗА

Ул арада ярышлар тәмамланды. Беренче урында – Украина, икенче урында – Сербия, өченчедә – Һиндстан. Менә сиңа мә, Европадан булмаган илгә тәтегән беренче медаль бар. Тизрәк ашыгыйк сенсацияле спортчы янына. Һиндстан кызы медальләр белән бүләкләнү тантанасына әзерләнә торган арада әлеге ил делегациясе белән таныша тордык. Делегациянең җитәкчесе Прахладрао Дешмукх Шарадрао әфәнде (Һиндстан командасының менеджеры буларак исемләнә ул халыкара спорт теленд**ә – авт.**) бронза медаль яулаган спортчы кызның әтисе дә икән әле. Күпләр кебек үк, ул да оештыручыларның сыйфатлы хезмәтен билгеләп үтте. Аннан милли мәдәниятләрнең аермасы турында сөйләүгә күчте, кызыклы бер фактны күзәткән булып чыкты һиндлы әфәнде.

– Һиндстанда ату белән шөгыльләнүчеләрнең гомуми саны алты меңнән артык, ә начар ишетүчеләр арасында ату белән шөгыльләнүчеләр – дүрт-биш кенә. Шуларның икесе – биредә. Икесе дә студентлар. Соңгы көндә бронза медаль яулаган кыз – Приеша Дешмукх – минем кызым. Һиндстаннан беренче тапкыр дөньяга чыгуы. Ату белән ул өч ел шөгыльләнә, һәм менә – шушындый уңыш.

АЛАР ГАДИ ТҮГЕЛЛӘР

Ярыш нәтиҗәләре буенча, инде әйткәнебезчә, Россия җыелмасы төрле дәрәҗәдәге 10 медаль яулады. Җиңүчеләребезнең исемнәре: Роман Кузьмин (2 көмеш, 1 бронза), Юлия Чурсина (алтын), Евдокия Каторгина (алтын), Валерия Кладовикова (2 көмеш), Ирина Борисова (көмеш), Ольга Мисоченко (бронза), Дарья Булавина (бронза).

Ябылу тантанасында ТР яшьләр эшләре һәм спорт министрының беренче урынбасары Хәлил Шәйхетдинов монда җыелган бар халыкка котлау сүзләрен юллады: «Бу беренче чемпионатның уңышлы тәмамлануы белән барыгызны да котларга рөхсәт итегез. Казанда әле сурдлимпиячеләр арасында шулкадәр югары дәрәҗәле ярышларның моңарчы булганы юк иде. Без Татарстанга мондый әһәмиятле халыкара ярышны оештырырга ышанып тапшыруларына чиксез рәхмәтлебез. Соңгысы булмас, дип өметләнеп калабыз. Үзләренең югары осталыкларын күрсәтеп, чын мәгънәсендә спорт көрәше белән безне куандырган спортчыларның ярышларын карау бик рәхәт булды».

Россиянең Сурдлимпия комитеты Президенты Александр Романцов оештырылу дәрәҗәсенең югары булуын билгеләп үтте.

Теләсә нинди спорт төренең асылы – ярыш, көндәшлек. Ләкин асылның асылы – көндәшлекне спорт мәйданында калдырып, гади тормышта дуслар, бер-береңне хөрмәт итә торган коллегалар булып калу.

Карап-карап торасың да, аптырыйсың. Гап-гади кешеләр. Мылтыктан, пистолеттан аталар. Күзләренә, үз-үзләрен тотышларына игътибар беләнрәк карыйсың – юк, гади түгелләр икән. Умырткалылар һәм искиткеч көчле рухлылар.

«КЕШЕНЕ ХӘСРӘТ ТӘРБИЯЛИ»

Сүз уңаеннан, умыртка баганасын имгәтеп, йөри алмый торган Россия сноубордчысы Алена Алехинаның сүзләре искә төшә. «Мин бер сәбәпсезгә депрессияләр белән «җәфаланучы» кешеләр өчен махсус аттракцион ясар идем. Үзем кебек, чыннан да авыр хәлгә юлыккан башка кешеләрнең ситуациясенә куеп торыр идем үзләрен берникадәр вакытка. Депрессияләренең, иң кимендә, берничә елга юкка чыгачагына һич шигем юк. Элеккеге кайгыруларымны миңа хәзер искә төшерү дә көлке. Эһ, ник шул вакытта күңелемне төшереп, борчылып йөрдем икән җыен вак-төяккә, дип тә еш уйлыйм. Һәр мизгелне шаулатып, гөрләтеп яшисе, һәр нәрсәдән тәм табасы калган икән! Кешене гади әйберләргә сөенергә, тормышның һәр минутыннан тәм табып яшәргә көчләп өйрәтеп булмый. Гадәттә, моңа адәм баласын хәсрәт өйрәтә. Хәсрәт тәрбияли. Ләкин сәламәт кешеләрне дә сәламәт ысуллар белән өйрәтеп карыйсы килә...»

Менә нәрсәдә сере бу спортчыларның. Алар, безнең кебек кошлар сайравын, музыка аһәңнәрен ишетә алмыйлар, башка кешеләр белән аралашу мөмкинлекләре дә чикле. Ләкин аларның йөрәкләрендә көрәш уты сүнми. Алар, бернигә карамастан, яраткан эшләре белән шөгыльләнеп, рәхәтләнеп яши беләләр. Безгә алардан гади генә нәкъ менә шул хакыйкатькә өйрәнергә була – яши белергә.



ТАРИХКА КҮЗ САЛЫП

Начар ишетүчеләр һәм бөтенләй ишетмәүчеләр өчен төрле ярышлар үткәрү дөнья тарихында XX гасырның 20нче елларыннан башлана. 1924 елда Франция башкаласы Парижда беренче җәйге Сурдлимпия уеннары үткәрелә. Аларда спортчылар җиңел атлетика, велосипед спорты, футбол, йөзү буенча көч сынаша. Беренче Кышкы уеннар 1949 елның гыйнвар аенда Австриядә уздырыла. Ярышларны оештыру вазыйфасы Халыкара комитетка (ICSD) йөкләнгән (1924 елның 16 августында оештырыла). Башлыча 10 вәкил-илдән генә торган бу оешма хәзерге көндә составына кергән 90нан артык милли федерация белән горурлана ала. Сурдлимпия һәм паралимпия спортларын берләштерү идеясе дә булган, ләкин ул уңышка ирешмәгән.

Пуля белән ату – беренче җәйге Сурдлимпия уеннары программасында да булган. Сурдлимпия уеннарына һәм ярышларга бары тик иң яхшы ишетә торган колагы да 55 децибелдан начаррак ишетә торган кешеләр генә кертелә. Әлеге ярыш кагыйдәләре гадәти ярышлардагы кебек үк.

Начар ишетүчеләр арасында пуля белән ату буенча Европа чемпионатлары 1967 елдан бирле уздырыла. Казанда 8-14 сентябрьдә узган дөнья чемпионаты – беренчесе. Казанда узачак чемпионат спортның әлеге төре тарихында дебют турниры булып торачак. ICSD һәм Россиянең Сурдлимпия комитеты тарафыннан уздырыла торган турнирда дөньяның 16 иленнән – Венгрия, Германия, Греция, Израиль, Һиндстан, Кипр, Кытай Тайбэй, Латвия, Монголия, Россия, Сербия, Украина, Финляндия, Чехия, Хорватия һәм Швейцария ир-ат һәм хатын-кыз командалары катнашты. Пневматик һәм кече калибрлы коралдан пуля белән ату ярышлары барышында 12 комплект медаль тапшырылды.

Беренче дөнья чемпионаты Казанның «Динамо» спорт базасының ату үзәгендә үтте. Дөнья чемпионаты киләсе елга Самсун шәһәрендә (Төркия) узачак XXIII җәйге Сурдлимпия уеннарына әзерлекнең хәлиткеч этабы буларак бәяләнә.

PRESSA.RU

Йолдызларга!

«Казан Гипронииавиапром» коллективы Казан федераль университетын, В.П. Энгельгардт исемендәге Астрономия обсерваториясе хезмәткәрләрен ачылуларына 115 ел тулган көн белән тәбрикли!

В.П.Энгельгардт исемендәге Астрономия обсерваториясе җитәкчелеге, галимнәре һәм белгечләре белән безгә бик кызыклы фәнни-белем бирү проекты – АСТРОПАРК төзү барышында якыннан аралашу, хезмәттәшлек итү бәхете тәтеде. Планетарийны проектлау ышанып тапшырылган безнең «Казан Гипронииавиапром» коллективы бу хезмәттәшлекне аеруча бер җылылык белән искә ала. Бу чын уртак иҗат чоры булды, ул безгә, галим-астрономнар ярдәмендә, архитектура проектлаштыруы өлкәсендә шактый кызыклы идеяләрне «ачу» һәм гамәлгә кертү мөмкинлеге бирде.

Шул ук вакытта безнең уртак табыш һәм ачышларыбыз буш урында гына пәйда булмады. Татарстан планетарие-ның уникаль проектын ясарга керешкәнче дөньяда мондый үзәкләрне төзү тәҗрибәсен җентекләп өйрәндек. Европага барып, Нюрнберг, Лион, Римдагы планетарийлар белән таныштык. Германиядәге заманча Астрономия үзәге каршындагы планетарийның яңа инновацион проектын төзү белән шөгыльләнүче галим-астрономнар, архитекторлар белән очраштык. Ә үзебезнең партнерларыбыз – В.П. Энгельгардт исемендәге Астрономия обсерваториясе галимнәреннән никадәр файдалы тәкъдим керде!

Обсерватория белгечләренең тәкъдимнәре безгә күп кенә нәтиҗәле һәм кызыклы техник чишелешләрне табарга булышты. Зал гөмбәзенең авышлыгы, астрономия машинасын сайлау, гөмбәз экранын тышлау өчен материаллар сайлап алу, тамаша залындагы һәм гөмбәзара пространстводагы кондиционерлар һәм вентиляцияләр системасын җайлау – болар барысы да коллектив иҗат, ике якның чын партнерлык мөнәсәбәтләре нәтиҗәләре.



В.П. Энгельгардт исемендәге Астрономия обсерваториясенең искиткеч коллективы белән аралашу һәм хезмәттәшлек итү кызыклы һәм уңышлы булды. Ул, ике як өчен дә файдалы булып, дәвам итәр, дип өметләнәбез. Без киләчәктә дә АСТРОПАРКны проектлауда катнашуыбызга шат булачакбыз. Әле күп кенә идеяләр кәгазьдә генә калды бит. Уртак тырышлык белән аларны тормышка ашыруда һәм Татарстанда фәнни ачышлар уникаль интерактив паркын булдыруда иманыбыз камил.

«Казан Гипронииавиапром» коллективы В.П. Энгельгардт исемендәге Астрономия обсерваториясе коллективына уңышлар, яңа фәнни ачышлар һәм иҗади илһам тели!

Обсерваториянең барлык хезмәткәрләренә сәламәтлек һәм бәхет телибез!



Ихтирам белән,
«Казан Гипронииавиапром» АҖ
генераль директоры
Борис Тихомиров;

архитекторлар-проект авторлары
Р.М. Ибраһимов,
Г.Ф. Уткузова,
Б.Н. Блинов;

проектның баш инженеры
Евгений Сизов;

«Казан Гипронииавиапром» АҖ коллективы

75 КАЗАНСКИЙ ГИПРОНИИАВИАПРОМ

Реклама

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Татарстанда борынгы венгрларның эзләре **КАЙДА** табылган

Республикада татар авыллары **НИНДИ** хәлдә

Яла ягучылар «донос» сүзен **НИГӘ** сөймиләр

«Күзге китаплар» **НИНДИ** хисләр уята

Биектаулылар **НИГӘ** су үгезеннән куркалар

БОРЫНГЫ ВЕНГРЛАР ЭЗЛӘРЕ

Әле узган айда гына Татарстан Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков исемендәге Археология институты галимнәре Будапешт университетыннан килгән венгр коллегаларын кабул иттеләр. Әйтергә кирәк, Татарстан археологлары белән Венгрия галимнәре арасында тыгыз хезмәттәшлек һәм дуслык җепләре узган гасырның 70нче елларыннан ук сузылган иде.

Автор:
Фаяз Хуҗин

ХЕЗМӘТТӘШЛЕК ТАРИХЫ

1974 елда безнең археологлар республикабызның Алексеевск районы Зур Тигәнәле авылы янында борынгы венгр (мадьяр) кабиләләре калдырган каберлеккә тап булдылар. Гыйльми җәмгатьчелектә әлеге каберлекне тикшерү нәтиҗәләре чын сенсация буларак кабул ителде. Идел болгарлары белән борынгы венгрлар арасында урнашкан мәдәни һәм сәяси мөнәсәбәтләр тарихы, әлбәттә, күпләрне кызыксындыра торган актуаль проблема. Венгрия һәм Татарстан галимнәре бу юнәлештәге эшләрне киләчәктә дә дәвам итү, ике арадагы хезмәттәшлекне тагын да ныгыту юллары турында фикер алыштылар. Сөйләшүләрдә катнашучыларны Венгриянең Казандагы Генераль консулы Ференц Контра һәм аның тышкы икътисадый мәсьәләләр буенча урынбасары Шпиндлер Жолт кабул итте.

Дөресен әйткәндә, республикабыз территориясендә борынгы венгрларның (мадьярларның) археологик эзләре галимнәргә күптән билгеле иде инде. IX гасырда яшәгән мәҗүси болгарларның 1960нчы елларда ук казып тикшерелгән Танкеевка каберлегендә (ул Спас районында, Болгардан 20 чакрым ераклыкта урнашкан, 6000ләп кабернең 1200гә якыны өйрәнелгән – авт.) борынгы венгрлар культурасына хас әйберләр табылды. Алар арасында галимнәрнең игътибарын үзенчәлекле бизәнү әйберләре, түгәрәк төпле савыт-сабалар һәм юка көмеш калайдан кисеп ясалган маскалар җәлеп итте. Ике күз, борын һәм авыз урыннарында тишекүемтылар ясалган әлеге маскалар белән үлгән кешеләрнең йөзләрен каплый торган булганнар. Күмү йоласының бу элементы бары тик венгрлар һәм алар белән кандардәш ханты, манси халыкларында гына очрый.

Шунысы кызык: әле XX йөз башларында ук күренекле венгр галиме, тел белгече Золтан Гомбоц үзенең хезмәтләрендә хә-

Юка көмеш калайдан ясалган кұму битлекләре. Баян (1,2 рәс. Пермь крае), Танкеевка (3 рәс. Татарстан), Рождественск (4 рәс. Пермь крае) каберлекләре.

Чәчүргеч бизәнү әйберләре. Башхалом каберлеге (Венгрия).

зерге венгр телендә яшәп килгән 800ләп төрки алынмаларының 230га якыны (eke – сука, borso – борчак, kender – киндер, arpa – арпа, komlo – колмак, balta – балта, beka – бака һ.б.) Идел болгарларыннан кергән булуын исбатлаган иде.

Менә шушы материалларга таянып, галимнәр, венгрларның борынгы бабалары Көнбатыш Европага, ягъни Карпат–Дунай буйларына, көнчыгыш тарафлардан, Урал арьягыннан күчеп килгәннәр, дигән теориягә (гәрчә ул баштарак фараз рәвешендә генә булса да) нигез салдылар. Урта гасырлардан ук сакланып калган кульъязмалардагы Magna Hungaria («Бөек Венгрия»; биредә «бөек» сүзен «борынгы» мәгънәсендә аңларга кирәк -авт.) урнашкан территорияне дә алар Көнчыгыш Европадан, башлыча Урта һәм Көньяк Урал якларыннан һәм дә Днепр-Дон, Төньяк Кавказ тирәләреннән эзли башладылар. «Magna Hungaria»не Идел–Урал арасында урнаштыручылар да бар иде.

ЗУР ТИГӘНӘЛЕ КАБЕРЛЕГЕ

Югарыда телгә алынган Зур Тигәнәле каберлегенең искиткеч бай материаллары венгрларның килеп чыгышы проблемасына яңача караш тудыруга сәбәпче булды. Биредә VIII–X гасырның беренче яртысына караган 100дән артык каберлек ачылды. Венгрлар мәетне, кагыйдә буларак, каберенә, һич тә кызганмыйча, күп кенә затлы әйберләр куеп күмгәннәр. Баш очында гадәттә балчыктан ясалган матур чүлмәк тора, аяк очында – ат түшкәсе, ә күп очракта аның карачкысы гына: анатомик тәртиптә урнаштырылган баш һәм койрык сөякләре, аяклары һәм эченә салам тутырылган тиресе. Ирләрне дә, хатын кызларны да матур итеп киендереп күмгәннәр: муеннарында пыяладан һәм асылташлардан ясалган төймәләр, күкрәкләрендә башлыча көмештән ясалган асма бизәкләр, кулларында беләзек-йөзекләр, билләрендә көмеш накладкалар белән бизәлгән каешлар. Ирләрне, кагыйдә буларак, сугыш кораллары белән, сул ягына – ук-җәяләр, уң ягына хәнҗәр-кылычлар яисә сөңге куеп күмгәннәр. Каберләрдә, мәетнең баш сөяге тирәсендә, еш кына көмеш дирһәмнәр дә табыла.

Зур Тигәнәле каберлегенең борынгы венгрларныкы икәнлеге ничек расланды соң? Миңа калса, бу сорауга җавап табу өчен Казан дәүләт университеты археологы Елена Халиковага артык тырышырга туры килмәде кебек, чөнки күму йоласының һәм табылдыкларының үзенчәлекләре ягыннан караганда нәкъ менә Зур Тигәнәледәге кебек каберлекләр Венгриянең үзендә моңа кадәр күпләп тикшерелгән иде инде. Дөрес, аларның иң элгәреләре IX гасыр азакларына гына карый. Шулай булырга тиеш тә, чөнки аңа кадәр бит мадьярлар Көнчыгыш Европа далаларында күчмә тормыш алып барганнар.

Татарстан җирләренә килеп төпләнгән иң борынгы мадьярларның эзләре VII–VIII гасырларга карый. Шул чорларга караган материаллар, югарыда телгә алынган Танкеевка каберлегеннән башка, Актаныш районының Такталачык авылы, Спас районының Әҗмер авылы янындагы каберлекләрне казыганда да табылды.

МАДЬЯРЛАР БЕЗНЕҢ ЯКЛАРГА КАЯН КИЛЕП ЧЫККАННАР?

Зур Тигәнәле һәм Танкеевка материаллары бу сорауга да төгәл җавап бирергә ярдәм итәләр. Табылдыкларның кайсы гына төрен алып карама – савыт-саба һәм бизәнү әйберләре дисеңме, сугыш корал-

PRESSA.RU

Декоратив кылыч. Баян каберлеге (Пермь крае).

Чәчүргеч бизәнү әйберләре.
Арпад ыруына карый.

Бил прәшкәсе.
Башхалом каберлеге.

Венгрларның Карпатны кичүенә 1100 ел тулу хөрмәтенә Верецк үткелендә куелган Истәлек билгесе (Украина).

лары һәм кумү йоласымы – барысының да элгәреге прототипларын борын-борыннан урман-далалы Көнбатыш Себер территориясендә яшәгән угыр кабиләләре культурасыннан табарга була. Безнең эрага кадәр V – безнең эраның IV гасырларына караган әлеге культураны археологлар *саргат культурасы* дип йөртәләр, чөнки бу кабилә кешеләре калдырган курган каберлекләр беренче мәртәбә Омск өлкәсендәге Саргатка авылы янында казып тикшерелгән. Төрле сәбәпләр аркасында (табигать катаклизмнары булырга мөмкин, диләр палеоклиматологлар) бу кабиләләр (ә аларга кадәр безнең һун бабаларыбыз), Урал тауларын үтеп, VI гасырда хәзерге көньяк Башкортостан җирләренә килеп чыгалар. Биредә саргат культурасы кабиләләре борынгы мадьярлар калдырган культура – *кушнаренко* исемен ала (каберлекләре иң әүвәл Кушнаренко район үзәге янында табылган). Безнең Зур Тигәнәле каберлеге бар яклап та кушнаренко культурасы истәлекләренә охшаш. Әлеге истәлекләр (башлыча борынгы каберлекләр; торулык урыннары сакланмаган, чөнки аларны калдырган халык нигездә күчмә тормыш алып барган) Урал таулары белән Идел-Кама елгалары арасында урнашкан. Югары телгә алынган Magna Hungaria, хәзерге галимнәрнең бердәм фикеренчә, нәкъ менә шушы Идел–Урал җирләрен биләп торган да инде.

Magna Hungaria мадьярлары (аларның бер өлеше инде Азов – Кара диңгез буйларыннан, элеккеге Бөек Болгар һәм әле үзенең чәчәк ату чорын кичерүче Хәзәр каганаты җирләреннән Урта Иделгә күчеп килгән болгарлар арасында төркиләшкән була) VIII гасырдан башлап IX гасырның икенче яртысында кадәр көнбатыш юнәлешендә хәрәкәтләрен дәвам итәләр. Күрәсең, алар сугышчан болгарларның басымына түзә алмаганнардыр. Чираттагы миграция дулкынына эләккән мадьярлар башта Хәзәр дәүләтенең тарихка Леведия исеме белән кереп калган бер өлкәсендә, Дон һәм Донец елгалары тирәсендә, яшәп алалар, аннан соң тагын да көнбатышкарак күченеп китәләр. Аларның 895 елда бөҗәнәкләр һөҗүме нәтиҗәсендә Паннониягә, Урта Дунай буйларына күченеп киткәнчегә кадәр Днепр – Днестр буйларында яшәгән җирләре тарихта Этелькёзе (Этел-кюзю – елгаара өлкә) исеме белән билгеле.

895 елдан башлап – бу төгәл дата борынгы елъязмаларда күрсәтелгән! – мадьярлар үзләренең бүгенге җирләрендә яши башлыйлар. Әлбәттә, бу җирләр ул вакытта да буш ятмаган, аларны Алмошның улы Арпадка (икесенең дә исемнәре төрки телдән чыгып аңлатыла) – җиде мадьяр кабилә башлыклары арасындагы иң көчлесенә – сугышып алырга туры килә. Шул заманнарда ук мадьяр халкының дәүләтчелегенә – Венгрия корольлегенә нигез салына.

Әлбәттә, Идел –Урал киңлекләрен биләп алган Magna Hungaria мадьярларының барысы да көнбатышка күчеп китми, бер өлеше шул җирләрдә төпләнеп кала. Мәсәлән, күпсанлы башкорт кабиләләре арасында *юрматы* исемлесе (венгрларда – дьюрмата) әле XVIII–XIX гасыр документларында да телгә алына.

Яшәүләрен Идел Болгарстанында дәвам иткән мадьярлар әле озак вакытлар үз телләрен, гореф-гадәтләрен саклап калалар. Шул ук вакытта көнбатыштагы Паннония венгрлары белән дә бәйләнешләрен югалтмыйлар. Бу турыда без 1235 елда безнең якларга килеп чыккан доминикан монахы Юлиан язмаларыннан укып беләбез.

Халыкларның Бөек күчеше чоры каберлекләрен казу. (Пермь крае).

Балчык чүлмәкләр. Кушнаренко культурасы (Башкортостан).



Караякуп культурасына (Көньяк Урал) караган корал һәм ат иярләү кирәк-яраклары.

Аның максаты – тугандашларыннан Идел буенда аерылып калган һәм әле һаман да мәҗүсилекләрен саклап килгән мадьярларны тугры юлга өндәү, католик диненә күчерү. Юлдашларын югалтып, мең газаплар белән килеп җитә Юлиан Идел Болгарстанына. Һәм олуг шәһәр – дәүләтнең ул вакытлардагы башкаласы Биләр тирәсендә болгар кешесенә кияүгә чыккан, әмма туган телен дә онытмаган бер мадьяр хатынын очрата. Ул аңа элеккеге кабиләдәшләренең олуг шәһәрдән ике көнлек юл ераклыгындагы бер җирдә, Итил (хәзерге Кама) исемле зур елга буенда яшәп ятуларын әйтә. Юлиан шулар янына китә, аларны таба, мәҗүсилектән ваз кичәргә өнди һәм бераздан (үз максатына ирешкәнме-юкмы – анысы билгеле түгел) кире туган иленә кайтып китә.

ВЕНГРИЯДӘ САКЛАНГАН ТӨРКИ АТАМАЛАР

Сөйләнгән вакыйгалардан күпкә элгәрәк, әле 970нче елларда ук, бертуган Билла һәм Боксу исемле кешеләр кул астындагы болгарлар төркеме, соңыннанрак исә Хәсән бәк җитәкчелегендәге тагын бер төркем, Биләрдән чыгып, берничә айлык озын юл үтеп, Венгриягә килеп җитәләр. Биредә аларны шатланып каршы алалар. Такшонь исемле король Болгарстан кунакларын Буда крепостендагы резиденциясендә кабул итә һәм аларга Дунайның сул ягында урнашкан бер авылда яшәп торырга куша. Бу урында болгарлар Пешт исемле шәһәргә нигез салалар. Соңыннан Венгрия короле болгарларның берсен, сәүдә һәм алыш-биреш эшләрен яхшы белүен күз алдында тотып, дәүләт фининслары җитәкчесе (ягъни финанс министры) итеп билгели.

Игътибар иткәнсездер инде: Венгрия дәүләтенә нигез салган король Арпадның әтисе Алмош исемле булган дигән идек. Сүз дә юк, ул – төрки исем, Идел Болгарстанының беренче ханы да Алмыш исемле булган бит. Арпадның улы Золта һәм аның улы Такшон, мадьярлар составындагы тарьян, ене, кер, кеси кабиләләренең исемнәрен дә лингвистлар төрки телдән чыккан дип аңлаталар. Бүгенге көндә Венгриядә өч дистәгә якын этнотопоним болгарлар исеме белән бәйләнгән: Болгар, Богард, Полгар, Полгарди, Боляр, Берсел һ.б. Әле XIII йөздә үк язып алынган бер легендада Менотның Энет исемле хатыныннан туган Һунора һәм Могора исемле уллары – һуннарның һәм мадьярларның борынгы бабалары турында сүз бара. Алар Меотида (Азов) сазлыгында Белар исемле ирнең балаларын һәм саклаучысыз калган хатынын очраталар, ятимнәргә ярдәм кулын сузалар. Бу легендада игътибарыбызны венгрларга төрки телдән кергән энет (әни) һәм Белар/Биләр сүзләре җәлеп итә.

Сүзебезне йомгаклап шуны әйтәсем килә: Болгар җирендә борынгы мадьярлар эзе, Венгриядә исә болгар бабаларыбыз калдырган эзләр бүгенге көннәргә кадәр яхшы сакланган. Мадьяр – болгар бәйләнешларына бәйле фәнни проблемалар – аларның актуальлеге бездә шик тудырмый – әлегә чишелеп бетмәгән. Шуңа күрә бу өлкәдә эшләребезне киләчәктә дә дәвам итәргә уйлыйбыз. Киләсе елга венгр коллегаларыбыз белән Танкеевка каберлегендә өстәмә рәвештә казу эшләре үткәрергә планлаштырып куйдык. Танкеевка һәм Зур Тиганәле материалларын тулысынча фәнни әйләнешкә кертү дә (рус, венгр һәм инглиз телләрендә) көн кадагында торган мәсьәләләрдән.

PRESSA.RU

ТАТАРСТАН

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә

Индекс **П 2381** – татар телендә: алты айга язылу бәясе **864 сум 24 тиен**
Индекс **П 2378** – рус телендә: алты айга язылу бәясе **864 сум 24 тиен**



Ф.СП-1

Почта России

АБОНЕМЕНТ на ~~газету~~ журнал П 2381 (индекс издания)

Татарстан (наименование издания) количество комплектов:

на 2017 год по месяцам:

1	2	3	4	5	6	7	8	9	10	11	12
✓	✓	✓	✓	✓	✓						

Куда (почтовый индекс) (адрес)

Кому (фамилия, имя, отчество)

ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА

ПВ место литер

на ~~газету~~ журнал П 2381 (индекс издания)

Татарстан (наименование издания)

Стои-мость: подписки 864 руб. 24 коп.; пере-адресовки ___ руб. ___ коп. количество комплектов:

на 2017 год по месяцам:

1	2	3	4	5	6	7	8	9	10	11	12
✓	✓	✓	✓	✓	✓						

Куда (почтовый индекс) (адрес)

Кому (фамилия, имя, отчество)

Шулай ук электрон почта аша да язылырга мөмкин:
milyaushanb@tatmedia.com
Дистрибуция бүлеге хезмәткәрләре, шалтыратып, кызыксындырган сорауларыгызга җавап бирерләр.

Яки түбәндәге телефон буенча тарату бүлеге җитәкчесе Миләүшә Байрашевага үзегез шалтырата аласыз: **тел. +7 (843) 222 09 79**

ЯШЕЛЧӘ КАРАБАШ

«Татарстан» журналы, кызыклы атамалы татар авылларын, аларның тарихын һәм бүгенге яшәешен яктырту максаты белән, яңа сәхифә башлый. Сез дә безгә үз авылларыгызның хикмәтле яклары, гыйбрәтле хәлләре, уңган-булган кешеләре турында яза аласыз.

Яшел Үзән районы Олы Күлбаш авылы

Безне читтән генә Солтан абый Бикмөхәммәтов белән Айдар абый Абуталипов күзәтеп утырган икән.

ИДЕЛ БУЕНДАГЫ СУСЫЗ ЯШЕЛЧӘ

Автор:
Линар Закиров

Беренче тукталышыбыз Кама Тамагы районындагы Яшелчә авылында. Зур юлдан фермага кадәр юл ярыйсы гына иде, ә менә фермадан авылга текә таудан төшеп җитәргә кирәк. Без килгәндә коеп яңгыр яуды, җитмәсә, юлның бу өлешенә бер дә «биш»ле куярлык түгел. «Төшүен төшәрбез. Ә менә алмасак?» – дип сорады машина йөртүчебез. Нәрсә дип җавап бирергә дә белмәдек. Машина тын гына юлын дәвам итте.



БӘХЕТ ЭЗЛӘП «КАЧУЧЫЛАР»

Төштек тә, соңыннан исән-имин генә мендек тә. Яшелчә искиткеч матур урында – яшеллек кочагында, тау итәгендә, Идел буенда урнашкан. Авылга килеп кергәч, безне тавыклар белән казлар каршы алды. Як-ягыбызга каранып барабыз. Күп кенә йортларны заманча тәрәзә йөзлекләре бизи. Модасы шундыйдыр, дип уйладык без.

Бер йорт капкасына эленгән таксофонны күреп алгач, кызыксынып киттек. Эшлиме икән бу, дип трубкасына үрелдек. Эшли. Безнең кыланмышларыбызны читтән генә Солтан абый Бикмөхәммәтов белән Айдар абый Абуталипов күзәтеп утырган икән. Яннарына килгәч, алар безгә Яшелчәнең тарихы турында бәян итте.

– «Декрет о земле» чыккач, 1925 елда Кече Салтык авылыннан Мөхәммәди исемле карт хәзерге Яшелчә авылы урнашкан урыннан җир сорап, Казанга бара. Монда 30 гаилә күченеп киләсе була. Ул вакытта Кече Салтык гөрләп тора, хәзер генә беткән хәлдә ул. Казаннан киләләр дә гаиләләргә җирне бүлеп бирәләр, – дип сөйләп китте безгә Солтан абый.

Аның дәү әтисе дә шушында беренчеләрдән булып килеп төпләнә, алар гаиләдә 6–7 малай була.

– Күченәсе кешеләр күченеп беткәч, авылга исем эзлиләр. Башта Тукай авылы булсын, диләр. Әмма андый исемле авыл инде Тәмте (Кама Тамагы районына ул әле соңрак кушыла) районында булганга күрә, башканы уйлыйлар. Тирә-якта яшеллек күп, әйдәгез, Яшелчә дип кушыйк, диешәләр, – дип сөйләде әңгәмәдәшләребез.

Абзыйлар әйтүенчә, бүген авылда 15 йортта гына ел әйләнәсе кеше яши, хәтта бармакларын бөгеп, барысын барлап та чыктылар: Илфат, Вәгыйзь абый, Фәнис, Рәфидә, Рөстәм, Хәлим… Җәен бакчачылар күп кайта икән.

– Һәммәсе дә үзебезнең авылдан чыккан кешеләр. Алар, колхоз «кәпийкә» түләгәнгә, яхшы тормыш эзләп, Казанга «качтылар» да пенсиягә чыккач, бәрәңге утыртырга, кышка яшелчә хәстәрләргә кайталар, – диде Солтан абый. Аның бер малае белән килене шушында яши, ә икенче бер улы һәм кызы, үзе әйтмешли, шулай ук бәхет эзләп, Казанга «качканнар».

– Яшелчәгә Казаннан «качып кайткан» художник та яши, – ди Айдар абый. – Безнең якларга ничек килеп эләккәндер – шайтан белгән. Ни дисәң дә, рәсемнәрне оста ясый. Рөстәм исемле ул, татарча авыррак сөйләшә. Картиналарны ясый-ясый да Казанга илтеп тапшыра.

Фотолар: Луиза Шарова

Әңгәмәдәшләрем сөйләвенчә, авыл тирәсендә фермада гына эш бар. Кышлый (биредә шулай дип сөйләшәләр – авт.) үгезләрне-таналарны китерәләр дә, аларны өч-дүрт кеше карый. Айдар абыйның улы да малларга күз-колак булып йөри.

– Таксофоныгыз эшли икән. Аңардан кем дә булса шалтыратамы? – дип сорыйбыз.

– Шәһәрдән кайтканнар шалтырата торгандыр, – дип җавап бирде Айдар абый. – Художник та еш кына кем беләндер сөйләшә.

– Тәгәрмәчле кибет – автолавка киләме? – дибез.

– Килә-килә. Атнага ике мәртәбә: чәршәмбе һәм шимбә. Ризыклары һәрвакыт «свежий». Казанда торучы дачниклар да, мондагы әйберләр шәһәрдәгедән дә «свежийрак», дип мактыйлар, – диде Айдар абый.

«Суны чишмәдән 20 литрлы савытта тачка, машина белән ташыйм», – ди Дилбәр апа Гыйниятуллина.

СУ КҮП – ЭЧӘРГӘ ЯРАКЛЫСЫ АЗ

Идел елгасы моннан кул сузымында гына. Авыл аша балыкчылар ел әйләнәсе йөреп тора, шуңа да Яшелчәдә юлның кышын да беткәне юк. Ял көннәрендә авыл тирәсендә 100–150ләп машина җыелып, бөтен Идел буе балыкчылар белән тула икән.

– Әнә, балыкчыларның бригадиры килә, – дип көлешә башлады ирләр, безгә таба килүче клуб мөдире Дилбәр апа Гыйниятуллинаны күреп алгач.

– Клубыгыз да бармыни? – дип гаҗәпләндек.

– А как же! – диләр бертавыштан абзыйлар.

Дилбәр апа тумышы белән Тәтеш районыннан. 1983 елда кияүгә чыгып, ире белән бирегә килеп төпләнгән.

– Исәпләвем буенча, без килгәннән бирле авылда ел саен бер кеше үлде, – диде ул.

– Туучылар бармы? – дип, сөйләшүне күңеллерәк якка борып җибәрергә тырышабыз.

– Әйе, быел Айдарның оныгы һәм Эльмираның баласы туды. Үлүче булмады. Балалар мәктәпкә Камскига (Кама Тамагы бистәсен авыл халкы шулай дип атый – авт.) йөри. Автобус фермага кадәр килә, – диде Дилбәр апа.

Почтаны авылга нибары ике тапкыр китерәләр. Шуңа да вакытлы матбугат почта әрҗәсенә җиткәнче, андагы бөтен мәгълүмат «күгәреп» бетә.

– Бездә су юк. Аның бит әле уты-күзе дә бар. Идел якын булса да, кем анда төшеп су алсын, ди. Мин суны чишмәдән 20 литрлы савытта тачка, машина белән ташыйм. Кызу көннәрдә, кышлый да коеда су бетеп куя. Хәзер бөтен җирдә автомат машинада кер юалар. Район башлыгына да, депутатларга да: «Кул белән юар өчен порошок та чыгармыйлар инде», – дип әйттем. Көлделәр генә, – диде күзлеге аша усал итеп карап клуб мөдире.

– Законы юк аның…

– Солтан абый, законы бар. Без йөри белмибез… Авыл эчендәге юлыбыз да бик начар. Ирем быкырдыктан «Нива»сында үтсә, үземнең «14»лем белән ул юлдан бара алмыйм. Коры вакытта гына чыга алам.

– Яшелчә авылында яшелчәне күп үстерәсезме? – дибез.

– Юк. Әлеге дә баягы суга килеп тоташа, – диде Дилбәр апа. – Ил җитәкчелеге хайван асрарга куша кушуын. Әмма аның өчен нәрсә кирәк? Су кирәк. Без аны кайдан алыйк соң?! Ярый, печәнне чабарбыз. Ә син язын-көзен быкырдыктан көянтә белән су ташып кара әле…

PRESSA.RU



ТАРИХ КҮЗЛЕГЕННӘН: КАРАБАШ

Бөгелмә районына кергәч тә, Каравыл тавы күзгә ташлана. Аның итәгендә эшчеләр бистәсе – Карабаш урнашкан. Биредә ел саен республика күләм нефть саммиты үтә. Карабашка эшчеләр бистәсе статусы 1957 елда, нәкъ менә биредә «кара алтын» чыгарыла башлаган чакта бирелә.

Автор:
Альберт Борһанов,
тарихчы-археолог

ӘКИЯТ ТҮГЕЛ – ЧЫНБАРЛЫК

Җирле халык сөйләвенчә, авылның борынгы урыннарында, Каравыл тавы итәгендә ук очлары, сөңгеләр, пычак рәвешендәге пластиналар, керамик савыт кыйпылчыклары, тимер, таш, пыяла эшләнмәләр, кыргый һәм йорт хайваннары сөякләре, борынгы кешеләрнең җәсадләре табыла. 2009 елда үткәрелгән фәнни эзләнүләр вакытында авыл тирәсендә зиратларның күп булуы ачыклана. Бүгенге көндәгеләрен дә исәпләсәң, барлыгы сигез каберстан килеп чыга. Искесендә элеккеге кабер ташлары табыла. Авылның иң борынгы өлешендәге зиратта XVII–XIX гасырга караган тугыз кабер ташы тора, кайберләренең гарәп һәм искетатар язулары шулкадәр яхшы сакланган, аларны бүген дә укып була.

Карабаш авылы турында риваятьләр дә телдән-телгә күчеп бара. Шуларның берсен бүген инде мәрхүм булган Вафа Сәйфиев сөйләп калдырган.

«Кайбер мәгълүматлар буенча, бистәгә 1500нче елларда Карабаш исемле казак нигез сала. 1495–1499 елларда Казан белән Себер ханы идарә иткәндә, аның гаскәрендә себер татарлары, ногайлар, башкортлар һәм башка төрле кабиләләр була. Ханның Карабаш исемле дружиначысы безнең якларны ошата. Хан гаскәре Казаннан туган якларына кайтып барганда, Карабаш үзенең биш хезмәтчесе белән төп армиядән аерылып, «биш казак» таллыгында кача. Якында, тау итәгендә, берничә йорттан торган черемис (мари) авылы була. Берзаман Карабаш су буенда черемис кызын күреп ала да аның белән таныша. Кыз Таңбикә исемле була. Яшьләр бер-берсенә гашыйк булып кавышалар. Карабаш белән бергә шушы җирдә биш казак та кала».

Вафа Сәйфиевнең бабасы сөйләп калдырганча, тау итәгендә Мари әби ташы була, ул шул тирәдәге зиратта җирләнгән матур кыз истәлегенә куела.

Бу легенданың дөреслеген тарихи фактлар да дәлилли. 1495–1496 елларда Казан ханлыгы белән Мамык хан идарә итә. Легендада әйтелгәнчә, авылга 1490 елда нигез салына. Бу мәгълүматның хаклыгын авыл тирәсендә табылган Казан ханлыгы чорына караган предметлар раслый.

1700 елда Карабашка биш казак гаиләсе килеп төпләнә. Алар авылда күзәтчелек итәргә тиеш була. XVIII гасыр башында бирегә, көчләп чукындырудан качып, Казан губернасының Мамадыш һәм Мин-

Фотолар автор архивыннан

зәлә өязләреннән күп кенә татар гаиләләре күченә. Алар Котылдык, Түбән оч, Югары оч, Әхмәт төбәге, Шамкач урамнарына нигез сала.

КАРАБАШНЫҢ «КАРА АЛТЫНЫ»

1730 елда патша Карабаш аша үтәчәк Казан–Оренбург трактын салырга боера. Әлеге төзелеш авылга үсеп китәргә мөмкинлек бирә. Шул ук вакытта крестьяннар арасында төрле катламнарга бүленеш башлана. Иң елгырлары юлчылар өчен куну йортлары ача. Мөхәммәтрәхим исемле кеше Мөхәммәтҗан, Әхмәтҗан, Кәрим исемле уллары белән, сәүдәгәрләрне, түрәләрне һәм башка төрле кешеләрне Уфа, Оренбург, Чистай, Казан, Богыруслан якларына күчерү өчен, бик күп ат һәм җигү кирәк-яраклары тота.

1940 елда Карабаш халкында патефон, тимер карават, тегү машинасы, велосипед, радио барлыкка килә. Китапханә, медпункт, колхоз идарәсе бинасы төзелә. Мәчет исә клуб буларак файдаланыла.

Бөек Ватан сугышына Карабаштан 632 кеше озатыла. Йөздән артык хатын-кыз Горький (хәзерге Түбән Новгород – авт.) белән Иваново өлкәләренә торф казырга, хәрби заводларга җибәрелә. 1944 ел карабашлыларны тәмам аяктан ега: көтмәгәндә килеп чыккан септик ангина ике ай эчендә 393 кешенең гомерен өзә.

Нефть сәнәгате дә авыл тормышын яңа юлдан алып кереп китә. 1943 елда, ниһаять, күп төрле фаразлардан соң, нефть – Шөгер авылында, 1946 елда Баулыда табыла, 1948 елда атаклы Ромашкино нефть ятмасы ачыла. Ә 1950 елда Карабашта да «кара алтын»ның эзенә төшәләр. Бирегә Баку, Грозный, Украина, хәтта Сахалиннан белгечләр агыла. Баштарак алар крестьян йортларында урнаша, ул чакта әле кулланыштан төшеп калмаган юрталарның да кирәге чыга.

Соңгы җанисәп нәтиҗәләре буенча, Карабаш бистәсендә 5188 кеше яши: татарлар – 4281 (82,5%), руслар – 714 (13,5%), чувашлар – 76, мордвалар – 33, украиннар – 12, башкортлар – 9, казахлар – 8, әрмәннәр – 7 һәм башка милләтләр.

Бистәдә күпкатлы 63 торак йорт һәм 988 шәхси хуҗалык урнашкан. Бистә җирлегендә ике мәктәп, өч балалар бакчасы, ике мәдәният йорты, бассейнлы спорт комплексы, ике парк, стадион, җәмәгать мунчасы һ.б. эшли.

PRESSA.RU

СЕЗГӘ ШУЛ ХАКТА ХӘБӘР ИТӘСЕМ КИЛӘ...

«Донос» сүзен хәтта аны язучылар үзләре дә өнәми. Яла ягучы беркайчан да: «Төнлә донос яздым әле», – дими, үзен әллә кемгә куеп: «Тиешле җиргә хәбәр иттем!» – дип мактана, бәлки әле үзен социаль гаделлек һәм әхлаклылыкны яклап көрәшүче итеп тә тоядыр. Бу сүз безнең өчен бары тик тискәре мәгънәгә генә ия. Синонимнары да әллә ни түгел: яла, әләк, чагу һ.б. Юридик сүзлектә ул «күрәләтә ялган донос» терминында гына калган. Бу сүз инде беркайчан да акланмас кебек!

Автор:
Гадел Хәеров

СОВЕТ ПИОНЕРЫННАН САКЛАН

Сталин вакытында бу сүзне агартырга, гражданнарны аның ул кадәр үк начар түгеллегендә инандырырга маташу булган. Мәсәлән, «Пионерская правда» газетасының 1938 елның июнендә чыккан санындагы «Будь начеку!» материалында пионервожатый язмасын укыйбыз: «Күз алдында гаделсезлек кылынганны күргән чын пионер беркайчан да битараф калмаячак. Өлкәннәр ил җитәкчеләренә яла яга һәм партиянең дөрес курсын шиккә ала икән, нишләргә? Пионер, бу сүзнең яхшы мәгънәсендә, советларга каршы кеше хакында йорт буенча җаваплыга, урам себерүчегә, сыйныф җитәкчесенә, участок милиционерына хәбәр итәргә тиеш. Әгәр факт күзгә бәрелеп тора икән, аны яхшылап аңлатып язу һәм бу хатны пионер оешмасына илтеп бирү зарур...» Илһамланган тимурчылар советларга каршы кешеләрне бик актив ачыклый һәм дәфтәр битенә тырыша-тырыша хәрефләр тезә: «Сез-гә шул хак-та хә-бәр и-тә-сем ки-лә...» Әти-әниләре исә сабыйларын тырыша-тырыша өй эше әзерләп утыра дип уйлап сөенә!

«Пионерская правда» газетасында хәтта «Совет пионеры – халык разведчигы» таныклыгы да бастырыла, аны кисеп алып, буш калдырылган урынга фотосурәт ябыштырырга һәм пионер оешмасында мөһер суктырырга гына кирәк була.

Өлкәннәр паркта утырган, шахмат яки домино уйнаган, һава торышы, сәясәт, тегесе-бусы турында гәпләшкән. Алар үзләре янындагы бала-чага гербарий җыя яки чикерткә тота, дип уйлап бик нык ялгышкан: яшь доносчылар күпкә мөһимрәк эш – халык дошманнарын ачыклау белән мәшгуль булган!

Бәйрәм көннәрендә, коммунизм төзүчеләр исереп, җырлар җырлаганда, бигрәк тә шәп «уңыш» җыелган. Күбрәк эчкән саен куплетлар да кыюланган. Пионерлар исә язып барган:

Написал Фома донос,
И случился с ним понос.
Настрочил он писем рой –
Сразу вылез геморрой...

«КЫЗЫЛ» ХАТЫН «АК» ИРЕНӘ КАРШЫ

Пионер оешмаларындагы бу хәл партия тормышының турыдан-туры чагылышы булган. Әйтик, РКП(б) ҮК секретаре С.Гусев үз докладында, йодрыгын селки-селки: «Партиянең һәр әгъзасы донос язарга тиеш. Әгәр без нәрсәдән дә булса интегәбез икән, бу яла ягучылыктан түгел, бәлки әләк язучыларның җитәрлек булмавыннан», – дип ачыктан-ачык сөйләгән.

Социалистик реализм тарафдарлары булган язучылар, докладчы коммунистларны тыңлап, үз нәтиҗәләрен ясаган. Күбесе инде иҗат белән шөгыльләнмәгән, хакимияткә ярарга тырышып көн күргән. Мәсәлән, драматург Константин Треневның атаклы «Любовь Яровая» пьесасында сюжет мондыйрак: хатыны – кызыллар, ире исә – аклар яклы. Яроваяны акгвардиячеләр штабында яшерен документлар эзләгәндә тоталар, әмма ире ярдәмгә килә – барысын да көнләшүгә кайтарып калдыра, янәсе хатыны аның мәхәббәт хатларын эзләгән. Җибәрәләр. Ә инде шәһәргә большевиклар кергәч, хатын иренә качарга бирми, аны кызылларга сата. Ирен алып китеп барган патруль артыннан бер дә борчылмыйча карап калып, ул комиссарга: «Мин бүгенге көннән генә ышанычлы иптәш», – дип белдерә.

Асылда, бу пролетарлык чорын донослар өчен гаепләү дөрес тә түгел – чөнки марксизмга нигез салучы Карл Маркс үзе дә яшь чагында моның белән мавыккан. Җитмәсә әле акчага. 1960 елның 9 гыйнварында немецларның «Рейхсруф» газетасы Марксның Лондонда, Парижда һәм Швейцариядә эмиграциядә булган революционер иптәшләре өстеннән донослар язуы һәм һәркайсы өчен кырыгар марка алуы турында фактлар бастыра. Әтисеннән акча килеп торса да, соңрак исә Фридрих Энгельс иганәсендә яшәсә дә, еш кына биржада оттырганга, ул вакытта Маркс гел акчага кытлык кичергән.

ЯШЕРЕН КАНЦЕЛЯРИЯ

Ничек кенә булмасын, Сталин репрессияләре – безнең катлаулы тарихыбызның аерылгысыз бер өлеше. Ул еллардагы процесслар турындагы материаллар белән танышканда, кичәге җәлладларның тиз арада ничек корбанга әйләнүе ачык күренә. Чып-чын абсурд театры! «Халык дошманын» уйнаучы актер чирләп китсә, режиссер аның роленә «тикшерүчене» билгеләгән. Ул кулларындагы канны юган да, номер суккан роба кигән. Бөтен нәрсә буталып беткән.

Рус һәм татар авылларында таза хәлле крестьяннарны үз авылдашлары ук кулакка чыгарып юк иткән. Һәм, әйтергә кирәк, моны бик теләп эшләгән. Дәртләнеп, мәчет манараларын һәм чиркәү чаңнарын аударганнар, алпавыт утарларын тар-мар иткәннәр, мародерлык белән шөгыльләнгәннәр. Дөрес, алар донос язмаган,

Фото: Ната Смирнова

PRESSA.RU

чөнки яза белмәгәннәр. Әмма килгән комиссарның колагына бөтен әләкләрен пышылдарга өлгергәннәр!

Без барысын да Сталинга һәм аның әшнәләренә кайтарып калдырырга күнеккән. Әмма, миңа калса, Иосиф Виссарионович көнкүреш дәрәҗәсендә булган вазгыятьне законлаштырган (һәм яңа дәрәҗәгә күтәргән!) гына. Халык моның белән күптән шөгыльләнгән! Бу ул заманның рухында булган, пролетариат гавамы һәм интеллигенциянең асылын тәшкил иткән. Бөтенесе дә революциядән генә башланганмыни? Императорлар чорында сәяси эзәрлекләү булмаганмы? Яшерен канцелярия, яки Өченче бүлекне кая куясыз? Рус телендәге «сексот» (яшерен хезмәткәр) сүзе нәкъ менә патша Россиясендә пәйда булган. Ә элегрәк? Явыз Иван вакытында әләкләмәгәннәрдер, дисезме? Яисә Казан ханы Сафагәрәй сараенда? Ул заманда масштаблар гына башкарак булган...

ӘЛӘКЧЕ ҺӨНӘРЕ

Рус патшалыгы законнары җыелмасында («Соборное уложение 1649 года») әләкләмәгән өчен җәза бирү каралган: «А буде кто, сведав или услыша на царское величество в каких людях скоп и заговор или иной какой злой умысел, а государю, и его государевым боярам и ближним людем, а в городах воеводам и приказным людем про то не известит... и его то казнити смертию безо всякие пощады». Кылынган җинаять турында донос «извет» дип аталган, аның белән шөгыльләнүчеләр исә «изветчик» дип йөртелгән.

Петр I заманында доносчылык һөнәргә әйләнә, әләк өчен гонорар түлиләр. Ә 1725 ел Указы буенча, хуҗасын әләкләгән крепостнойга патшадан азатлык кәгазе бирелгән. Һәм менә тагын бер мөһим нәрсә. Әгәр фискаль донос ялган булса, чагучы судан коры чыккан: законда «фискалны гаепләргә ярамый» дип язылган. Кайберәүләр фикеренчә, 1715 ел Указы реформатор патшаның хәйләсе булган – ул Россия элитасының европалашуын тизләтү максатын куйган. Рус дворяннары, хезмәтчеләре аңламасын һәм патшага әләкләмәсен өчен, тиз арада чит телләрдә сөйләшергә өйрәнгән. Тора-бара исә хәтта иң ялкау алпавытларның да һәм кием-салымы, һәм фикерләре, һәм белем дәрәҗәсе үзгәргән. Менә шулай итеп русларның кимчелеге аларны мәгърифәткә һәм алгарышка китергән.

Бездә шундый бер шөбһә бар: донос россиялеләрнең яраткан шөгыле түгел микән? Аларның холкының үзенчәлеге? Әлбәттә, бөтенесенеке дә түгел. Безнең арада да намуслы, принципиаль, тәртипле кешеләр булган һәм бар. Әмма аларны ала каргаларны яраткан кебек яратканнар...

«А»ДАН «Б»ГА КАДӘР АРА

Журналист һәм язучы Рафаэль Мостафин үзенең соңгы «Һәрберсен исемләп искә алыйк» китабында репрессияләнгән язучылар һәм аларның җәлладлары турында сөйли.

«Пролетар идеология сафлыгын «ярсып кайгыртучылардан» булган Кави Нәҗми чыгышларының берсендә үзенең бөтен каләмдәшләрен ике төркемгә бүлә. «А» төркеменә, ягъни «чиста» яки «сулларга», ул үз иҗат юлларын Октябрьгә кадәр үк башлаган, әмма Совет властен сөенеп кабул иткән язучыларны кертә... «Б» төркеменә «нәҗесләр», яки «уңнар» керә... Аның мантыйгы буенча, әдәбиятта бары тик «А» төркеме әдипләре һәм яшь пролетар язучылар, шул исәптән үзе һәм тагын берничә каләмдәше генә калырга хокуклы булып чыга. «Б» төркеме язучыларын исә ул буржуаз дип атый, тарих барышы барыбер аларны һәлакәткә дучар итәчәк, дип фаразлый. Кави Нәҗми каләмдәшләрен физик юкка чыгаруны күздә тотмагандыр, әлбәттә. Әмма аның күп кенә нигезләмәләре һәм нәтиҗәләре соңрак турыдан-туры гаепләү бәяләмәләренә күчкән шул...»

Кави Нәҗми төзегән исемлекләр энкәвэдэчыларга зур ярдәм була. Озак уйлап тормыйча, алар анда авторның үзен дә кертәләр – «Б» төркеменә! Исемен Казан урамнарының берсе йөрткән язучы 1937 елда кулга алына һәм Черек күлдәге бер кешелек камерага ябыла. Аны өч ай газаплыйлар һәм гаебен танытмакчы булалар. Үрә катырып дивар буена бастыралар, янәшәсенә усал овчарка бәйлиләр – аның тешләре ир-атның җенес әгъзаларыннан бер генә сантиметр ераклыкта шакылдый, селкенсәң – беттең! Кыйнап, аның бөерләрен имгәтәләр, тешләрен коялар. Биш тапкыр, ялганлап, атарга дип алып чыгалар. Һәм Нәҗми бирешә, кемнедер гаепләп, беркетмәгә кулын куя. Ябыккан, буйсынган, бетерешкән язучыны өенә җибәрәләр. Хакимият биргән фатирындагы кабинетында утырып, тәмамланмаган кульязмаларына карап, елап утырырга гына кала. Кави Нәҗми «А»дан «Б»га кадәр араның шулкадәр кыска булачагын күз алдына да китермәгән була. Һәрхәлдә, үзе өчен.

ӘЛӘКТӘН – МӨРТӘТЛЕККӘ

Вакыт бара, репрессияләр аппараты үзгәрә – атуны илдән сөрү, сөргенлеккә җибәрү, психушкага утырту яки дөньяда барлыгыңны оныту алыштыра. Хакимияткә каршы язучының әсәрләрен бастырмыйлар. Ул читкә кагылган кешегә – мөртәткә әйләнә. Аның тыңлаучан дусларына фатирлар, иҗат йортларына юлламалар, мактаулы исемнәр, премияләр һәм дәүләт заказлары бирәләр, ә аңа – шымытыр!

Совет чорының 80нче елларында язучылар даирәсендәге вазгыять белән кызыксынган кешеләргә мин режиссер Константин Воиновның сюжеты буенча да, актерлар уены буенча да, салынган фикере буенча да искиткеч шәп «Шапка» фильмын карарга киңәш итәм. Сценарийга нигез итеп Владимир Войнович һәм Григорий Горинның «Кот домашний средней пушистости» пьесасы алынган. Минемчә, бүгенге язучылар оешмаларында да донос тыныч кына «яшәп ята». Бәлки, элеккеге кебек үк ачыктан-ачык түгелдер – ул бөтен кешенең күз алдында кәнәфидә кукраеп утырмый инде, шулай да шкаф артына качып, сызгырганны көтеп тора!

Үз-үзебезне тәнкыйтьләүдән тайчынмыйча әйтә алабыз – әләк язу өлкәсендә без журналистлар да язучылардан бер дә кимен куймыйбыз. Бигрәк тә гади корреспондентлыктан башлап, ниндидер югарырак вазыйфага ирешә алганнарга эләгә. Һәр баш мөхәррир өстеннән шактый әләк язылган, дип сөйлиләр, алар караңгы урында саклана һәм үз сәгате сугуын көтеп ята. Тагын, Казанда бары шул фискаль жанрда гына махсуслашкан бик сәләтле кеше дә бар, дип сөйлиләр. Аның турында каян белдекме? Табигый ки, аның өстеннән язылган доностан. Үзебез язган идек.

ФИСКАЛДАН – АНОНИМ КОММЕНТАТОРЛЫККА

Шаярту шаярту белән, әмма хәзерге доносның билгеле бер метаморфозалар кичерүен без дә таныйбыз. Явызлык теләүче хәзер нинди дә булса мәкаләгә комментарийлар биргәндә зәһәрен чәчә. Мәсәлән, «Бизнес-онлайн» материалларына. Биредә чын фамилиясен куеп язучылар сирәк. Тоташ – анонимнар. Безнең халык төрле сәбәпләр буенча һәм төрле персоналарга карата шул рәвешле парын чыгара. Замана әләкчесе үзгәрәк. Аның элемтәләре, бәйләнешләре саллы, ул үзенең югары урындагы танышына шалтырата һәм якынча болайрак сөйли: «Син бу адәм турында (бу урында нинди дә булса түрәнең исеме атала – уйдырманы тикшереп карамасыннар өчен эшләнә бусы) «югарыда» нәрсәләр сөйләгәннәрен ишетмәдеңмени? Мин синең урында булсам, аның бу романын бастырырга җөрьәт итмәс идем. Минем сиңа мөнәсәбәтем

яхшы икәнен беләсең бит, шуңа шалтыратам да...»

Күпчелек очракта шул җитә. Кешене кире боралар. Кульязмасын кире кайтарып бирәләр. Ул аптырашта! Телефоннан үзенә яла ягулары аның башына да килми.

ДОНОС ҺӘМ АНЫҢ ҖИРЛЕ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Бездәге һәрнәрсә үзенчәлекле булган кебек, үзебезнең җирле әләкнең дә үзенчәлекләре бар. Алар турында безгә үзебезгә дустанә мөнәсәбәттәге юмористик журнал редакциясендә сөйләделәр. Билгеле инде, мәзәк телендә. Иске, совет мәзәге бу: «МДУда бер профессор кандидатлык диссертациясен яклау процедурасыннан соң икенчесенә сөйли икән:

– Грузиядән диссертация якларга килсәләр, шәраб, шашлык алып киләләр... Урта Азиядән – кавын, йөзем... Татарстаннан килүче артыннан исә донос килеп җитә...»

Сүз уңаеннан, бу мәзәкне сөйләгән юмористик журнал мөхәррире үз басмасының исемен атамауны үтенде – сакланганны Аллаһ саклар, ди бит. Без вәгъдә бирдек-бирүен, әмма тиешле җиргә шыпырт кына сызгалап җибәрдек: «Сезгә шул хакта хәбәр итәм... Игелек теләүче».

БЕЗ АЛАРГА ҖИРӘНЕП КАРЫЙБЫЗ

Ә менә бусы чынлап та булган хәл. Безнең таныш язучыбыз М., 1990нчы еллар башында көнбатыш илләрен велосипедта урарга ниятләгәч, андагы гореф-гадәтләргә гаҗәпкә калган иде. Туристлар таптап бетергән сукмакларда боларны күреп булмый, ә ул ике тәгәрмәчле транспортында Европаны гизгән һәм аны үзе өчен бөтенләй башка яктан ачкан! Аны бигрәк тә инсафлы немецларның теләсә нинди хокук бозулар турында полициягә хәбәр итү тизлеге таң калдырган. Бервакыт трассадан барганда, коеп яңгыр ява башлаган, ул телефон будкасына кереп яшеренгән. Ә анда кемдер кергәч, ут үзеннән-үзе кабына икән. Салкын яңгыр туктамаган, һәм М. төнен шул будкада гына үткәрергә булган. Йокы капчыгына төренеп, бөкләнеп яткан. Әмма инде биш минуттан соң ук аны полиция сиренасы уяткан. Язучыны велосипеды белән участокка алып киткәннәр, документларын тикшергәч, хостелга илтеп куйганнар. Моны әле ул очраклы хәл дип кенә уйлаган. Янәсе, полиция янәшәдән генә үтеп баргандыр, будкада ут янгач, карарга булгандыр. Икенче көнне исә карурманда, кешесез җирдә М. тушенка банкасын җылытыр өчен кечкенә генә учак якмакчы булган. Һәм тагын уңышсызлык! Өч минуттан инде ул полиция машинасында утырган, штрафка тартылган. Шәһәр буасында су коенырга җыенгач, аны өченче тапкыр полиция алып киткән һәм тагын штраф салган. М. аптыраган, үзен көн-төн күзәтәләр, дип уйлаган, өзелеп үз иленә кайтып китәсе килгән.

Гамбургта ул Казан университетында укыган немец кызына өйләнгән якташын очраткан, ул инде беркатлы татарның күзләрен ачкан. Әгәр немец тәртип бозуны күрә икән, ул шундук полиция номерын җыя. Үзе беркайчан да борынын тыкмый. Бу – полиция эше! Ул шулай ук музыка яки телевизор тавышын әкренәйтүне таләп итеп диварга шакымый, тиешле җиргә шылтырата гына.

Моннан шул аңлашыла: «әләк-донос», төрле җиргә күчеп йөреп, начарга да, яхшыга да әйләнә ала икән. Менә шундый фокус-покус. Минем ишеткәнем бар, Японияда әләккә мөнәсәбәт нәкъ Германиядәге кебек. Франция законнары исә 1791 елда ук гражданлык доносы (délationcivique) турында төшенчәне рәсмиләштергән. Революцион законнар хәзерге француз хокукында да сакланган.

Безнең менталитет исә башкарак. Без тәртип яки кагыйдә бозучыны, җинаятьчене үзебез тотарга, аның танавына тондырырга һәм җавап алырга – үзебезгә дә суктырырга тиеш. Менә шундый эчкерсез, самими безнең күңелебез, шунлыктан төннәр буе әләк язучыларга яки тавышларын танытмаска тырышып телефоннан шалтыратучыларга без җирәнеп карыйбыз.

PRESSA.RU

КӨЗ: ДӨНЬЯГА БАШКАЧА КАРЫЙ ТОРГАН ВАКЫТ

«Бу дөньяда без бернигә дә хуҗа түгелбез. Бары вакыт-вакыт кешеләр һәм әйберләр бер-берсе белән табышалар гына». Никтер көзгә кергәндә Трумен Капотеның «Завтрак у Тиффани» әсәрендәге бу цитата аеруча актуаль яңгырый башлый. Һәм китаплар, фильмнар, музыканың да вазыйфасы үзгәрә. Яз белән җәйнең үз тантанасы – бу ике фасыл барлыгыңны тулаем биләп ала. Кыш исә Яңа еллы, Раштуалы, ылыс-мандаринлы сулышы, җете аклыгы белән юата, рухны күтәрә. Ә менә көз, җылы свитерлар, пледлар белән беррәттән, җәйдән кырысланып, суынып өлгермәгән күңелне җылытыр өчен, параллель дөньяларга сусау уята. Китаплар, фильмнар, музыкаль альбомнарга...

Автор:
Луиза Янсуар

Шуңа, бер дә шикләнмичә, бу юлы һәр өчесен берләштерергә булдык – көзге әдәбиятны, фильмнарны һәм, аңлашыла инде, аларның аһәңен – музыканы. Традицияне бозып, төп рольне галиҗәнап кинога һәм көзнең төп лейтмотивы булган музыкага биреп.

ТИФФАНИДА КУНАКТА

«Тиффани» турында сүз чыкса, гадәттә, киносын күз алдына китерәләр. Һәм, әлбәттә инде, Генри Манчини музыкасын, фильмның, заманча итеп әйтсәк, төп саундтрегы булган Moon River («Лунная река») җырын. Аны да, нигездә, төп героиня – ул елларның культ дәрәҗәсендә йөргән актрисасы Одри Хепберн башкаруында ишетеп.

1961 елда экраннарга чыккан фильмның режиссеры Блейк Эдвардс аның бу дәрәҗәдә популяр булачагын һәм Америка кино сәнгатенең җәүһәренә әвереләчәген күз алдына да китерми. Әлбәттә, һәр режиссер хыялланганча, уңыш казаначагына өметләнә. Әмма бу кадәресенә – юк.

Күпчелек кино тәнкыйтьчеләре фильмны шактый самими мелодрама буларак бәяләргә гадәтләнгән, әмма миллионлаган фанатлар өчен ул әле – феминизм күрсәткече һәм аннан соң киләчәк хиппилар, хипстерлар буынының беренче карлыгачы да. Моннан тыш, Америка хыялына һәм Нью-Йоркча яшәү стиленә гимн.

Нью-Йоркны яулап алырга килгән һәм үз бәхетен калын кесәле химаячеләр хисабына эзләргә мәҗбүр булган провинциалка язмышы безнең аннан соңгы совет кинематографына да, хәзерге поп-сериаллар белән арт-хауска да ят түгел. Әмма АКШ экраннарына «Тиффани» чыкканнан соң дистә еллар үткәч тә, бездә ул күпкә йомшартылып, һәм әхлакый кысаларга сыйдырышлы итеп бирелә әле. Әйтик, заманында бик популяр булган «Москва слезам не верит» фильмы. Юкка гына ул үз заманында «Оскар»га тәкъдим ителмәгәндер дә. Мәскәүне яуларга килгән Катя язмышы Холли язмышына шактый якын. Әмма ул, иң яхшы совет традицияләре рухында, «үз бәхетен үзе төзүче». Америкада аны беренче булып караучылар, кем белә, бәлки, СССРда моның шулай була алуына ышанганнардыр да.

Холли Голлайтли, беренче карашка, җилбәзәк, җиңел акчалар артыннан куучы гадәти туташ. Һәрхәлдә, аның күршесенә килеп урнашкан Поль Варжак исемле язучыга ул беренче карашка шундый булып тоела. Телефонының кайда икәнен дә белмәгән, атнаның кайсы көне булуын оныткан, төрмәдәге мафиозига акча өчен хәбәр җиткерергә йөргән, кысан гына фатирында шау-шулы бәйрәмнәр оештырган, песиенә исем бирергә дә кирәк тапмаган кызый турында тагын ни уйларга була, йә?! Һәм Варжак тиешле бәясен бирә дә.

Әмма аның үзенең – инде бик күптәннән бер генә яңа әсәр дә язмаган язучының – көзге моңсу кичләрнең берсендә нәкъ менә Холли чын йөзен ача. Баксаң, Поль Холлиның үзеннән бер генә дә аерылмый: фатирда сөяркәсе хисабына яши, иҗатында кризис кичерә, әмма моны танырга теләми, мин-минлеге исә – чиктән ашкан. Нәкъ менә шушы кичтә Холли аның язу машинкасында күптәннән кәгазь булмавына ишарә ясый, һәм Польны Фред дип атый. Фред – аның армиядәге энекәше. Фред тиздән кайтырга тиеш. Фред-

ны кеше итәргә кирәк! Ул – Холли өчен бердәнбер кадерле зат. Холли үзе матур тормыш эзләп, провинциядә калдырып киткән олы яшьтәге иреннән кала...

Әмма Tiffani салонына күпме генә йөрсә дә, матур, җитеш тормышка күпме генә ирешергә тырышса да, акчасы булган чыгымнарын капларга да җитми Холлиның. Шулай ук – Поль Варжакның да. Һәм менә бу икәү, бергә очрашкач кына, үзләре кайчандыр ышанган Америка хыялының асылда нинди булуына төшенәләр дә. Дөрес, аларга моңа төшенергә Холлиның провинциядәге тормыш иптәше дә килеп ярдәм итә. «Син үзеңне иректә һәм кыргый дип уйлыйсың. Сине читлеккә утыртырлар дип куркасың. Балакай, син инде болай да – читлектә...»

Читлекнең асылда ни икәнен абайлаган Холли белән Поль фильмның азагында, көзге яңгыр астында чылана-чылана, иреккә (асылда, билгесезлеккә) җибәрелгән җирән песине эзләп табалар һәм аңа исем кушалар. Димәк ки, тормышның аяусыз кануннарын инкарь итүдән туктыйлар. Димәк ки, реаль чынбарлыкка анык караш белән карый башлыйлар. Романтик финалсыз булмый Голливудта. Һәм – җанны өзәрдәй музыкасыз да.

Әмма мин Трумен Капотеның әсәренә өстенлек бирер идем. Голливудны үз күзләре белән күргән, андагы актрисаларның тормышын белгән, Одрига – дус, Мэрилин Монрога иң кыен чакларда терәк булган, һәм бу аяусыз чынбарлыкны бар чынлыгында прозасында тасвирлый алган Капотеның каһарманнарына да. «Ясень с видом деревенским приобщился к вальсам венским, он прорвется, Александра, он надышится Москвой» – «Москва слезам не верит» фильмы, хәтерлисездер, шушы җыр белән тәмамлана. Асылда, фильм традицияләре – бер. Голливудта булсынмы, СССРдамы, постсовет пространствосындамы. Әмма тормыш чынбарлыгы – әсәрдәге чынбарлык – фильмдагы ванильдән азат булуы, тормышчан булуы, катгый булуы белән әһәмиятлерәк.



Заманча гламур эстетика «Завтрак у Тиффани» фильмына яңа сулыш өрде, ул хәзер аңа охшаш яңа клоннар белән баеды: «Дьявол носит «Прада», «Не родись красивой», Сергей Минаев әсәре буенча куелган «Duxless» һ.б. Әмма безгә диагнозны инде ярты гасырдан элгәрәк Капоте куйган иде.

ГЕНРИ МАНЧИНИ ҺӘМ АНЫҢ АЙЛЫ ЕЛГАСЫ

1962 елда «Оскар» һәм «Грэмми»га лаек булган «Лунная река» композициясе Джонни Мерсер һәм Генри Манчини тарафыннан махсус Одри Хепберн героинясы өчен языла. Берара җырны фильмнан «кисеп ташлау» турында сүз чыга. Әмма Хепберн кистереп әйтә: «Бары минем мәетем аша гына!» – ди.

Двое бродяг, что пустились
в путь увидеть этот мир,
В котором так много всего,
что стоит увидеть,
Мы следуем за одним и тем же
концом радуги,
Ждущим нас за поворотом.
Мой верный друг,
Лунная река и я...

Бәлки, ул чакта Хепберн киностудия белән якалашмаган булса, безнең күзләрне җылытучы, яктыртучы бер шедеврдан мәхрүм булыр иде дөнья.

ЯБАЛАКЛАР – ЯБАЛАК КЫНА ТҮГЕЛ...

Минем өчен көзнең квинтэссенциясен Дэвид Линчның «Твин Пикс» сериалы тәшкил итә. Сериал дигәч, күз алдына иге-чиге булмастай тоелган очсызлы мәгънәсезлек кенә килеп басканга, аны болай атарга тел дә әйләнми. 90нчы елларның үзенә күрә бер символына әверелгән бу полотноны «Американы үзгәрткән фильм» дип тә атап йөртәләр.

Американы ничектер, белмим, әмма балачак-үсмерлек еллары үзгәртеп кору чорына туры килгән тулы бер буынның дөньяга карашын, чынлап та, әлеге картина формалаштырды, дисәм, ялгыш булмастыр. Кайчандыр Советлар Союзы территориясе буйлап таралып яшәгән халык «Будулай»ны, «Тын Дон»нарны карап хозурланса, безнең буынга баштарак шактый беркатлы-арзанлы «Рабыня Изаура», «Просто

Мария», «Богатые тоже плачут», «Санта-Барбара»лар тәтеде. Ә аннан инде бөтенләе белән дә Көнбатыштан ургылып, бәреп кергән ярымаңлаешлы-ярымаңлаешсыз концептлар белән тулы сериаллар бумы белән маңгайга-маңгай бәрелешү насыйп булды.

«Твин Пикс» шулар арасында иң сәере, шомлысы һәм чын-чынлап тетрәндергәне иде. Көзнең елап торган, кыраулап килгән бер кичендә күрсәтә башладылар аны. Хәтердә, пиар кампаниясе менә дигән итеп эшләнгән – көн дәвамында трейлерын берничә мәртәбә (хәер, ул чакта әле трейлер дигән сүзне белми идек без, рекламасы гына дия идек, гәрчә ул төшенчәне вә эчтәлекне Влад Листьев ТВдан «куып» чыгарырга тырышып караса да **– авт.**) әйләндерәләр, аннан – атна буена. Һәр серия атнага бер генә күрсәтелә бит. Йөрисең аннары киләсе сериягә кадәр мөлдерәмә тулып-тулышып.

Кыскасы, тинейджерлар тормышыннан идиллик булмаган картиналар рухында башланып киткән бу сериалның тора-бара яңадан-яңа катламнары ачыла башлады. Детектив мистика белән керешеп китте, мистика, үз чиратында, нәкъ менә Линч эстетикасына гына хас булган башваткыч-ребуска, квестка әверелде. Һәм көз буе, кыш буе шулай дәвам итте. Шул көздән соң инде без – «Твин Пикс» һәм Дэвид Линчның мөкиббәннәре – элеккеге булудан туктадык. Әйтерсең, үзенә күрә бер инициация үттек, масон ложасына кабул ителгәндәй, каһиннарга әвереләдек...

Беренче караганда, фильмның, әлбәттә, иң өске катламдагы сюжеты җәлеп итә – ФБР агенты Дэйл Купер килеп төшкән Канада чигендәге кечкенә генә шәһәрчектәге проблемалар. Бу алымны без инде Артур Конан Дойл, Агата Кристи әсәрләреннән, Артур Хэйли романнарыннан да белә идек – йомык пространство, җинаять вә шул төеннең чишелеше. Әмма Линчның төене андый җиңел генә булса, ул Линч булмас иде! Һәм менә чираттагы серияләрнең берсендә ул безгә беренче табышмакны ташлый – «Совы это не то, чем они кажутся». Аннары табышмаклар берсе артыннан берсе кабатлана башлый. Һәм син аңлыйсың – фильм бөтен Америка, ә аның артыннан Россиянең зәңгәр экраннары артында утыручы тамашачылар тилерер дәрәҗәгә җитеп җавап эзләгән проблема – «Лора Палмерны кем үтергән?» проблемасы турында түгел, ә бөтенләй башка.

Бу сериалдан, бер карагач, кире «китеп» булмый. Кайта-кайта караган саен исең китә һәм менә син, ниһаять, аңлыйсың: «Твин Пикс» Америка һәм инде хәзер безнең дә капиталистик чынбарлыгыбызга зур бер пародия икән. Ничек итеп аң катламы әле башта кабул итеп бетерә алмаган бу ваемлау теге чакта ук баш миенең кайсыдыр бер өлешен ялкынсындыра алды икән?! Әле фильмның беренче катламын гына күрә башлаган чакта ук?! Күрәсең, режиссерның даһие нәкъ менә аң катламы артында яшеренгән рецепторларга кешенең үзенә дә сиздермәстәй итеп тәэсир итә белүдә.

Фильм тоташ цитата-реминисценцияләрдән тора – Көнбатыш һәм Көнчыгыш мәдәниятләренең нигезен тәшкил иткән, Линчның кызыксыну объекты булган барлык кодлар да яшеренгән анда. Әйтик, агент Куперның Лора Палмерны үтерүчене индукция һәм дедукция алымнарын кулланып чишәр өчен тулы бер полиция составын урманга алып чыгып китүе, анда аларга Далай-Лама һәм Тибет турында лекция укуы, урман эчендәге ташландык аланга килеп урнашкан Уиндом Эрлның биредәге рухлар белән бәйләнешкә флейтада уйный-уйный керүе. Ә инде Ак Вигвам белән Кара Вигвам, ягъни Король Артур җырләнгән Глостенбери урманының мистик игезәге буларак тәкъдим ителгән 12 сикомор үсеп утыручы портал – болары безне гомумән дә друидлар ритуалларына һәм мистерияләренә алып китә...

Линчның сорауларына җавапларны беркайчан да табып бетереп булмый. Һәрхәлдә, минем өчен «Твин Пикс» – әле һаман да башваткыч. 1993 елда Россия телевидениесе беренче тапкыр күрсәткәннән башлап, һәр көзне карыйм һәм сорауларның кимегәне, тәмәнең җуелганы юк. Кемнәр Линч дөньясына аяк басып карамаган, нәкъ менә «Твин Пикс»тан, яисә аның тагын бер көз тәме белән өретелгән фильмы – «Малхолланд драйв»тан башларга тәкъдим итәр идем.

Һәм бер искәрмә: Линчка аппетит өстәл артына утыргач барлыкка килә. Авыз итеп карауга, йөзне чытып, ваз кичәргә ашыкмагыз.



«БУ ГАҖӘЕП АНДЖЕЛО!»

Линч фильмнары йолдызлы составы белән дә уникаль. Изабелла Росселини, Кайл Маклахлен, Шерил Ли, Шерилин Фенн, Наоми Уоттс, Билли Зейн, Хэзер Грим һ.б. Шулай ук аларның тагын бер магиясе – бер фильмнан икенчесенә күчеп йөри торган кәрләләр, әзмәверләр. Әйтерсең, бу режиссер заманында әкиятләрдә, риваятьләрдә сурәтләнеп, инде хәзер югалды дип исәпләнгән чынбарлыкны «торгызып карап» уйный. Һәм синең карашыңның фокусын үзгәртә – кинәт сиңа урамда Твин Пикста яшәүче Дама с поленом очрый, каршыңда торган чия пирогы һәм каһвә аша сорауларыңа җавап табыла...

Линч тудырган дөньяның иң әһәмиятле визит карточкасы – фильмнарының саундтреклары. Анджело Бадаламенти исемле композитор белән күп елларга сузылган иҗаттәш һәм шәхси дуслык нәтиҗәсе булган әлеге санудтрекларны хәтта Линч фильмнарын карамаган кешеләрнең дә ишеткәне бар. Ә ике дус бергәләп алган «Грэмми» – халык мәхәббәтенең бер чагылышы гына. Дуслык үзе нәкъ менә «Твин Пикс» төшерелгәндә чын-чынлап ныгый. «Бу гаҗәеп Анджело!» – дип атый үзенең дустын Америка ТВсына биргән бер интервьюсында Линч. Чыгышы белән Сицилиядән булган композитор белән Америка провинциясендә үскән Линчны дөньяга бик якын эстетик карашлар берләштерә. Бадаламенти музыкасы булмаса, мөгаен, Линч полотнолары аша бу дәрәҗәдә инфернальлек бөркелеп тә тормас иде.

Аларны «исәрләр» дип атыйлар. Әйтик, нинди максат белән бу икәү, көннәрдән бер көнне җырлый-җырлый, сикерә-сикерә, Беверли-Хиллзның Малхолланд драйвы буйлап узарга уйлый? Җитмәсә, әле үзләрен видеога төшереп? Аны Ютубка элеп?

Әйе, икесе дә – эпатаж осталары. Икесе дә – дөньяның сүрүен сүтеп, аның икенче ягына чыгып-кереп йөрергә ярата. Чөнки беләләр – бу дөнья бер генә яссылык белән чикләнми.

«Твин Пикс» Дэвид Линчның кызы тарафыннан язылган «Тайный дневник Лоры Палмер» һәм Скотт Фростның «Воспоминания специального агента Дэйла Купера» китапларына нигезләнгән. Әмма болар – этәрелеп китү ноктасы гына, сериалның төп тукымасы нәкъ менә Линчның авторларча стиле, карашы, «фишка»ларыннан тукылган. Шуңа да, китапларга түгел, ә игътибарыгызны, иң беренче чиратта, фильмның музыкасына юнәлтәсем килә...



КӨЗ УЛ – ДЖАЗ...

Һәм аның тагын бер корифее – Харуки Мураками. Бу очракта инде без, традицияне яңадан кайтарып, векторны романнан – музыкага, романнан кинога таба билгелибез.

Муракаминың кайсы гына романын алма, ул безнең яңгырап торган ялгызлыгыбызга турыдан-туры ишарә. Дуслар арасындамы без, гаиләбездә – туган-тумачалар янәшәсендәме, эштәге коллегаларыбыз тирәлегендәме –һәркайсыбыз аерым бер галәм. Безнең аша үтәләр-сүтәләр, без – кемнәрдер аша... Көздә бу халәт аеруча сизелә.

Темасы яңа да түгел кебек югыйсә, экзистенциалистлар аны рәхәтләнеп әвәләде инде. Әмма Муракамида ул барыбер янача. Мин аны тыштан бик минималистик, гадәти күренсә дә, эчендә исә катлы-катлы, ящерен тартмалар вә юллар белән чуарланган зур гына бер комодка тиңләр идем. Кайсы гына тартманы ачып җибәрмә, эзләгән-көткәнеңнән күбрәккә юлыгасың.

Әйтик, гадәти бер яшүсмернең өен ташлап чыгып китүеннән башланган «Кафка на пляже» әсәрендәге фабула кинәт, көтмәгәндә-уйламаганда, бик күп кешеләрнең язмышларын тоташтыра да, әлеге малай белән Наката-сан исемле песиләр белән сөйләшә белүче исәррәк картка дөньядагы тигезлекне кайтару бурычын йөкли. Йә булмаса, «Хроники заводной птицы» әсәрен алыйк. Гади генә, урта яшьләрдәге ир-атның шулай ук песиен эзләп күрше йортлар арасындагы ташландык бер утарга барып чыгуы берничек тә Маньчжуриядәге сугыш вакыйгаларына китерергә тиеш түгел иде шикелле. Әмма – китерә. Алай гына да түгел, бу гасыр, чор кешеләрен андагы вакыйгаларның чишелеше өчен җаваплы да итә. Сүз уңаеннан: Линчның ябалакларыдай, Муракаминың песиләре дә – ике дөнья арасындагы арадашчылар. Капоте мәчесе дә – каһарманнарны реаль тормышка кайтаручы илче икәнен дә искә алсак...

Муракамидагы төп үзенчәлек шулдыр, мөгаен: аның вакыты горизонтальдә ятмый, Мебиус лентасымы шунда ул, кыллар теориясенең (теория струн) чагылышымы. Һәрхәлдә, син беркайчан да хәрәкәт, димәк ки, сәяхәт итүдән туктамыйсың. Беркайчан да тыныч кына була алмыйсың: һәр адымың, һәр ымың, һәр гамәлең җиһан системасына, машинасына (компьютерына диярргә, бәлки) «көйләнгән», барысы да бүген һәм шушында хәл ителә. Бу әсәр каһарманнарына коточкыч җаваплылык өсти кебек. Ләкин алар салкын канлы, аек акыллы, хәтта ваемсыз диярлек булып кала бирә белә. Менә шуның аша Мураками безгә замана кешесенең портретын күрсәтә дә.

МУРАКАМИ МУРАКАМИ БУЛГАНЧЫ...

Бу суперпопуляр япон авторының әсәрләрен миллионлаган укучыга яраттыра торган тагын бер сыйфат – Муракаминың әсәрләреннән музыка агыла. Берәзлексез!

Өстенлекне ул классикага һәм классик джазга бирә: әйтик, Леош Яначекның «Симфониетта»сы, Джоакино Россинининың «Сорока-воровка»сы, гасыр башының даһи джазменнары Чет Бейкер, Чарли Паркер, Бенни Гудмен, Майлз Дэвис, Луи Армстронг, Билли Холидей, Нэт Кинг Коул, Элла Фицджеральд... Җитмәсә, барысы да уникаль, раритет язмаларда, без хәзер Интернеттан тыңлаган музыка түгел бу, Мураками музыканы бүгенге иң алга киткән технологияләр заманында да тәлинкә-пластинкадан, ягъни винилдан гына тыңлый. Аның тәлинкәсендәге энә, иске бер җөйгә юлыгып, сикереп китеп, бөтенләй башка юлга күчкәндәй, әсәрләрендә дә – тоташ күчеш, метаморфозалар, тоташ убылулар.

Мин бүген Муракаминың әдәби әсәрләренә тукталып торырга теләмим. Сезгә, көзегезне тәмлерәк итәр өчен, аның «Джазовые портреты» китабын һәм әсәрләрендәге музыканы берләштергән, туплаган дискларны тәкъдим итәм.

Яшьлегендә, әле язучы булачагын күз алдына да китермәгән чорда, Харуки Мураками джаз-барда эшли, соңрак ул бу барның хуҗасына да әверелә. Язучы бүген гаҗәеп бай джаз коллекциясе белән чын мәгънәсендә горурлана ала. Һәм менә бу китапны да ул джаз сөючеләргә бүләк буларак тәкъдим итә – Макото Вада исемле иллюстратор белән берлектә, алар

үзләренең эстетикасын тәрбияләгән һәр даһи джазменны ягымлы, сөйкемле, бераз гына юмор, ностальгия һәм үтә бер ярату белән сурәтләп, укучыга да яраттыралар.

PRESSA.RU

«Коровы на водопое» картинасы. А.Н. Степанов.

АКМАҢГАЙ

Язучы Нәбирә Гыйматдинованың юбилее уңае белән, сезгә аның Татарстан китап нәшриятында яңа гына басылып чыккан «Сөйлим, тыңла...» китабында тупланган хикәяләреннән берсен тәкъдим итәбез. Әдибәгә киләчәктә дә иҗат уңышлары телибез!

Автор: Нәбирә Гыйматдинова

– Му-у-у...

Аның «җыры», дулкын-дулкын булып, тирә-юньгә таралды. Дөнья яңгыратып мөгрәмәде ул, нибары «у-у» дигән авазлар белән генә «көйләде». Мондый илаһи тынлыкны бозалар димени! Әй, рәхәт тә соң! Беркем дә «Әйдәгез, әйдә, мәхлуклар» дип, арттан кумый, беркем дә колак төбендә чыбыркы шартлатмый.

Бүген аны авыл көтүенә кумадылар, бүген дә үз иркенә җибәрделәр. Чөнки хуҗалары ышана: Акмаңгай – акыллы хайван, тәртип бозмый, иген кырын да, хуҗалыкларның бакчасын да таптамый, елан кебек бормаланып яткан бердәнбер сукмагыннан аланга гына юырта.

Иртән генә ләйсән яңгыр явып узды, шуңа күрә үлән яфракларында җемелдәгән чык бөртекләре, кояш нуры белән куышып, күзне камаштыра... Акмаңгай кинәт кенә күшәвеннән туктап калды. Менә ничәнче көн инде урман артыннан сәер гөрелдәүләр ишетелә. Бу нәрсә икән соң? Шуны беләсе килеп угаланса да, ул хуҗалары тамгалаган биләмәдән читкә тайпылырга җөрьәт итмәде. Син башбаштак, дип, бөтен урам чырае күрсәтмәсләр! Әмма кызыксыну көчәйгәннән-көчәя, хәзер инде ул мөгездән тоякка кадәр төшеп җиткән, аңа карышу мөмкин хәл түгел иде.

Акмаңгай авызындагы ризыгын ашык-пошык йотты да, тәвәккәлләп, урман эченә томырылды. Аланда гына тулганып, урманның көчен бәяләмәгән икән: галәмәт куе икән ул, галәмәт зур икән. Мөгезе белән куак ботакларын аралый-аралый юл ярып хәлдән тайса да, ул ниятеннән кайтмады. Алда исә тамаша: чакрым баганасы хәтле генә ераклыкта өсте ябулы корылмалар тезелешкән иде. Акмаңгай аларның ферма икәнлеген чамалый. Димәк, хуҗасы Фәндәс һәр иртә, тракторын кабызып, шунда ашыга икән! Корылмасы... гадәти нәрсә инде, ә менә аның тирәсендә булышкан әкәмәт җанварларны кемнәр дип атарга икән? «Болар кайсыдыр ягы белән миңа охшаган да, охшамаган да... Бер үк тегүчедән тектереп кигәннәрмени, һәммәсе дә аклы-каралы, үзләре койрыксыз, үзләренең башында мөгез дигән «таҗлары» да юк. Үзләре Акмаңгай кебек үк «му-у-у» диләр тагы. Алларында печән, тик нигәдер ул кипкән, гадәттә андыйны кыш айларында гына салалар, әле бит җәй, болыннарда котырып үлән үсә!

Иң кырыйда – койма читендә – берсе ялгыз гына моңая иде, Акмаңгай шунда таба китте. «Әкәмәт» тә аны күзәтә иде. Алар шулай бер-берсенә озак кына сынап карагач, Акмаңгай:

– Иптәш, син кем? – дип сорап куйды.

– Сыер, мадам.

– Кит аннан! Мин дә сыер. Исемем – Акмаңгай. Ә синеке ничек?

«Әкәмәт», гаҗәпләнеп:

– Нәрсә соң ул исем? – диде.

– Һи, җүләр! Хуҗабикәң кушкан ат инде! Ул сиңа иркәләп эндәшәдер лә?!

– Үнөчле мин, колагымдагы язуны укы, мадам!

– Һи, сан, имеш! Исемсез нинди хайван инде ул? – Акмаңгай шикләнеп: – Син тучны сыермы соң? – диде.

– Сөтемне саугач, сыердыр инде, мадам.

– Мадам да мадам дип ят сүзләр кыстырмале! Үзебезчә, татарча сөйләш! Бәй, әллә син безнең татар сөтлебикәсе түгелме?

– Без – чит илдән кайтартылган нәселле токым! – «Мадам» мөгезсез башын горур гына өскә чөйде. Аның күз карашында тәкәбберлек һәм мин-минлек шәйләнә иде. Акмаңгайны түбәнсетте бу «койрыксыз», ләкин «авыл бичәсе» гарьләнүен сиздермәде. Аны беркем дә ирексезләмәде, ул үзе урман ерып килде, шуңа үпкәләргә хакы да юк иде.

– Әйдә, чык, аланда ямь-яшел үлән, авызда шикәр төсле эри, – диде ул, артка чигенеп. Койма аша гәп куерту уңайсыз, аннан битәр хуҗасы Фәндәс абзыйның күзенә чалынсаң, эш харап иде.

«Үнөчле» моңсу гына мөгрәде:

– Ярамый...

– Нишләп?!

– Без тоташ ябылуда гына яшибез.

– Бәтәчулла! Нәселле дигәч тә, урларлар дисеңмени? Тансык, ди сез! Авылда болай да йорт саен өчәр сыер. Көтүдә йөртмиләр мәллә?

– Нәрсә соң ул көтү?

Акмаңгай койрыгы белән шапылдатып корсагына сукты.

– Үлеш! Көтү нәрсә диме?! Без, авыл сыерлары, зур төркемгә оешып, көнозын сахраларда йөрибез. Әле пыяла минем тояк итен яралаган иде, шул сәбәпле хуҗаларым көтүгә чыгармады. Төзәлгәч барам! Анда күңелле!

– Бездә дә күңелле анысы. – «Әкәмәт» нәселдәшенә ымлады. – Без дә сезнең кебек серләшәбез, җаныбыз тыныч. Ниемә ул ирек! Бүре очраса, ничек качып котыласың, ди?!

– Һи, җүләр! Бүре очрасамы? – Акмаңгай башын уңлы-суллы чайкады. – Очлы мөгезләрем белән кадап корсагын тишәм мин аның!

– Кигәвен ише бөҗәкләр каныңны суыра ди әле.

– Койрыгым белән чәпәсәм, ун кигәвен кырыла! – дип гайрәтләнгән Акмаңгай кисәк авызын йомды.

«Үнөчле» ямансулап башын аска игән, ул яңа танышы мактанган «кораллардан» мәхрүм иде шул.

– Кайгырма әле син, мөгезең дә, койрыгың да булыр... Син яшь бит, – дигәч, тегесе:

– Булмас инде, – диде. – Кальций дигән витамин сөттә күбәйсен өчен, артык җирләребезне кисеп ташлыйлар...

PRESSA.RU

– Табигать безгә артык әйберләр тагып мәшәкатьләнмәс иде! Йә, борыныңны салындырма, син болай да матур! Безнең кебек төсе уңган кызгылт киемнән йөрмисең, тирең ефәкмени – ялык-йолык итә. Үгез әфәнделәр үлеп гашыйктыр әле сиңа.

– Үгез? Бездә андый зат күренми! – «Унөчле»нең төймә кебек түгәрәк күзләре тагын да зурайды. – Кем ул, нишли ул?

Акмаңгай кызарса да, кызыл йөзендә ул күренмәс иде. Бу мәхлукка үгезнең кем икәнен ничек төшендерергә икән? Көтүдә гайрәтле Батырҗан бар... Ул һәммәсен дә тигез ярата... Сөтлебикәләр аңардан биһуш...

– Син соң... – Акмаңгай оялуыннан нишләргә дә белмичә, тоягы белән җирне тырмаган булды, – бозаулыйсыңдыр ич?

– Бозауладым, күрсәтмәделәр генә. Аерым аранда тәрбияләлиләр.

– Үгездән башка гына нәсел үрчеми инде ул...

Чит мәмләкәттән килгән «унөчле», укымышлы «халык», Акмаңгайның кая суктырганын аңлады:

– Шуны әйтәсеңмени, – диде. – Ул эш бездә ясалма юл белән башкарыла.

– У-у-у, мәхәббәттән мәхрүм икән сез, алайса, – дип, аяныч тавыш белән мөгрәде Акмаңгай. Җуләр, тагын хаталанды, тагын саксыз сүз белән аклы-каралы танышының йөрәген яралады. – У-у-у, сез бәхетле икән, көндәшлек утында янмыйсыз икән. – Юри шулай такмаклады, юкса көтүдә беркем беркемнән көнләшми иде. – Кызганыч, син токтынлыкта, Батырҗан сине дә ошатыр иде... Әллә киртәне җимеримме? Безнекеләр белән күрешер идең...

Акмаңгай койманы мөгезе белән этәм дигәндә генә калай зеңгелдәде. Зең-зең... Зең-зең...

– Төшке тәгамгә чакыралар, – диде «унөчле». – Вакытында ашамасак, тагарак автомат рәвештә ябыла. Иртәгә кил! Кил, зинһар, Акмаңгай!

Акмаңгай өенә ашыкты. Баягы кичерешләрдән аның башы әйләнә иде. Хуҗабикәсе чиләге белән абзарга алма күтәреп керде һәм аның муенынан сыйпый-сыйпый:

– Кимер, матурым, сөтең балланыр, – диде. – Терелдең инде, иртәгә көтүгә куарбыз, матурым.

«Матурым»ның исә үз хәсрәте хәсрәт иде. Вәгъдәсе җилгә очар микәнни? Көтүдән качулары бик икеле... Акмаңгай тәҗел кирәк чакта мөгез очы белән капка келәсен шудыра иде, иртән, кояш уяныр-уянмас кымшанган арада, ул әкрен генә урамга чыгып тайды. Бу юлы калын урманны ашкынып-ашкынып ерып барды ул. Ләкин киртә янында «унөчле» күренмәде. Инде борылам дигәндә генә, таныш мөгрәү колак яфрагын иркәләде.

– Му-у-у... Гафу ит, Акмаңгай, яңа гына саудылар.

– Хуҗабикәңнең кулы йомшакмы соң? Минекенеке мамык төсле...

– Заманнан артта сөйрәлмә, сыерларны күптән машина сава! – «Унөчле», киресенчә, аны җуләрләнгән дип уйлады.

– Ай, харап икән! Оператор, диген кызый! Андук шикләндем, фермагызда хатын-кыз заты күренми. Хуҗам Фәндәс шулайрак диген иде шул. Кул белән савуга җитми инде, тәнеңә ничек тимер ыргаклар белән кагылдырмак кирәк.

– Тикмәгә генә чит ил хәтле чит илдән ташымаганнардыр, хикмәтледер инде сез?

– Без бик күп сөт бирәбез.

– Без дә кимен куймыйбыз инде анысы. Табыш дип инде... мөгезне сындырмыйлар, койрыкны кисмиләр.

Авыл көтүе Акмаңгайның телен генә чарламаган, ул анда йөри-йөри сүз көрәштерергә дә остарган иде. «Унөчле»дән ризалык та сорамыйча, Акмаңгай мөгезе белән койманың читен ишәргә тотынды. Алар, җил белән куышып, урман кочагына атылды. Юлдашы, чын мәгәр, сабый инде: агачта тукылдаган тукранга шаккатты, түмгәктә мыжлаган кырмыскаларга аздан гына борынын тыкмады, ботактан ботакка сикергән тиен баласына әсәренде. Бигрәк тә ул шау җиләкле аланга хәйран калды. Ямь-яшел үләнне керт-керт өзеп, тел өстенә салгач:

– Шәп деликате-е-ес, – дип сузды.

Акмаңгай кояш кыздыруыннан чамалады: көннең кыл уртасы. Хәзер авыл көтүе Хан елгасына төшәчәк.

– Кузгал, дустым, – диде ул. – Мин сине хәзер карендәшләрем белән таныштырам.

Сөтлебикәләр, «Унөчле»не күргәч, башта «җен, җен» дип, койрык чәнчешеп, тирә-якка сибелде. Акмаңгай аларны «Әдәпсезләр! Затсызлар!» дип тиргәгәч, сыер халкы, янә җыелышып:

– Кем соң син? – дип сорады.

Бөрешебрәк калган «Унөчле», кыяр-кыймас кына:

– Сыер мин, – диде.

– Рас, ул безнең кебек үк сыер! – дип куәтләде Акмаңгай.

– Му-у-у, – диеште сөтлебикәләр, мөгезең белән койрыгың кайда соң?

– Илле бүре белән сугышканда сындырган-өздергән!

Акмаңгай тагын нәрсә дисен инде? Киләчәктә безне шундый кырыкмыш токым алмаштырачак дисә, бичараларның йөрәге ярылып егылып үләчәкләр бит.

– Исемең ничек? – дип сорады Карлыгач атлы бичә, ул көтүдә иң тыйнагы иде.

Юлдашы ык-мык килгән арада Акмаңгай чатнатып:

– Мадам ул! – диде.

– Күркәм исем, – диеште халык.

Ул да түгел, яр астыннан Батырҗан күтәрелде. Аның күзләре очлы иде, Мадамны шунда ук шәйләп алды. Дөньяның бөтен хикмәтләрен күргән, төрле җирләргә «кунакка» чакырылган Батырҗан аклы-каралы яңа сыерга шаккатмады.

– Кунак кызы бар икән, – диде ул. – Көн эссе, тирләтә, әйдә, минем белән берчәк йөзеп ал...

Һәммәсе дә Мадамга юл биреп читкә тайпылды. Батырҗан ике әйттергәнне яратмый иде.

...Иртән Акмаңгай уң колагы белән тыңлап ятты. Абзар ишеге төбендә хуҗа белән хуҗабикә сөйләшә иде:

– Фәндәс, Акмаңгайга ниндидер зәгыйфь хайван ияреп кайтты. Ни кусам да китмәде.

– Нәселле сыердыр ул, Румия. Ярты ел элек Франциядән кайтардылар. Күндәм алар, мин бит шуларга азык ташыйм.

– Тизрәк урынына илт, Фәндәс! Урлаган диярләр!

– Димәсләр, хатын! Алла үзе китереп кертте аны безнең йортка. Комплекс директоры Әшрафиев хезмәт хакы исәбеннән бирәр сыер бирәм дигән иде. Бирде дип сана! Үзең бит, ике-өч сыер да саумагач, авылда ник яшәргә дисең! Рәхәтен күр менә!

Сап-сары салам өстендә җәйрәп йоклаган Мадам, әлбәттә, аларны ишетмәде. Кичәге күңелле сәяхәт аны бик арыткан иде. Беркатлы Акмаңгай: «Авылда яшәсә, дустыма мөгез дә, койрык та үсәр әле. Мәрхәмәтле Табигать, шәт, адәмнәрнең хатасын төзәтер», – дип уйлап куйды.


Чистай
Чистай Выселкасы
Каргалы
Татар Гаделшасы

Фото: Ната Смирнова

ЧИСТАЙ РАЙОНЫ

«ЧИСТА КЫР» МЕЦЕНАТЛАРЫ

«Чиктән тыш катлаулы, билгесезлек белән өретелгән каршылыклы хисләр белән якынлаштым мин Чистай пристаненә...» – дип язган 1868 елда танылган журналист Николай Демерт һәм үзенең бу өяз шәһәрендә бераз гына торып алуы хакындагы кызыклы язмаларын соңыннан бастырып та чыгарган.

Аннан соңгы 150 елга якын гомерендә Чистай шундый ук булып кала бирә – ул һаман да «өяз» вакыйгалары үзәге. Бер үк вакытта кунакчыл һәм ябык та, шатлыклы һәм сагышлы да, аңлаешлы һәм серле дә.

PRESSA.RU

Автор:
Олеся Бондаревская

«ЮКӘ ТАВЫ»НДАГЫ ХӘЗИНӘ

Каманың текә ярындагы Чистай элеваторы корылмалары тирәсендә – Бөек Идел Болгары шәһәрләренең берсе булган борынгы Җүкәтауның ныгытма урлары калдыкларына тамырлары белән береккән караңгы яшел әрәмәлек. Җүкәтау – ягъни юкә тавы, рус елъязмаларына Жукотина исеме белән кергән.

– Шәһәр урыны дип фаразланган территориядә берничә дистә ел дәвамында казу эшләре бара. Галимнәр Җүкәтауның X гасырдан XV гасырга кадәр яшәвен расладылар. Зурлыгы буенча Болгар, Биләр, Сувар һәм башка болгар шәһәрләреннән калышса да, ул ярыйсы гына эре шәһәр була. Җүкәтау Венеция һәм Каталониянең XIV гасыр диңгез атласларында күрсәтелгән, – дип сөйли Чистайның Тарих музее директоры Наталья Бикмуллина. – Төп һөнәрләренең берсе – чүлмәкчелек. Хәтта «брендлы» балчык савыт-сабалары да бар – монда табылган XIII–XIV гасырга караган дулкын сурәтле эшләнмәләрне галимнәр керамиканың «җүкәтау» тибындагы аерым бүлегенә керттеләр.

Хәзер исә чәчәк аткан чагында (Урда чоры), фаразлар буенча, 7 гектар мәйдан биләгән шәһәрне «Федераль әһәмияттәге һәйкәл-территория» дигән элмә такта гына хәтерләтеп тора. Аннары Чистайның тарих музеенда сакланган артефактлар бар. Мәсәлән, сфероконуслар – мунча өчен кирәкле майларны саклый торган керамик савытлар (балчыктан ясалган күпшә фрагменты да сакланган) һәм Җучи идарә иткән чордагы көмеш тәңкәләр хәзинәсе.

Тагын әле, кайбер чыганакларда әйтелгәнчә, XVII гасырда рус алпавыты Савва Аристов шушында ук, Кама буенда, нигезләгән үз авылына да Жукотино исемен кушкан. Бу авыл Чистайга «керү юлы»на әверелгән. Хәер, монысы бөтенләй башка тарих.

«Соңгы арада, яңа исправник эшли башлагач, урамнарга берничә фонарь куйганнар иде, әмма бу яңалыкның урнашуы шикле. Икенче көнне үк яки өченчесендәме ике фонарьны урлаганнар. Җирле статистиклар күзгә ике генә фонарь калыр, дип исәпли: исправник һәм аның ярдәмчесенең ишек төпләрендә; калганнары урланачак, чөнки Чистайда «һәркем – үзе өчен, Аллаһ – бөтенесе өчен» дигән зирәк әйтемне һәрчак истә тоталар». (Николай Демерт язмаларыннан)

МИЛЛИОННАРНЫ СУГА САЛУ

– Ул сезне тиз генә кертмәячәк, көтмәгез дә, – дип куркыта мине Чистай белән Михаил Сергеевич. Ул үзе – төп Чистай кешесе, хәзер оборонканың җирле оешмасы хезмәткәре. – Сез базарга чыгыгыз, иске-мосКы рәтләрен табыгыз. Андагы әйберләргә, кешеләргә карагыз, нәрсә турында сөйләшкәннәрен тыңлагыз. Скверларда утырыгыз. Никольск соборы янында басып торыгыз. Шул чакта Чистай, бәлки, сезгә нидер сөйләр. Ә болай, ашыгыч кына – ай-һай.

Иске-москы рәтләренә барып җитә алмадык, һава торышы мөмкинлек бирмәде. Аның каравы, шәһәрдәге беренче су суырту башнясын якыннан күрдек. Очындагы тимердән коелган флагчыгына караганда, 1886 елда ук төзелгән ул. Төзелешкә акчаны Чистайның бик бай сәүдәгәре, икмәк белән сату итүче, шәһәрнең танылган меценаты Василий Челышев гаиләсе биргән. Аннан берничә ел элегрәк ул Чистайга беренче суүткәргеч төзү өчен дә акча бүлеп биргән булган. Насос станциясе, сүз уңаеннан, XXI гасырга кадәр тугры хезмәт иткән.

Сәүдәгәрнең мирасы гына четерекле тарихка дучар булган. Ул үзе һәм хатыны үлгәннән соң, хатынының васыяте буенча, мирас тиенендә кадәр ике дистә кеше арасында бүленергә тиеш булган. Тик турыдан-туры варислары, борчуга калып, мирасны үзләренә кайтаруны сорап, судка мөрәҗәгать иткән – янәсе, ханым үз акылында булмаган. Эш буенча җавапка тартылучылар – 22 кеше булып, ә акча үзе 3 миллион сумны тәшкил иткән. Варисларга барысы да кире кайтмаган. Кайбер варислар Челышев миллионнарын Кама суына яшергән, дип тә сөйлиләр, һәм ул мирас әлегәчә шунда ышанычлы рәвештә саклана, имеш.

Фото: Ната Смирнова, tatfrontu.ru, artinrussia.org

Патша Россиясенең иң яхшы архитекторлары проектлаган бу биналарның күбесенең тәрәзәләрендә – 30нчы елларда репрессияләнгән һәм атып үтерелгәннәрнең шәүләләре. Подвалларда һәм ишегалларында әлегәчә пуляларның түгәрәк тишекләре калган кеше баш сөякләрен табалар. Бу газаплы тамга искиткеч гүзәл һәм мәгърур Никольск соборын да читләтеп үтмәгән.

PRESSA.RU

ЧОР ШАҺИТЛАРЫ

Сүз уңаеннан, XIX гасыр Чистай тарихы – ул ашлык, тоз, урман һ.б. белән сату итүче берничә сәүдәгәр династиясенең тарихы. Бу сәүдәгәрләрнең күбесе – иске дин тотучылар булган (старообрядцы). Шуң күрә дә югары сәүдәгәрләр җәмгыятенә эләгү бик җиңелдән булмаган, диләр.

Ул вакытларның купшы, мәгърур, кайчагында серле дә истәлеге булып «икмәк патшалары» Челышевлар, Шашиннар, Чукашёвлар, Подуруевларның Санкт-Петребург сарай-резиденцияләренең күчермәсе рәвешендә салынган аерым өйләре калган. Чистай үзәгендә андый йортлар – 144. Сәүдәгәрләр акчасына төзелгән «хезмәт» биналарының күбесе бүгенгәчә үз вазыйфаларын үти. Карл Маркс урамындагы хастаханә кайчандыр – земская больница, татар гимназиясе – прапорщиклар мәктәбе, 1нче гимназия руханилар училищесы булган (анысын үзгәртеп кору өчен бүленгән акчада Иоанн Кронштадскийның да өлеше бар).

КЫШКЫ МИРАС

– Менә монда XX гасыр башында шәһәрнең куас кайнату урыны булган. Ә 1941 елның көзендә бирегә Леонид Леонов килеп, аңа капиталь ремонт ясаган, – дип сөйли туристик-мәгълүмат үзәгенең өлкән хезмәткәре Елена Хәбибрахманова, Маркс урамына чыга торган ишегендә «трикотаж» тибындагы язуы булган һәм башкалардан берни белән дә аерылып тормаган корылмага күрсәтеп. – Чытырдап торган бозлы, очкан кошлар егылып төшә торган зәмһәрир суык кышта, ачлык, салкынны һәм сугышның бөтен авырлыгын тоеп, Леонов үзенең «Нашествие» дигән пьесасын яза. Аны шушында ук, Чистай театры сәхнәсендә, җирле актёрлар һәм Ленинград өлкә театры труппасы куя. Леонов Сталин премиясен ала һәм аны тулысынча баш командование фондына – фашистлар өстенә яудырыр өчен бомбалар ясауга җибәрә. Озакламый Леонов яшәгән йортта музей ачылачак.

Леоновның Чистайдагы тарихы – бирегә сугыш елларында башкаладан эвакуацияләнгән 200 язучы, шагыйрь, әдәбиятчының тарихы да. Бик күп мәгълүм исемнәр, эвакуация елларында тудырылган бик күп яхшы әсәрләр, бай документаль мирас.

– Билгеле булганча, без кечкенә шәһәрләр өчен Бөтендөнья банкыннан 50 миллион долларлык грант оттык, һәм ведомствоара комиссия безнең заявканы раслады. 10-11 ай дәвамында ул банк тарафыннан ахыргача расланырга тиеш, аннары Хөкүмәтнең тиешле карарын көтәбез. Шуннан соң инде проектны эшләү башланачак, ул бер елга якын вакытны алыр, дип фаразлыйбыз. Димәк, Чистай үзәген үзгәртеп кора башлау 2018 елга планлаштырыла, – дип сөйли шәһәрнең тарихи йөзенең киләчәк ренессансы турында «Чистай» музей-тыюлыгы директоры Александр Печёнкин. – «Энәсеннән җебенәчә» ясалачак реставрация шәһәрнең бөтен музейларын, шул исәптән Пастернак музеен, 30лап бинаны һәм мәдәни мирасның күпсанлы объектларын үз эченә ала. Әмма Чистайның киләчәге ул – Россиянең әһәмиятле туристик һәм мәдәни үзәгенең киләчәге дип, бүген үк әйтергә мөмкин.

Җукәтау хәрабәләрендә үсеп чыккан карт имән янына яңа никахлашучылар һәм гашыйклар еш килә. Парлыларга ул тугрылык һәм мәхәббәт бүләк итә, диләр.

XII гасыр башында Каманың бу ярларын юлбасарлар һәм качкын крестьяннар үз иткән, дип сөйлиләр. Крестьяннарны кире кайтарганнар, өйләрен яндырганнар һәм монда «чиста кыр» гына торып калган. Икенче фараз буенча, бу җирләрне үзләштерергә керешкән алпавытлар монда үз крестьяннарын күчереп утыртканнар. «Кая барасыз?» – дип сораучыларга «Чиста кырга инде!» – дип җавап кайтарганнар алар. Ә 1781 елда Екатерина II указы белән рәсми рәвештә Чистай өязе оештырылган.

Кайбер көннәрдә XX гасыр башы Чистаеның үзәк урамына үтеп керерлек булмый – халык крестьян Николай Мельниковның үз «махинасын» сынап каравын карар өчен җыела. «Күр инде, нәрсә уйлап тапкан!» – дип ачулана берәүләре. «Менә ичмасам баш!» – дип хуплый икенчеләре. Шул арада Чистай Кулибинының могҗизасы – педальле һәм эчендә Мельников та булган искиткеч зур агач тәгәрмәч хәрәкәткә килә. Халык таң кала һәм көлеш башлана.

БАР НӘРСӘГӘ ДӘВА

– Әлбәттә, шәһәр үзгәрә. Мин монда 1972 елда ирем белән килгән идем – аны бирегә эшкә чакырдылар. Автобустан чыктым да иремнең эшенә кадәр елый-елый бардым – карарга куркыныч иде. Ә хәзер биредә – чәчәк атып утыручы бакча, – дип сөйли Светлана Проничева. Берничә ел Чистай балалар хастаханәсендә участок педиатры булып эшләгәч, ул аңа җитәкчелек тә итә башлый, ә 90нчы елларда яңа гына ачылган балалар шәһәр дәваханәсенә баш табиб итеп билгеләнә. Хәзер Светлана Константиновна педиатр эшен Чистай җәмәгатьчелек советына җитәкчелек итү белән бергә алып бара.

– Менә сез сорыйсыз, Чистай ничек һәм ни өчен үзгәрә? Минемчә – бик күп кешеләрнең тырышлыгы белән. Безнең дәваханә ачылганда, анда бик күп нәрсәне эшләп бетерәсе бар иде. Һәм без ирем белән үз ваучерларыбызны плитка сатып алуга керттек, чөнки агач идәннәрнең такта ярыгы аша төрле җан ияләре кереп йөри иде. Кемдер безгә ул плитканы ике көндә салып та бирде. Андый кешеләр ул чакта күп иде, – ди Светлана Константиновна һәм шунда ук үз-үзен төзәтә дә: – Ул чакта гына түгел, хәзер дә бар алар. Күрү сәләте түбән булган балалар өчен бакчада бушлай төркем ачуга ирештек. Терапия өчен аппаратлар кирәк, акча юк. Һәм мин бер аппаратка – «Бетар»дан, икенчесенә Чистай округы буенча Татарстан Дәүләт Советы депутаты Виктор Смыковтан акча сорадым. Алар каршы килмәде. Бик күп сораучыларга каршы килмәгән кебек үк. Бу – шушындый күпсанлы очракларның берсе генә ләбаса.

– Меценатлык, шәфкать күрсәтү – бу Чистайга хас аерым үзенчәлек, – дип дәвам итә Светлана Константиновна. – Минем дус кызым Казан дәваханәләренең берсенә җитәкчелек итә. Кайчакта без очрашкалыйбыз, ә миңа шул вакытта хәйриячелек мәсьәләсендә шалтыраталар. Һәм мин менә шулар-шулар кирәк, дип әйтәм. Ул миннән: «Акча бирүче кешеләр синә кем?» – дип сорый. «Чистайлылар!» – дим. Алар нибары безнең, дөресрәге, үзләренең шәһәрен яраталар.

ЙОМГАК УРЫНЫНА

Чистайның үткәне, хәтта беркадәр киләчәге дә чагыштырмача аңлаешлы, диярсез. Ә бүгенге көне ничек? Бүгенге көндәге горурлыгы – илебезнең бирегә Бөек Ватан сугышы елларында эвакуацияләнгән иң яхшы заводларының бай үткәненнән даими үсеп килүче яңа оешмалар. Мәктәп кыңгыравы шалтырауга, балалар агыла торган яңартылган парк һәм скверлар. Чистай кешеләре йөри һәм, әйтик, доктор Живагоның прототибы – күренекле Чистай табибы Дмитрий Авдеев йортын карар өчен, әледән-әле туристлар туктаплып кала торган матур һәм тыныч урамнар. Хәер, безнең каһарманнарыбызның берсе әйткәнчә, Чистай тиз генә һәм теләсә кемгә ачылмый ул. Ә сезгә, һичшиксез, ачылачак. Иң мөһиме – барыгыз.

Иске татар бистәсендәге «Нур» мәчете – Чистайда иң борынгылардан. Аңа 150 елдан артык. Биредә «Нур» һәм Казандагы «Мәрҗани» – республикабызның хәтта гражданнар сугышы елларында да бер генә көнгә дә ябылып тормаган ике мәчете. «Нур» шуның белән дә танылган: анда ярты гасыр буе суфичылык ордены лидеры Мөхәммәтзакир Габделваһап улы Мөхәммәткамалов хезмәт иткән. Кадимчелек мәгърифәте яклы бу кеше күренекле җәмәгать активисты, меценат һәм йодрык сугышы остасы да булган.

«Нур» мәчетеннән ерак та түгел исеме дөньяга танылган композитор Софья Гобәйдуллинаның туган йорты булган. Бераз арырак элеккеге «Аеклык трактиры» урнашкан – бирегә бистә халкы төрле тәм-том белән чәй эчәргә җыйналган.

Фото: Ната Смирнова, tatfrontu.ru, artinrussia.org

PRESSA.RU

ТӨП РЕСУРС – КЕШЕ КАПИТАЛЫ

Чистай районы башлыгы Дмитрий Иванов «Татарстан» журналына республикабыздагы иң өлкән районнарның берсенең ничек яшәве турында сөйләде.

– Дмитрий Алексеевич, Чистай август ахырында үзенең 235 еллыгын билгеләп үтте. XIX гасырда ул икмәк сәүдәсенең Идел буе үзәкләреннән берсе булган, XX гасырда куәтле сәнәгать күтәрелеше кичергән. Хәзер шәһәр акрынлап музей-шәһәргә әверелеп бара. Анда әүвәлге заманнардан иң яхшы нәрсәләр сакланып калганмы?

– Һичшиксез. Район икътисадының драйверлары булып машина төзү һәм прибор төзү предприятиеләре кала – «Бетар», оборона заказлары белән шөгыльләнүче «Восток» ФТҮ, ике тапкыр «Сколково» резиденты булган «Вектор», нефть табу оешмалары өчен насослар җитештерүче «Яңа технологияләр» актив үсештә. Гомумән алганда һәм күбесенчә җитештерү тармагы хезмәте нәтиҗәсендә, быел бездә тулай керемнең динамикасы уңай: узган ел белән чагыштырганда - плюс 12,5%. Эш урыннарының саны арта. Узган ел 850 урын булдырылган иде, быел – 100гә якын, инде әйткәнемчә, берничә яңа оешма ачылуын көтәбез.

– Нинди дә булса аерым юнәлештәме?

– Безнең төп шартларыбызның берсе – экологик стандартларны саклау. Ә эшчәнлек юнәлешенә килгәндә, бу төрледән төрле оешмалар. «Чистай» индустриаль паркы проектын тормышка ашыру кысаларында «Татремстрой»ның яңа резиденты тарафыннан яңа завод корпусы төзелде. 1 сентябрьгә беренче 7 километр торба чыгарылды. Бу билгеле бер мәгънәдә импортны алыштыручы җитештерү – полиэтилен чималын завод республика җитештерүчеләреннән сатып алачак. ТР Министрлар Кабинетында кул куелган «Газпром Газ-мотор ягулыгы» белән килешү кысаларында сыекландырылган табигый газ җитештерү заводын ачу планлаштырыла.

– 2015 елда шәһәр Бөтендөнья банкы грантын отты, шәһәр

үзәгендәге тарихи биналарны һәм музейларны зур күләмдә үзгәртеп кору көтелә. Бу проект башка инвесторларны дә җәлеп иттеме?

– Әйе, дип әйтергә мөмкин, бу миңа әле эшнең башы гына кебек тоела.

– Кайсы проект аларның игътибарын аеруча җәлеп итте?

– Кунакханәләр төзү проекты. Узган ел бездә 80 мең турист булып китте. Әгәр безнең аларны урнаштыру өчен тиешле мөмкинлекләребез булса, күпләре өчәр көнлек турист булыр иде. Хәзер безнең бер генә кунакханәбез бар, һәм ул 100% ка тулган. Шуңа да без кунакханәләрнең – 15–20 номерлы мини-отельләрнең – берничә эскиз проектын эшләдек, һәм аларны сүтелгән тузган биналар урынына шәһәрнең тарихи үзәгендә урнаштыру өчен, Президент каршындагы мәдәният советы утырышын көтәбез.

– Районыгыз Татарстан Президенты карамагындагы программаларда катнашамы?

– Әйе, әлбәттә. Без республиканың барлык программаларында да актив катнашабыз. Быел гына дүрт спорт мәйданчыгы төзелде, дүрт мәктәпкә, күпфатирлы 16 йортка капиталь ремонт ясалды, «Солнышко» лагере, ике яшүсмерләр клубы ремонтланды. Юл эшләренең зур күләме башкарылды, һәм шәһәрнең берничә мөһим участогында эшләр әле һаман да дәвам итә. Безнең горурлыгыбыз булган яңа объектларның берсе – өч мең урынлы яңартылган «Татнефть Олимп» стадионы. Аны реконструкцияләү өчен акчаны, Татарстан Дәүләт Советының безнең округ буенча депутаты Виктор Смыков башлангычы буенча, «Татнефть» ГАҖ бүлеп бирде. 25 августта объектның тантаналы ачылышында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты.

– Районда бүгенгә ничә объект төгәлләнгән?

– Яңа күпфункцияле үзәк, ике ФАП, ике авыл советы, спорт мәйданчыклары һәм, мәктәпләрдән тыш, районның авыл җирлекләрендә дүрт мең кв. метрдан артык юллар ремонтланды. 13 торак пунктта урам яктырткычлары торгызылды. Чистай Выселкасы авылында 300 урынлы клуб төзелә. Республика программалары ярдәмендә безнең район да, республика да гомумән үзгәрде.

– Сезнең тарафтан күптән түгел расланган Чистай районының үсеш стратегиясе буенча шәһәрдә медицина шәһәрчеге булдыру күздә тотыла икән.

– Сәламәтлек саклау – өстенлекле юнәлешләребезнең берсе. Чистай хастаханәсе, перинаталь үзәк кебек үк, 7 районга хезмәт күрсәтә, һәм пациентлар агымы арта. Шуңа да безнең планда – медицина шәһәрчеген булдыру. Хәзер исә шәһәрдә 200 кеше кабул итүгә каралган балалар дәваханәсе төзелә башлады.

– Документ шулай ук студентлар шәһәрчеген оештыруны да күздә тота.

– Чистайда КМТТУ-КАИның да, Казан инновация институтының да филиаллары эшли. Мәгариф министрлыгы тарафыннан безнең авыл хуҗалыгы техникумы базасында эшче һөнәрләр буенча белгечләр әзерләү буенча ресурс үзәген булдыру проекты расланган. Болар барысы да студентлар шәһәрчеген ачу өчен сәбәп булып тора. Моннан тыш, КАИ Чистай сәгать заводы мәйданында эшләүче барлык предприятиеләр белән хезмәттәшлек итә – алар барысы 40. Ягъни студентларның эшләп торучы җитештерүләрдә өйрәнү мөмкинлекләре бар.

– Районны транспорт инфраструктурасы үсеше белән бәйле проектлар көтәме?

– Безнең стратегия, Республиканың 2030 елга кадәрге үсеш стратегиясе белән тулысынча ярашкан хәлдә, Чистай районы аша үтә торган «Европа – Көнбатыш Кытай» тизлекле автомагистраленең бер өлеше буласы юлны төзүне күздә тота. Һәрхәлдә, эшләр инде башланды.

– Нәтиҗә ясап: район инвесторны конкрет нәрсә белән җәлеп итә ала?

– Бу туристик потенциал да – Чистай, республиканың географик үзәге, Кама елгасы буенда урнашкан һәм үзенчәлекле бай тарихка ия. Җитештерү ягыннан да – Бөек Ватан сугышы елларында бирегә берничә эре оешма эвакуацияләнгән, һәм бу безнең бүген инде яңа этапка чыгучы сәнәгатебез үсешенә нигез салган. Болардан тыш, авыл хуҗалыгы җирләренең мәйданы буенча без республикада өченче урында торабыз – бу кара туфраклы, уңдырышлы җирләр. Без, соңгы берничә елга караганда, бу ресурсны тагын да нәтиҗәлерәк файдалана башлау турында уйланабыз. Өстәвенә, тиешле инфраструктурабыз – причалларыбыз һәм порт элеваторы да бар. Һәм соңгысы, әмма иң мөһиме: кеше капиталы. Соңгы ярты гасырда районга җитәкчелек иткәннәрнең һәркайсы бирегә күптөрле тармакларның – сәнәгать булсынмы ул, мәгариф, сәламәтлек саклау, хәтта дин тармагымы – иң яхшы профессионалларын саклап калырга һәм читкә җибәрмәскә генә түгел, ә бәлки бу ресурсны тагын да арттырырга тырышкан. Һәм бу эш бүген үз җимешләрен китерә.

Әңгәмәдәш – Ксения Сёмина

PRESSA.RU

Капиталь ремонт ВЛ-110 кВ.

Монтаж КЛ-10 кВ ПС 110/10 кВ Болгар.

ВЛ-110 кВ трассасын чистарту.

АЛГА БАРЫРГА КИРӘК!

Авыр һәм беренче карашка күзгә күренми торган хезмәтне мәгълүм җыр геройлары гына түгел, башка бик күп оешмаларның хезмәткәрләре дә алып бара. Чистайның «ЭнергоСтройСервис» компаниясе генераль директоры Халит Гарифуллин Татарстандагы күп районнарның йортлары һәм оешмаларының тәрәзәләрендә утлар балкытучы кешеләрнең ничек яшәүләре һәм эшләүләре турында сөйләде.

– Халит Мәхмүтович, 13 ел элек сез «ЭнергоСтройСервис» ҖЧҖнә җитәкчелек итә башладыгыз, аны «Татэнерго» берләшмәсен үзгәртеп кору барышында белгеч-энергетиклардан оештырдыгыз. Бу вакыт эчендә нинди нәтиҗәләргә ирешә алдыгыз?

– Кыскача гына әйткәндә, без башкарыла торган эшләрнең күләмен 10 тапкырдан артыгракка күтәрдек, ә оешманың еллык әйләнеше 1 млрд сум тәшкил итә.

– Бу саннарга караганда, компаниянең эшчәнлеге Чистай районы территориясендәге проектлар белән генә чикләнмидер кебек?

– Әйе, безнең эшләрнең географиясе бу чикләрне күптән үтеп чыкты. Бүгенге көндә безнең бригадалар, Чистай электр челтәрләрен куллануга тапшыру зонасыннан тыш, ә бу Кама аръягының 7 районы (Чистай, Алексеевск, Нурлат, Спас, Аксубай, Әлки һәм Яңа Чишмә районнары), «Челтәр компаниясе» ААҖ филиалларының барысында да эшли. Без бик күп муниципаль районнар белән тыгыз элемтәдә торабыз, безнең белән «Татнефть» ГАҖ, «Татех» компаниясе, «Нефтегаз» СМП, «Ритэк» ААҖ, «САНЕКО» компаниясе һәм башкалар хезмәттәшлек итә. Күрше төбәкләр белән эшләү тәҗрибәбез дә бар, тәкъдимнәр килә тора.

– Территориягез кечкенә түгел. Ә барлык бу заказларны күпме хезмәткәр башкара?

– Хәзер «ЭнергоСтройСервис»та эшләүчеләрнең саны 200дән аз гына артып китә. Алар барысы да – югары класслы белгечләр. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: без технологияләрнең даими камилләшеп торган чорында яшибез, бу шулай ук безнең тармакка да кагыла. Шулай булгач, безнең барлык хезмәткәрләребез дә даими рәвештә квалификацияләрен күтәрә, ел саен аттестацияләр үтә.

– Аларның квалификациясе электр тапшыру линияләренә техник хезмәт күрсәтергә генә мөмкинлек бирәме, әллә алар тагын нинди дә булса эшләр башкара аламы?

– Әгәр безнеке кебек компания нәтиҗәлелеккә ия булырга теләсә, хезмәткәрләренең компетенцияләре энергетика өлкәсендәге юнәлешләрнең тулы спектрын колачларга тиеш. Шактый катлаулы – 2008, 2009 елларда без әйләнешләребезне арттыра бардык. 2009 елда «Татарстан Республикасы тәэзүчеләре хезмәттәшле-

Реклама

ге»нә кердек, һәм 30дан артык төрдәге эшне башкару хокукына ия булдык. 2012 елда без «Идел–Кама архитекторлары һәм проектлаучылары берлегенә» кердек һәм проект эшләрен башкару хокукын алдык, моның өчен проект бүлеге оештырылды. Шул ук рәвештә инженерлык-геодезия эзләнүләре бүлеге булдырылды. Электр җиһазларын эшләтеп җибәрү-көйләү һәм сынау эшләрен башкарабыз. 2016 елда эшчәнлегебезне тагын да җәелдереп, генподряд эшләренә керешү мөмкинлеге алдык – хәзер без капиталь төзелешнең куркыныч һәм техник яктан катлаулы объектларында эшләү хокукы белән 3 млрд сумга кадәрле килешүләр буенча эшлибез. Безнең 70 берәмлектән торган заманча техника паркыбыз бар. Бу техниканың күпчелеге – махсуслашкан, һәр җиргә үтешле, эре энергообъект төзелешләре өчен билгеләнгән.

– Бүлекләрдәге белгечләр объектларга бер үк вакытта чыгамы?

– Без үзебез өчен эшнең билгеле бер алгоритмын булдырдык. Ул бик конвейерны хәтерләтә. Әйтик, бер объектта электр тапшыру линияләрен үзгәртеп корырга кирәк, ди. Моның өчен безгә 8 сәгать бирелгән – бу районда ут сүндереп тору вакыты. Монтажчылар терәкләрне һәм үткәргечләрне сүтә башлый. Алар артыннан ук терәкләрне утыртучылар һәм үткәргечләрне сузучы монтажчылар килә. Без шул 8 сәгатькә сыешабыз, ә эш дөрес оештырылмаганда яки искечә эшләгәндә, моның өчен берничә көн китәр иде. ЛЭП-35 кВ (һәм аннан да югарырак) төзегәндә дә шулай ук – эшне фундамент монтажлаучы белгечләр башлый, икенче бригада параллель рәвештә терәкләрне җыя. Ә инде җыелган терәкләрне өченче белгечләр урнаштыра. Бөтен процессны бер команда башкаруга карагандa, барысы да тизрәк эшләнә.

– Димәк, сезнең хезмәткәрләрнең эш графигы бик тыгыз?

– Әлбәттә. Эшләрнең күләме зур. Моннан тыш, гадәттәгедән тыш һәм авария очраклары да була. Мәсәлән, электр үткәрү линияләре (ЛЭП) терәкләренең җимерелүе. 2010 елда бозлы яңгыр нәтиҗәсендә утсыз калган берничә районда үткәргән ашыгыч төзекләндерү эшебез өчен ТР Президенты исеменнән Рәхмәт хаты алдык. Безнең егетләр ул чакта суык һавада, кыска тәнәфесләр генә ясап, тәүлегенә 20шәр сәгать эшләде. 2,5 меңгә якын терәкне торгыздылар.

– Ә оешмагызда эшләргә теләүчеләр күпме?

– Башка бик күп оешмалар кебек үк, без дә урта һөнәри звено белгечләренә кытлык кичерәбез, элек аларны училищелар, колледжлар әзерли иде бит. Шуңа күрә без әзерлексез кешеләрне алабыз да монда әзерлибез. Әйбәт электромонтёр тәрбияләү өчен ике-өч ел кирәк. Ә тагын да югарырак дәрәҗәдәге белгечне, әйтик, подстанция ремонтлый алучыны, әзерләүгә биш еллап вакыт сорала.

– Ничек уйлыйсыз, кешене мондый эшкә тагын нәрсә белән кызыксындырып була? «ЭнергоСтройСервис»та хезмәт хаклары дәрәҗәсе көндәшлеккә сәләтле, ә эш бит акчада гына түгел?

– Һәркем үзе өчен сайлый, билгеле. Тик шуны да әйтим: бу эш ялкаулар өчен түгел. Һәм монда физик яктан гына түгел, интеллектуаль яктан да хезмәт куярга кирәк. Нәрсә эшләгәнеңне уйларга. Эшнең сыйфаты да һәм, әлбәттә, куркынычсызлыгы да шуннан тора. Бу эшкә бүгенге көндә альтернативалар бар, билгеле. Тик кемгәдер кредит сату – бер нәрсә, ә менә, мәсәлән, син Иннополиска барасың, ди, ә анда син төзегән ЛЭП – бу бөтенләй башка! Бу бит горурлык!

– Сүз уңаеннан, Иннополис турында: соңгы вакытта «ЭнергоСтройСервис» башкарган эре проектлар турында сөйләгез әле.

– Хәзерге вакытта «Щелоков–Үзәк» ЛЭП-220 кВ төзелешендә эшлибез. Күптән түгелгесе –Иннополис, без анда электр белән тәэмин итү объектларын төзүче берничә подряд оешмасы арасында идек. Бик җиңел булмаган участокта – югарылыгы 120 метр аралыгында әледән-әле тирбәлеп торган урында, Зөя елгасы кичүендә. Яр Чаллыда «Кама Кристалл Технолоджи» оптоэлектроникасы өчен синтетик сапфир җитештерүне энергия белән тәэмин итүне башкардык һәм Казандагы «Салават күпере» торак комплексы өчен җиһазлар монтажладык, кабель линиясен үткәрдек. Түбән Камада «Бигеш» энергоподстанциясен төзүдәге эшләр комплексын башкарып чыктык. Һәм, әлбәттә, 2011 елда «Чистай» индустриаль паркын электр белән тәэмин итү проектын, ул чакта рекордлы кыска арада катлаулы эшләр комплексы башкарылды. Оешмабызның барлык эшләренең сыйфаты ISO 9001 сертификаты белән расланган. Дөресен әйткәндә, мин барлык объектларны хәтерләмим дә инде, чөнки бөтен эшчәнлегебез дәвамында алар ике меңнән артып китте.

– Кызыклы объектлар бар идеме?

– Бездә бөтен объектлар да кызыклы. Еш кына ситуациягә карап схемалар эшләргә туры килә. Менә чагыштырмача күптән түгелгесе – Болгар музей-тыюлыгы территориясендә реконструкция ясау кысаларындагы эшләр. Кызыклы да, катлаулы да иде. Беренчедән, кайда казыма, тарихи катлам һәм ниндидер артефактларны бозу ихтималы бар. Икенчедән, безнең бөтен объектларыбыз гомуми экспозиция белән ярашырга тиеш. Әмма нәтиҗәсе тәэсирле булды.

– Компания өчен үз булган Чистайны онытмыйсызмы?

– Чистайны бик яратабыз. Аның матур, заманча булуын телибез. Шуңа да даими рәвештә аңа спонсорлык ярдәме күрсәтәбез – соборга һәм Чистайның хәтта совет власте елларында да бер генә көнгә дә ябылып тормаган борынгы мәчетенә архитектур яктырткычларны монтажладык. Бәйрәмнәр үткәрергә булышабыз, Яңа елга үзәк чыршыга иллюминация ясыйбыз. Шәһәрнең үсүе, анда безнең өлешебез дә булуы, безнең оешма хезмәткәрләренең дә гаиләләр төзүе, балалары тууы бик тә яхшы. Менә ул киләчәк. Сүз уңаеннан, үзәк мәчет янында балалар өчен спорт мәйданчыгы төзедек. Шулай ук башка районнарга да булышабыз.

Без «Челтәр компаниясе» ААҖгә безнең төп заказчыбыз булуы һәм барлык проектларыбызда ярдәм итүе өчен бик рәхмәтле. Безнең девизыбыз: «Ирешелгәннәрдә туктап калырга ярамый, алга барырга кирәк». Димәк, шәһәребез иминлеге, республикабыз иминлеге хакына хезмәт итәчәкбез.

PRESSA.RU

(EFQM моделе) критерийлары буенча «Танылган камиллек» дәрәҗәсе өчен бәяләү үткәрде, һәм иң югары бәя – 5 йолдыз алды.

Сыйфат өлкәсендә үткәрелгән эш чынлап та танылуга китерде. Предприятие сыйфат өлкәсендә Россия Хөкүмәте премиясе алу конкурсында ике тапкыр җиңеп чыкты, ул – сыйфат өчен ТР Хөкүмәте премиясенә, продукция һәм хезмәт күрсәтү сыйфаты өлкәсендәге казанышлары өчен БДБ илләре премиясенә лаек булды. Идарә итүнең нәтиҗәле ысулларын кертүдә югары казанышларга ирешкәне һәм продукциясенең югары сыйфаты өчен «БЕТАР» ЖКФ ЖЧЖ турындагы мәгълүмат Бөтенроссия сыйфат оешмасының Дан залына кертелде.

ЭНЕРГОРЕСУРСЛАР – АКЧА САНАГАННЫ ЯРАТА

1996 елда оештырылган «БЕТАР» Җитештерү-коммерция фирмасының («БЕТАР» ЖКФ ЖЧЖ) төп юнәлеше – энергоресурсларны исәпләү приборларын җитештерү. Компания 40тан артык исемдәге продукция чыгара. Линейканың нигезендә – су исәпләгечләрнең (фатирныкыннан башлап, сәнәгатьнекенә кадәр) төрле модификацияләре, газ, җылылык һәм электр энергиясен исәпләгечләр.

«БЕТАР», Татарстанда беренче булып, коммуналь һәм шәхси су куллану системалары өчен эчә торган су исәпләгечләре җитештерүне үзләштерде. Квалификацияле кадрлар – конструкторлык эшкәртүеннән башлап, сатуга кадәр – операцияләрнең тулы циклын тәэмин иттеләр. Бүген, 20 ел үткәннән соң, «БЕТАР» – сатулар күләме һәм продукциясенең сыйфаты буенча Россиянең энергоресурслар исәпләү приборлары базарында әйдәп баручылар сафында тора. Эшчәнлек дәверендә предприятие тарафыннан 55 миллионнан артык продукция берәмлеге чыгарылган.

Кулланучыларга уңайлы булсын өчен, Россиянең 69 төбәгендә, һәм хәтта якын чит илләрдә – Белоруссиядә, Казахстанда, Кыргызстанда, Төрекмәнстанда, Үзбәкстанда, Монголиядә фирманың вәкилләкләре булдырылган. Инде 10 елдан артык «БЕТАР» үз кулланучыларына трэйд-ин – гарантия срогы яки тикшерү интервалы үткән приборларны кара-каршы сату-алу хезмәте тәкъдим итә. Бу кулланучыларга яңа приборларны завод гарантиясе белән түбәнрәк бәядән сатып алырга мөмкинлек бирә.

Фирманың сыйфат менеджменты системасы ISO 9001 һәм ISO/TS 16949:2009 (ISO 9001:2008не автомобильләр һәм аларга запчастьлар җитештерүдә куллану буенча шәхси таләпләр) таләпләренә ярашуга сертификацияләнгән. Экологик (ISO 14001), энергетик (ISO 50001), хезмәтне саклау (OHSAS 18001) менеджмент системалары да сертификацияләнгән.

2012 елда фирма үз эшчәнлеген Европа сыйфат белән идарә итү фондының камиллек моделе

«БЕТАР» эшләнмәләренең сыйфаты даими билгеләп үтелә. Әле күптән түгел оешма җитештерә торган кечкенә күләмле СГБМ (2,5; 3,2; 4) көнкүреш газ исәпләгече «ТРның иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре – 2016» конкурсында «Халык өчен сәнәгать товарлары» номинациясендә лауреат дипломы белән билгеләнде.

Бүгенге көндә «БЕТАР» ЖКФ ЖЧЖнең эре җитештерү мәйданнары, заманча технологик җиһазлар паркы, югары квалификацияле белгечләре бар. Һәм бу ирешелгәннәрдә тукталып калмаска, ә җитештерүне киңәйтә барып, яңа юнәлешләрне актив үстерергә мөмкинлек бирә. Перспективалы, Россия базарында ихтыяҗга ия юнәлешләр арасыннан станоклар төзү һәм инструментлар җитештерүне алырга була. Предприятие автоматлаштырылган линияләр, робот-манипуляторлар, коюы өчен пресс-формалар, кисү инструментларын проектлаштыра һәм эшкәртә. Моннан тыш, фирма предприятиеләрдә һәм ТКХ идарәче компанияләрендә ешрак ихтыяҗга ия була баручы «САКЛАУ» энергоресурслар куллануны комплекслы автомат исәпләү системасын (АСКУПЭ) кертү проектларын уңышлы рәвештә тормышка ашыра.

Компания актив социаль эшчәнлек алып бара: тузган торакны бетерү буенча дәүләт программасында катнашып, Чистайның үсешенә булыша, шулай ук борынгы Болгар һәм Свияжск утрау-шәһәре һәйкәлләрен торгызуда «Яңарыш» фонды эшчәнлегенә финанс ярдәме күрсәтә.

РАЙОННАР БҮЙЛАПІ / МАХСУС ПРОЕКТ

Реклама

ЮЛ ТӨЗҮЧЕНЕҢ ЭШЕ КҮП ЧАК

Татарстанның бу елгы планында – 130 километрдан озынрак яңа юллар төзү һәм 200 километрдан артыграк озынлыктагы искеләрен ремонтлау. Планны турыдан-туры тормышка ашыручыларның берсе – «Чистай Автодор» ҖЧҖ. Эшнең барышы һәм Чистай районы юл челтәренең торышы турындагы сорауларны оешманың генераль директоры Эльвира Рәхмәтуллинага бирдек.

– Эльвира Мансуровна, Чистай юлларының торышын ничек бәялисез? Ул шәһәрнең автомобильләшү дәрәҗәсенә ничегрәк яраша?

– Соңгы биш елда безнең юлларның торышы сизелерлек яхшырды – бүген Чистайның барлык үзәк урамнары диярлек нормативларга туры килә. Шул ук вакытта, башка күп шәһәрләрдәге кебек үк, автомобиль юллары инфраструктурасы, аеруча хәрәкәт күп чакта, шактый киеренкелек тудыра: светофорлар, альтернатив урап узу юллары җитми…

– Сезнең профессиональ карашка яхшы автомобиль юлы нинди булырга тиеш?

– Эталон дип ышанычлы һәм куркынычсыз хәрәкәтне тәэмин итәрлек юлны санарга була. Барыннан да элек, яхшы күренгән, тар участоклары булмаган, юл тамгалары, билгеләре куелган һәм, әлбәттә, тигез булган юлны.

– Безнең юлларны, әйтик, Европаныкы кебек итү өчен нәрсә җитми?

– Барыннан да элек, комплекслы мөнәсәбәт. Норматив-хокукый базаны үзгәртү һәм камилләштерү, яңа нормалар һәм технологияләр эшләү һәм аларны проектларга кертү зарур.

– Сезнең компания юл төзелешендә нинди прогрессив ысуллардан һәм материаллардан файдалана?

– Инде 2010 елдан ук без асфальт-бетон өслек өчен ком-таш мастикалы асфальт-бетон куллана башладык. Ул югары йөкләнешләргә чыдый ала, шуңа күрә көчле хәрәкәт булган трассаларда уңышлы кулланыла. Типик тимер-бетон суүткәргеч торбалар урынына спиральле гофре тибындагыларны кулланабыз. Беренчедән, алар чагыштырмача тизрәк монтажлана, бу эш вакытын кыскартырга мөмкинлек бирә. Икенчедән, ялганган урыннары булмаганга, алар җыелган хәлдә тоташ торбаны хасил итә. Монысы герметиклык һәм куллануның уңайлылыгы белән бәйле күп проблемаларны хәл итә. Гомумән, шуны әйтергә телим: проектта яңалыклар каралган икән, без аларны, һичшиксез, истә тотабыз.

– Бүгенге көндә сезнең оешма Чистай районының кайсы проектларында катнаша?

– Менә өч ел инде без торак пунктларның юл-урам челтәрләрен норматив торышка китерү буенча республика программасын тормышка ашыручылар булып торабыз. Гади генә итеп әйткәндә, юлсызлык белән көрәшәбез, районыбыз авылларына каты өслекле юллар сузабыз, шулай итеп, аларны инде үсеш алган автоюллар челтәренә тоташтырабыз. Әйтик, узган ел Уракчы авылын «Казан – Оренбург» федераль автоюлына тоташтырдык: әлеге торак пунктка китергән асфальт-бетон өслекле юлның озынлыгы 2,3 км ны тәшкил итте. Кызыл Болгар авылына 1,2 км озынлыкта юл салдык. Быел Байтирәк авылына илтүче 3,5 км озынлыктагы юлны үзгәртеп төзибез. 2017 ел планнарында Чистай муниципаль районының Каратай авылына, җирне күтәртеп, 2,5 км озынлыкта ком-таш өслекле юл төзү каралган.

– Бу катлаулы заманда оешмагызның югары үсеш темпларын саклап калу мөмкинлеге бармы?

– Моның өчен мөмкин булганның барысын да эшлибез. Юлларны карау һәм куллану белән шөгыльләнүче оешмалар белән актив хезмәттәшлек итәбез. Алар кайда чокыр-чакырны ямау, кайда юл төзү һәм үзгәртеп төзү таләп ителгәнен яхшырак белә. Һәркайсында баланс тотучыга үз хезмәтебезне тәкъдим итәбез. Әлбәттә, күп нәрсә финанслаудан тора. Шулай да бу җиңел булмаган шартларда, бик авыр көндәшлек басымы астында, тулы канлы режимда эшләү, ягъни инерт материалларны үз вакытында сатып алу, технопаркны яңартып тору, хезмәт хакларын түләү кулыбыздан килә. Дәүләт заказы буенча үз өстебезгә алган бурычларны сыйфатлы итеп һәм вакытында үтибез. Моннан тыш, хәйриячелек белән шөгыльләнергә тырышабыз. Күптән түгел аз тәэмин ителгән һәм күп балалы гаиләләрдәге балаларга мәктәпкә җыенырга булыштык, Исляйкино авыл җирлегенең беренче класс балаларына мәктәп кирәк-яраклары туплап бүләк иттек. Без ярдәм кулы сузарга һәрчак әзер.

Реклама

PRESSA.RU

СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ – ӨСТЕНЛЕКТӘ

2015 елда Чистай перинаталь үзәгендә экстремаль түбән тән массасы белән – 670 һәм 720 г авырлыктагы ике сабый дөньяга килде. Аларны тәрбияләп, күпмедер вакыттан соң өйләренә чыгардылар. Шушы очрак һәм гомумән районнардагы сәламәтлек саклауның торышы турында «Татарстан» журналы «Чистай ҮРХ» ДАССУ баш табибы Рәис Мостафин белән сөйләште.

– Рәис Робертович, экстремаль түбән тән массасы белән туган ике сабыйны уңышлы рәвештә исән саклап калу – бу республикадагы рекордмы?

– Юк. Бу – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының һәм, гомумән, Хөкүмәтнең эш нәтиҗәлелеге күрсәткече һәм безнең белгечләрнең профессиональлеге билгесе дә.

– Булачак әниләр нинди күрсәткечләргә карап перинаталь медицина үзәгенә җибәрелә?

– Безгә хәлләре уртача авырлыкта булган һәм баланы вакытыннан алда тудыру куркынычы янаган хатын-кызлар 32–37 атналык срок белән Алексеевск, Әлки, Аксубай, Спас, Яңа Чишмә һәм Нурлат районнарыннан китерелә.

– Аларга нинди ярдәм күрсәтелә?

– Зарури булган бар нәрсә дә. Моннан тыш, үзәктә яңа туган сабыйлар өчен 4 койкалы интенсив терапия палатасы бар, әнә шунда аларга ярдәм күрсәтелә, түбән һәм экстремаль түбән масса белән туган балалар карала.

– Ничек уйлыйсыз, бу сабыйларны саклап калуга ирешү беренче чиратта нәрсә белән бәйле?

– Бездә техник яктан барлык шартлар да тудырылган, һәм бу бик тә мөһим. Әмма мондый сабыйларның гомерендәге беренче сәгатьләрдә неонатологларның роле зур – аларның намуслылыгы, мөмкин булган бөтен ярдәмне күрсәтергә әзерлеге.

– Әлеге белгечләргә эш йөкләнеше зурмы?

– Үзәкнең штаты нормативларга туры китереп тулысынча комплектлаштырылган, әмма, гомумән алганда, ҮРХндә кадрлар кытлыгы 48%ны тәшкил итә. Шул ук вакытта белгечләрнең уртача яше 53не тәшкил итә. Табиблар җитми. Тик бу кечкенә шәһәрләрнең уртак проблемасы. Сүз уңаеннан, сыйфат ягыннан караганда, районыбыз уңды дияргә була – алар бик көчле һәм белемле белгечләр.

– Кадрлар җитмәү проблемасын ничек хәл итәсез?

– Шунысын билгеләп үтәргә кирәк: район җитәкчелеге – элеккеге башлык өчен дә, бүгенгесе өчен дә – сәламәтлек саклау проблемалары өстенлекле урында булды һәм шулай булып кала да, һәм бу тармакка төрлечә ярдәм күрсәтелә. Перинаталь үзәк тә нәкъ менә шулай барлыкка килде. Хәзер яшь белгечләргә торак бирелә. Быел югары звенолы алты табиб таптык. Барысы да – башка төбәкләрдән. Татарстан, сүз уңаеннан, башка субъектлардан медицина кадрларын җәлеп итүдә лидер булып тора.

– Бу белгечләргә эшләү өчен тиешле шартлар тудырыламы? Яхшы җиһазлар бармы?

– Әйе, безнең район «алгарышлы». 2009 елдан кан тамырлары үзәге эшли. Яхшы нәтиҗәләр дә бар – инсульттан һәм кискен миокард инфарктыннан үлү очраклары кимеде. Хәзер тромболизис дип аталган нәтиҗәле методиканы кулланабыз. ҮРХ базасында 7 районга хезмәт күрсәтүче II дәрәҗәле травма үзәге эшли. ТР сәламәтлек саклау министры Адель Вафин ярдәме белән цифрлы флюорограф алуга ирештек. Хәзер Карл Маркс урамындагы 59/3 номерлы тарихи бина реконструкцияләнә. Анда туберкулёз диспансеры дәваханәсе урнашачак. Моннан тыш, табибларның квалификациясен күтәрү өчен даими рәвештә мастер-класслар һәм семинарлар үткәреп торабыз.

– «Ашыгыч ярдәм»гә төшкән йөкләнеш зурмы?

– Бездә атнасына 130дан 160ка кадәр чакыру була, бригадага тәүлегенә 12–14 чакыру туры килә.

– Алар районга да чыгалармы?

– Чыгалар, күбрәк кичләрен һәм төнлә белән. Көндез анда фельдшер-акушерлык пунктлары яхшы эшли. Гомумән, шәһәрдән аермалы буларак, ФАПлар – безнең төп ресурсыбыз. Шуңа да аларда эшләрнең көйләнгән булуын игътибарда тотабыз. Республика программасы буенча узган ел модульле өч ФАП ачылды, быел икене ачу күздә тотыла, киләсе елга тагын өчне ачарга телибез. Хәзер районда барлыгы 36 пункт эшли.

– Ә диспансерлаштыру программасы сездә ничегрәк үтә?

– Бу бик әйбәт программа, ул профилактика вакытында, шул ук инфарктларны, башка төр йөрәк-кан тамырлары авыруларын кисәтүдә яхшы нәтиҗәләр күрсәтә. Әмма аңа халыкны җәлеп итү – чып-чын проблема. Бездәге халык аны әлегә бәяләп җиткерә алмады. Форсаттан файдаланып, бөтен кешегә мөрәҗәгать итәсем килә: һичшиксез, диспансеризация үтегез! Зыяны булмаячак, ә җитди авыруларны дәвалауга караганда, кисәтү яхшырак.

Реклама

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТОВ

Җиңә

БАШЛАУЧЫЛАР ӨЧЕН МӘЙДАНЧЫК

Июнь аенда Петербург халыкара икътисадый форумында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов якын арада республикада сәнәгать мәйданчыкларының саны 100гә җитәчәге турында белдерде. Бүгенге көндә Татарстан территориясендә өч дистәдән артык сәнәгать мәйданчыгы эшли.

Хәзерге икътисадый вазгыятьтә алар кече һәм урта бизнес предприятиеләренә ярдәм инструменты булып кала. Чистай сәнәгать мәйданчыгы җитәкчесе Юрий Стахеев безгә бүгенге көндә аның резидентлары үзләрен ничек хис итүе турында сөйләде.

– Безнең монда ремонт – эш урыннарын тәртипкә китерергә булдык. Безнең белән эре инвесторлар да кызыксынуларын күрсәтә, ярашырга кирәк, – Юрий Михайлович сәнәгать мәйданчыгы территориясе – элекке авторемонт заводы буйлап экскурсия үткәрә. – Без 2014 елда аккредитация алдык, 10нан артык резидент кабул итәргә әзерләнгән идек. Тик нәкъ менә кризис китереп сукты, һәм җидәү генә килеп урнашты.

Чистай мәйданчыгының потенциаль резидентка тәкъдим итәр яклары бар. Аерым алганда, – 10,5 кв. м мәйданда ирекле җитештерү-склад бүлемнәре, алар клиентның техзаданиесенә яраклы итеп җиһазландырыла ала. Күп энергия таләп итүче җитештерүләр өчен үз өстенлекләре бар: үз фидеры булганга күрә, мәйданчык резидентларына электр энергиясен шәһәрнекеннән ике тапкыр түбәнрәк бәягә тәкъдим итә. Моннан тыш, сәнәгать мәйданчыкларының барлык преференцияләре эшли: резидентларның җиһаз алу өчен тоткан чыгымнарын субсидияли (бәясенең 50%ына кадәр, тик 5 млн сумнан артыграк түгел), Россия кредит оешмаларыннан алынган кредитларны түләгәндәге чыгымнарны субсидияли, оешмалар өчен 1 елга кадәрле «Лизинг-грант» программасы буенча 45%ка кадәр субсидия ясый (тик 1,5 млн сумнан артык түгел), һәм калганнарына – 30%ка кадәр (тик 5 млн сумнан артык түгел). Гомумән, үз җитештерү эшен башлаучылар өчен барлык шартлар тудырылган.

Мәйданчыктагы бүгенге резидентларның эш юнәлешләре төрле – су транспорты двигательләре өчен втулкалар ясаудан башлап, инновацион пресслау технологиясе буенча тышлау кирпече (облицовочный) җитештерүче мини-заводка кадәр.

Резидентларны җәлеп итәргә директорга үз тәҗрибәсе булыша – Юрий Михайлович мәйданчык оешмаларының берсе булган «Металлстрой» ҖЧҖгә җитәкчелек итә. Компания металл конструкцияләр – ишекләр, пандуслар, култыксалар җитештерә. «Металлстрой» «Уңайлы мохит» республика программасы субподрядчыларының берсе булып тора. Металл терәкләрнең бер өлешен – Кама аша сузылган күперне яктырту фонарьларын да монда әзерләгәннәр.

Күршедәге бүлемдә безнең игътибарны ниндидер җиңел материалдан әзерләнгән тротуар плиткасы үрнәкләре җәлеп итте.

– Без аны икенчел полимер чималыннан җитештерәбез. Татарстанда бу технология тәкъдим ителмәгән диярлек, – дип аңлата Алексей Савельев, «Мета-С» компаниясенең башкаручы директоры. – Бу плитканың аерым өстенлекләре бар – ул җиңел, нык, тузуга бирешми дисәң дә була. Бәясе бетон плиткадан әллә ни кыйммәт түгел. Ассортиментны киңәйтергә – шушы ук технология буенча канализация люкларын әзерләргә уйлыйбыз.

Алексей Савельев экспериментал ь үрнәкне дә күрсәтә – плиткага табигый таштан йолдызчыклар эретеп уелган. Көндез алар яктылыкны туплый, ә эңгер-меңгердә нурландыра башлый. Йолдызлар буйлап үтү – кызыктыргыч!

Әмма ялтыравык плитка әлегә тәҗрибә үрнәге булып кына кала. Кырыс икътисад шартлары лирикага урын калдырмый. «Мета-С», Чистай сәнәгать мәйданчыгының башка резидентлары кебек ук, туктаусыз кыйммәтләнүче чимал һәм тотрыксыз ихтыяҗ шартларында җитештерүне саклап калу өчен байтак тырышлык куя.

– Күптән түгел безнең резидентларның берсенә элек чит ил фирмасы белән хезмәттәшлек иткән эре бер компания заказ белән чыкты. Импортны алыштыру сәясәте шартларында ул хәзер үзенә кирәкне Россия тәэминатчыларыннан сатып ала, – дип сөйли Юрий Стахеев, сүз уңаеннан, ул – сәүдәгәр Стахеевлар нәселеннән. – КУЭ вәкилләре ала алырдай һәм импортны алыштырырлык тиешле продукция буенча мәгълүматлар базасы булса, шәп булыр иде. Бу республиканың күп сәнәгать мәйданчыклары үсеше өчен стимул булып хезмәт итәр иде. Чөнки кечкенә компанияләр, эреләреннән аермалы буларак, үз җитештерүләрен мондый заказлар өчен тизрәк арада үзгәртеп көйләргә сәләтле.

Реклама

PRESSA.RU

МОНДА КОРЫЧНЫ **ЧЫҢЫКТЫРАЛАР**

Мичтән гүләп эссе тарала. Казанда 1500˚С ка кадәр кызган алтынсу корыч кайный. Һәм менә казан авыша да сыек ялкын чүмечкә ага. Эшчеләр аны чүмечтән центрифугага күчерәләр. Ишеге ачык, центрифуга әйләнә, утлы катнашма цилиндрга әверелә. Берничә минуттан аны центрифугадан чыгарачаклар да суынырга куячаклар. Аннары секцияләргә кискәләячәкләр – алар ВАЗ җиңел автомобильләре модельләренең кайберләре өчен тормоз барабаннары бөҗралары булачак.

РАЙОННАР БУЙЛАП / МАХСУС ПРОЕКТ

Чистай сәнәгать мәйданы территориясендә урнашкан «Мегалит» ЖЧҖ цехында мичтән центрифугага кадәрле әлеге сыналган адымнар алгоритмын менә 10 ел башкаралар инде. Тик беренче карашка гына гади тоела ул.

– Без автопром өчен бөҗралардан башладык. Аннары су транспорты дизельләре өчен втулкалар чыгарырга керештек. Бер ел элек безгә моңа кадәр Украинада башкарылган заказны – РТЮ тепловозларының дизель двигательләренә втулкалар эшләүне тапшырдылар, – дип сөйли предприятие директоры Сергей Зубков. – Җитештерүне шактый тиз үзләштердек, хәзер 4 төрен чыгарабыз. Җитештерүне шулай ук киңәйтергә дә уйлыйбыз – әлеге мәйдан гына җитми.

Хәзер «Мегалит» Чистай сәнәгать мәйданының 500 квадрат метрлы цехына сыеша. Планнарында – шундый ук мәйданда күрше территорияне көйләү. Ә ни өчен үз предприятиесен сәнәгать мәйданы резиденты итәргә теләве турындагы сорауга Сергей иңнәрен генә сикертә – болай да билгеле бит инде. Җиһазлар сатып алу өчен ташламалар, арендага яхшы бәя.

– Шихта электр мичендә эретелә, бу коточкыч күп энергияне сарыф итү дигән сүз. Ә биредә ул, гадәти мәйданны арендалауга караганда, ике тапкыр диярлек кимрәк, – дип аңлата «Мегалит» директоры.

Әмма сәнәгать мәйданы шартларында да рентабельлек өчен көрәшергә туры килә. Соңгы ике елда корыч чималының бәясе туктаусыз үсә – 1,5 ел эчендә ул ике тапкыр диярлек арткан. Шул ук вакытта оешма үз продукциясенә бәяне күтәрә алмый – дәүләт компанияләре белән яңа килешүләр төзү процедурасы гаять тә катлаулы. Яңа төр продукцияләрне үзләштерергә кала, тик монысы да бик җиңелләрдән түгел.

– Күптән түгел безгә оборона сәнәгате объектлары өчен втулкаларга заказ керде. Мондый продукция күп баскычлы тикшерүләр аша үтә. РТЮ өчен гильзалар әзерләгәндә без тиз арада формуланы эшли һәм куллана башлауга ирешә алдык, ә монда – тулы бер проблема. Тиешле параметрлардагы корыч формуласын саклау өчен модификатор кирәк (металлның кристаллы рәшәткәсен формалаштыруга тәэсир итүче өстәмә), аны эшләүдә безгә республикада беркем дә ярдәм итә алмады. Урындагы белгечләр берничә технология эшләгәннәр иде, тик алар буенча тәҗрибә үрнәкләре ясап карагач, сыйфаты тотрыклы булып чыкмады, – дип сөйли Сергей.

Хәзер ул «Мегалит» заказы буенча Екатеринбург ФҖОсы белгечләре эшләгән модификаторны көтә.

– Билгеле инде, яңа җитештерү өчен технология булдыру – чыгымлы эш. Әмма без мондый шартларда да заказны башкарырга әзер. Кече предприятиенең аерым бер өстенлеге – шушындый мобильлектә, дип уйлыйм. Эре холдинглар өчен монда, табышларга караганда, кыенлыклар күбрәк, – ди Сергей.

Заказларның бөтен күләмен предприятие 15 кешенең көче белән башкара. Алар – ышанычлы, җаваплы кешеләр, кайберәүләре «Мегалит»ның беренче көненнән үк эшли. Бу вакыт эчендә җитештерү процессының бөтен нечкәлекләрен үзләштереп, оешма хезмәткәрләре бүген теләсә нинди катлаулылыктагы заказларны сыйфатлы итеп һәм үз вакытында башкара ала.

Әмма корыч коючының хезмәте, хәтта кечкенә җитештерү участогында булса да, авыр, бу өлкәдә белгечләр җитешми. Штатка технолог табып булмаганга күрә, Сергей, чарасызлыктан, бу профессияне үзе үзләштерә башлаган. Аннары инде продукциянең яңа төрләрен үзләштерүгә дә ерак калмый.

Реклама

МАХСУС ПРОЕКТ

— 15нче чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

PRESSA.RU

ЫШАНЫЧ БЕЛӘН АЛГА КАРАП

Хәлил Зиннурович Гыйниятов исеме илебезнең тармак саклану-сәнәгать җәмәгатьчелегендә дә, биредә, Татарстанда да, үз хезмәтенә тугры калуның үрнәге булып тора. Илебез сәнәгатендәге хәзерге заман җитәкчеләренең тулы бер (яисә бөтен диярлек) хезмәт биографиясенең бер генә предприятие белән бәйле була алуы – сирәк күренеш. Хәлил Зиннурович Казан дары заводына тулаем алганда 32 ел гомерен багышлады, һәм шуның 13 елы – директор вазыйфасында.

Ә бит шундый зур вакыт аралыгы җитештерүнең барлык серләрен белү яисә кирәкле һөнәри бәйләнешләр, зур идарә итү тәҗрибәсе тупланган иконлеген генә күрсәтми. Биредә шунысы да мөһим: әлеге шәхес өчен предприятие бик кадерлегә әйләнә. Ул аның традицияләрен, рухын үзенә сеңдерә, завод өчен кадерле булган һәр нәрсә аның өчен дә бик мөһим – остазлар, ветераннар, хезмәт династияләре, кадрлар. Ул, ниһаять, предприятиенең тарихын бик яхшы белә башлый. Ә КДКДЗның, билгеле булганча, тарихы бик бай.

Дары заводына (ул вакытта – В.И.Ленин исемендәге Казан химия заводы) аның булачак директоры 1979 елда Казан дәүләт университетының химия факультетын тәмамлагач килә. Яшь мастер, ә аннары технолог, шунда ук үзенең инициативалы булуы һәм эшләргә көчле теләге белән игътибарны җәлеп итә. Перспективалы белгеч тиздән дары цехының бер участогын (биредә ул заманча, ихтыяҗ булган эшләнмәләр җитештерүне үзләштерә), ә соңрак лак-буяу продукциясе чыгаручы цехны җитәкли башлый. Һәм алдагы «бишьеллык» эчендә цех заводның иң нәтиҗәле һәм рентабельле бүлекчәсенә әверелә.

Шуннан соң яшь җитәкченең оештыру сәләте республика дәрәҗәсендә кирәк була: алдагы ике елда ул Дәүләт милке белән идарә итү буенча ТР комитетындагы бүлекне җитәкли.

2000 елда Хәлил Гыйниятович үз стихиясенә, ягъни җитештерүгә кире әйләнеп кайта – «Казан оптика-механика заводы» ААҖнә. Баштарак ул генераль директорның коммерция мәсьәләләре буенча урынбасары булып эшли, ә аннары предприятиенең генераль директоры була.

Ниһаять, 2003 елда Хәлил Зиннурович туган дары заводы белән идарә итүне кабул итеп ала. Әгәр хәтерләсәк, барлык «оборонка» өчен дә, аерым шушы предприятие өчен дә бу бик катлаулы чор булды. Шулай булса да, яңа директор аңа хас булган энергия белән эшкә тотына, һәм иң кыска вакыт аралыгында югары квалификацияле кадрларны да, җитештерү базасын да саклап калып, заводны яңа дәрәҗәгә күтәрә. 2005 елда ул үзе җитәкчелек иткән заводның кыска вакытлы, уртача һәм озак вакытлы перспективаларга үстерү концепциясен төзү традициясен торгызып җибәрә. Вакыт шуны күрсәтте: өч федераль максатчан программада катнашу кебек үк, бу да шактый алга карап ясалган адым булып чыкты. Боларның барысы да җитештерүнең төп өлешләрен модернизацияләргә һәм яңа эшләнмәләр (шул исәптән чит илгә чыгару өчен дә) чыгаруга керешергә, җитештергән продукциянең сыйфатын яхшыртырга һәм җитештерү процессларында күп хезмәт куюны киметергә, персоналны проблемалы участок чикләреннән чыгарырга мөмкинлек бирде. Төп статистик күрсәткечләргә кагылып узсак, мәсәлән, сәнәгать җитештерүе индексы Хәлил Гыйниятов җитәкчелек итүенең беренче ун елында биш тапкыр үсте.

Әмма үзгәрешләргә җитештерү сәясәте генә дучар булмады. Билгеле булганча, зур хуҗалык механизмында барлык детальләр дә бер-берсе белән бәйләнгән: мәсәлән, тиешле дәрәҗәдәге кадрлар булмаса, уңышка ирешү мөмкин түгел. Шуңа күрә заводта «социалка»ны үстерүгә басым ясала. Бу эшләүче яшьләргә ярдәм күрсәтүдә дә, завод хезмәтчәннәренең керемнәре дәрәҗәсен күтәрүдә дә, яшь белгечләр һәм күп балалы гаиләләргә өстәмә түләүләр оештыруда да чагылыш таба. Моннан тыш, предпрятие көчле социаль инфраструктурасын да саклап кала алды. Нәтиҗәдә, предприятие эшчәнлегенең социаль юнәлеше тармакта иң көчлеләрнең берсе дип танылыла, ә завод үзе «Югары социаль нәтиҗәлелек оешмасы» исеменә лаек булды.

Мондый уңышларга җитәкче ягыннан көчле ихтыяр көче һәм чын кызыксыну булганда гына ирешергә мөмкин. Дары заводы белән булган очракта да бу коры сүзләр генә түгел: үзенең көндәлек эшчәнлегендә Хәлил Зиннурович тармакка кагыла торган яңа һәм алдынгы дип тапкан барлык нәрсәне дә үз заводында кабул итәргә һәм гамәлгә кертергә омтыла. Шуңа күрә дә Казан дары заводы киләчәккә ышаныч белән карый.

Хөрмәтле Хәлил Зиннурович! Без, Казан дары заводы хезмәткәрләре, Сезне һәрвакыт безнең предприятие чәчәк атсын һәм һәр хезмәткәрнең иртәгесе көнгә ышаныч хисе булсын өчен, мөмкин булганның барысын да эшли торган җаваплы һәм ышанычлы җитәкче буларак беләбез. Шуның өчен рәхмәт Сезгә! Сезне олы юбилеегыз белән котларга һәм сәламәтлек, бәхет, озын гомер теләргә рөхсәт итегез!

Реклама

Рафаэль Галимов,
«КВАРТ» АҖ
генераль директоры

Оборона җитештерү комплексын үстерүгә керткән өлешегез өчен рәхмәтебезне белдерәбез

Хөрмәтле Хәлил Зиннурович, 60 яшьлек юбилеегыз уңаеннан чын күңелдән әйтелгән котлауларны кабул итеп алыгыз.

Менә 13 ел дәвамында Сез Россиянең иң борынгы предприятиеләренең берсе булган Казан дары заводын җитәклисез.

Һичшиксез, шундый бай тарихлы һәм күркәм традицияләре булган предприятие белән идарә итү – ул искиткеч җаваплылык, шул ук вакытта намус эше дә. Әгәр җитәкче, директор постына билгеләнгәнче, күп еллар аның белән бәйле була икән, бу тагын да зуррак кыйммәткә ия. Сез, Хәлил Зиннурович, дары заводына күптән – 1979 елда ук килгәнсез, мастер, өлкән инженер, цех җитәкчесе булып хезмәт куйгансыз. Дөрес, Сезгә берара туган предприятиегезне калдырып торырга кирәк була, әмма аннары, завод өчен катлаулы чор башланып киткәч, Сез кире әйләнеп кайтасыз, әмма инде җитәкче буларак.

Сезнең идарә итә белү талантыгыз, үҗәтлегегез һәм хезмәт сөючәнлегегез, предприятие мәнфәгатьләрен яклау өчен үз дигәнегездә нык тора белүегез асылда мөмкин булмастай нәтиҗәләргә китерде – Казан дары заводы, нәкъ элеккегечә, икътисадый тотрыклылыкка, үсешкә ирешә һәм диверсификацияләүгә сәләтле булуын күрсәтте. Озак еллар дәвамында Сезгә тапшырылган предприятие оборона продукциясенең күп төрләрен үз илебездә эксклюзив җитештерүче статусын тотып тора. Сезнең тырышлыгыгыз нәтиҗәсендә завод уңышлы гына модернизацияләнде – хәзерге заман технологияләре кертелде, көндәшлеккә сәләтле продукциянең яңа төрләре өйрәнелде, хезмәт җитештерүчәнлеге һәм производствода куркынычсызлык шактый үсте.

Хәлил Зиннурович, әлеге истәлекле көндә Сезгә хас булган зирәклек, дөньяга ышанычлы караш, дәрт-дәрманның сакланып калуын, ә предприятиегезгә киләчәктә дә уңышлы, кирәкле һәм алдынгы булып калуын теләргә рөхсәт итегез.

Юбилеегыз белән!

Виктор Тагунов,
«Вымпел» Амур патрон заводы» ФКП
генераль директоры



Галина Казанцева,
«Вымпел» АПЗ»
ФКП башлангыч профсоюз оешмасы рәисе

Данлы традицияләрне лаеклы дәвам итүче!

Хөрмәтле Хәлил Зиннурович, «Вымпел» Амур патрон заводы» федераль казна предприятиесе коллективы Сезне чын күңелдән олуг бәйрәмегез – 60 яшьлек юбилеегыз белән котлый!

Әлеге датага Сез уңышлар һәм яуланган үрләрнең зур багажы белән килдегез. Гади белгечтән башлап, предприятие җитәкчесенә кадәр сузылган хезмәт юлы үттегез. Хезмәттәшләрегез Сезне үз эше өчен янып торучы, принципиаль һәм таләпчән җитәкче буларак беләләр. Сез дары җитештерүне техник яктан үзгәртү, яңа технологияләр кертү, оборона билгеләнелешендәге продукция номенклатурасын киңәйтүгә күп көч куйдыгыз. Республика алдындагы хезмәтләрегез өчен югары бүләкләргә ия булдыгыз.

Сез җитәкчелек иткән чорда Казан дары заводы шактый зур казанышларга иреште. Сез предприятиенең данлы традицияләрен лаеклы рәвештә дәвам иттерәсез, аны яңа дәрәҗәгә күтәрү өчен кулыгыздан килгәннең барысын да эшлисез. Завод тармакның стратегик предприятиесе булып тора, дәүләт заказы буенча дары һәм зарядларның 95 тән артыграк төрен чыгарырга сәләтле. Безнең предприятиеләр арасында тыгыз партнерлык һәм дустанә мөнәсәбәтләр урнашты.

Хезмәттәшлегебез алга таба да үсәр һәм ныгыр, дип ышанабыз, ә бу, әйтергә кирәк, ике коллективның да киләчәгенә уңай хезмәт итәчәк.

Әлеге истәлекле көндә Сезгә, Хәлил Зиннурович, шәхси тормышыгызда бәхет, сәламәтлек, бәрәкәтле эшчәнлек, иҗади күтәренкелек, оптимизм, барлык башлангычларда да уңышлар һәм катлаулы хезмәтегездә уйланылган планнарның һәрчак тормышка ашуын теләргә рөхсәт итегез.

PRESSA.RU

БЕРЕНЧЕ ТӨЗҮЧЕЛӘР НӘСЕЛЕННӘН

«Кама-Тракс» ТКФ генераль директоры Леонид Штейнберг сентябрьдә үзенең 70 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Леонид Данилович – үзенең бөтен вакытын диярлек яраткан эшенә багышлаган сирәк затлар нәселеннән. КАМАЗны төзү чорында, Яр Чаллының дәртле комсомол дружинасы командиры булганда, көндезләрен дә, төннәрен дә эштә үткәрә торган булган Штейнберг. 1992 елда «Кама-Тракс» ТКФ ҖЧҖне җитәкли башлагач та, ул вакыт белән исәпләшеп тормаган. Аның җитәкчелегендә Идел буенда халыкара йөк ташучылар арасында иң эреләр рәтенә баскан предприятие белән идарә итү дилбегәсен кулдан ычкындырмаган Леонид Данилович бүген дә хезмәттә. Шул ук вакытта иҗтимагый эшчәнлек тә беренчеләр рәтендә кала бирә аның өчен. Леонид Данилович – «Татарстанда логистика һәм автоташулар» коммерциячел булмаган партнерлык президенты, шәһәрнең беренче төзүчеләре иҗтимагый Советының актив әгъзасы. Ул хәйриячелек белән шөгыльләнә, сәләтле балаларга ярдәм итә һәм яшьләр өчен остаханәләр оештыра. Яр Чаллының мактаулы гражданины үзенең яраткан шәһәре өчен кулыннан килгәннең барысын да эшли.

Азат Бикмурзин,
«Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ генераль директоры

Сезнең янда бары тик тугры һәм ышанычлы дуслар гына булсын!

Хөрмәтле Леонид Данилович!

Юбилей бәйрәмегез һәм Сез җитәкли торган «Кама-Тракс» компанияләр берлегенә нигез салынуга 25 ел тулу уңаеннан чын күңелдән юлланган котлау сүзләребезне кабул итеп алыгыз.

«Кама-Тракс» Россиядә транспортның барлык төрләре ярдәмендә йөк ташуны тормышка ашыра торган эре транспорт компанияләре белән бер рәттә басып тора һәм «Түбән Кама Нефтехим» продукциясен төп ташучыларның берсе булып санала. Шундый ук ышанычлы һәм җаваплы булган яхшырак хезмәттәшне табып булмавына без күп мәртәбә инандык. Сезнең логистика өлкәсендә эшләү дәверендә тупланган зур тәҗрибәгез, кул астында эшләүчеләргә карата югары таләпчәнлегегез компания хезмәткәрләренең төгәл һәм көйле эш-гамәлләренең нигезе һәм «Кама-Тракс»ның безнең акционерлык җәмгыяте планын үтәүгә керткән лаеклы өлеше булып тора.

Безнең коллективларның хезмәттәшлеге алга таба да шундый ук уңышлы һәм үзара файдалы булыр, дип ышанам.

Юбилей көнегездә Сезгә чын күңелдән бәхет һәм озын гомер телим. Сезгә һәрвакыт һәм һәркайда уңыш юлдаш булсын, ә тормыш юлыгызда бары тик тугры һәм ышанычлы дуслар гына озата барсын! Өегезгә тынычлык, иминлек иңсен!

Гүзәл Моратова,
«Автоградбанк» АҖ Идарәсе Рәисе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы

Сезнең тәҗрибә һәм идеяләрегез бәяләп бетермәслек!

Хөрмәтле Леонид Данилович!

Олуг юбилеегыз уңаеннан «Автоградбанк» АҖ Идарәсе һәм коллективы исеменнән чын күңелдән әйтелгән котлауларны кабул итеп алыгыз!

Сез – эш кешесе! Җитәкче буларак үз стилегез бар. Бу – уңышлы идарә итү һәм югары профессиональлек, таләпчәнлек һәм куелган максатларга ирешә белү.

Сез башкалардан эшкә зур сәләтегез һәм принципиальлегез белән аерылып торасыз. Әлеге сыйфатларыгызны бизнеста да, иҗтимагый өлкәдә дә күрергә мөмкин! Сезне Яр Чаллы шәһәре мэриясе каршындагы Аксакаллар советы составына керергә чакырулары да очраклы түгел. Чөнки идеяләрегез һәм туплаган тәҗрибәгез күп кенә мөһим мәсьәләләрне чишәргә ярдәм итәчәгенә ышанычыбыз зур.

Сезнең хәйриячелек эшчәнлеген бәяләп бетерү дә авыр. «Безнең мирас» Сәләтле балаларга ярдәм итү фондындагы попечительләр советы әгъзасы буларак, Сез аз керемле гаиләләрдә тәрбияләнүче балаларга ярдәм итү өчен күп эш башкарасыз. Сезнең теләк буенча һәм турыдан-туры катнашуыгыз нәтиҗәсендә, Яр Чаллыда балалар һәм яшүсмерләр спортын үстерүгә финанслар бүлеп бирү һәм бу эшне оештыруда ярдәм күрсәтү тормышка ашырылды.

Ышаныч һәм үзара аңлашуга нигезләнгән күп елларга сузылган дустанә мөнәсәбәтләребез еллар узган саен ныгыр, дип ышанабыз. Алда безне әле күп матур эшләр көтә!

Сезне тагын бер мәртәбә туган көнегез белән котлыйбыз! Алга таба да Сезгә уңыш һәм ышанычлы дусларыгызның ярдәме насыйп булсын!

Үзегезгә һәм якыннарыгызга саулык-сәламәтлек һәм бәхет телибез!

Вячеслав Улитин,
«Буревестник» ҖЧҖ директоры

Татарстан йөк ташучылары хакына

«Буревестник» ҖЧҖ транспорт компаниясенең күпсанлы коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне тормышыгыздагы мөһим вакыйга – 70 яшьлек юбилеегыз белән котларга рөхсәт итегез!

Һәр кеше өчен үзе башкарган хезмәтнең бушка китмәвен, аның нәтиҗәләр бирүен күрә алу әһәмиятле. Бу җәһәттән Сез горурлана аласыз! Сезнең тырышлыгыгыз һәм үҗәтлегегез нәтиҗәсендә 2004 елда – Яр Чаллы шәһәре һәм «Кама аръягы» регионының Автомобиль йөк ташучылары ассоциациясе, ә бер елдан «Татарстанда логистика һәм автойөк ташулар» коммерциячел булмаган партнёрлыгы оештырылды. Бүген ул 600дән артык предприятиене берләштерә һәм Татарстан Республикасы йөк ташучыларының көндәлек әһәмияткә ия булган мәсьәләләрен уңышлы рәвештә чишү белән шөгыльләнә.

Алга таба да республиканың транспорт тармагында Сезнең ярдәм белән гади хезмәткәрләрнең эш шартларын яхшыртуга, логистика бизнесын оештыруны камилләштерүгә, аның нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлтелгән проектларның шулай ук уңышлы тормышка ашырылачагына ышанам. Һәм боларның барысы да ахыр чиктә тулаем регионның эзлекле рәвештә икътисадый үсешенә ярдәм итәчәк.

Хөрмәтле Леонид Данилович, Сезнең эшкә сәләтлелек һәм үҗәтлек, максатка омтылучанлык, җаваплылык кебек иң яхшы сыйфатларыгыз күркәм уй-ниятләрегезнең һичшиксез тормышка ашуына булышыр, дип ышанам.

Сезгә уңышлар һәм яңа үрләр яулавыгызны телим!

PRESSA.RU

Бисмилләһир-Рахманир – Рәхим!
Әссәламе-галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү!
Кадерле мөселман кардәшләр!

Сезне изге Корбан бәйрәме белән котлыйбыз! Бу иман, бердәмлек һәм миһербанлык бәйрәме. Безнең изге гамәлләр, мохтаҗларга ярдәм кулы сузарга омтылган көнебез. Корбан бәйрәме йортларыбызны иман нурына күмсен, күңелләребезгә тынычлык һәм шатлык иңдерсен.

Корбан бәйрәме – әле ул миллионлаган мөселманның Изге Кәгъбәгә хаҗ кылу вакыты да. Безнең күп кенә кардәшләребез, үз бурычларын үтәп, Изге Җирдә корбан чала. Безгә дә, Ходай ризалыгы хакына, хаҗ яисә кече хаҗ – өмрә кылу өчен мөмкинлекләр ачылсын.

Мәгълүм булганча, хаҗ ислам динендә һәр мөселман үтәргә омтыла торган баганаларның берсе. Кызганыч, хаҗ оештыру белән бәйле чыгымнар аркасында, күп кенә мөэмин-мөселман кешесе аны үти алмый.

Хаҗ кылырга ниятләгән гади мөселман кешеләренең финанс мөмкинлекләрен чит илләрнең уңай тәҗрибәсе буенча җиңеләйтү максатыннан, акча җыю системасын искә алып, Россия мөселманнарының Үзәк Диния Нәзарәте һәм Ислам финанслар йорты мондый системаны Россиядә куллану мөмкинлеге бирә торган Россия мөселманнарының «Хәйрия Хаҗ Фонды» дигән Бердәм хаҗ үзәген булдырды. Фонд барлык хаҗ кылучылар өчен Аллаһ кануннарына яраклаштырып, хаҗ кылуның бердәм стандартын эшләде.

Россия мөселманнарының «Хәйрия Хаҗ Фонды» Бердәм хаҗ үзәге хаҗның коммерциячел булмаган оештыручысы булып санала, һәм ул Россия мөселманнарының хаҗ оештыру буенча Советында аккредитацияләнде. Ташламалы турлар «Хәйрия Хаҗ Фонды»ның «Ислам финанслар йорты» ААҖ белән партнерлык программалары, шулай ук аз керемле мөселманнар өчен шәхси хәйрия ярдәме хисабына финанслана. Фонд коллективы даими рәвештә чит илләрнең һәм үзебездәге югары дини уку йортларында әзерлек үтә, алар анда бердәм стандарт дәрәҗәсендәге хезмәтләндерүче персонал квалификациясен ала. Без сезнең һәм гаиләгезнең Аллаһ йортына сәфәре уңайлы һәм хәлдән килердәй булсын өчен барысын да эшлибез. Сезгә иминлек, Аллаһ рәхмәте һәм бәрәкәт иңсен!

Хаҗ Фонды дирекциясе.

Хаҗ 120 мең сумнан башлана!

«Хаҗ һәм Гөмрәне Аллаһ ризалыгы өчен кылыгыз»

(«Әл-Бәкарә» сүрәсе, 196нчы аять).

БЛАГОТВОРИТЕЛЬНЫЙ ХАДЖ ФОНД
ALL RUSSIAN CHARITY HAJJ FOUNDATION

Хаҗ Фонды

Хаҗ кылу үсешенә ярдәм итүнең Бөтенроссия фонды

Яр Чаллыдагы вәкиллек
8-8552-912-848, 8-953-482-75-50

Россия Хаҗ-миссиясенең «кайнар линиясе» телефоны
8-800-555-15-15
Шалтырату бушлай

www.hajjfund.ru

Реклама

ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

Реклама бүлеге:
тел: (843) 222-09-76

Махсус проектлар бүлеге:
тел: (843) 222-06-05

Реклама 16+

ҺӘРВАКЫТ КИРӘК БУЛГАН СӘЛӘТ

ТР Предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре ассоциациясе президенты Александр Лаврентьев октябрьдә үзенең 70 яшьлеген билгеләп үтә.

Александр Петровичның хезмәт биографиясенең зур өлеше Казан вертолет заводы белән бәйле. 1970 елда предприятиегә килгәннән соң, ул һөнәри үсеш баскычлары буйлап инженер-конструктордан алып бүлек башлыгына кадәр юл узды. 1990 елда Александр Лаврентьев – инде «Казан вертолет заводы» ААҖ генераль директоры. Лаврентьевка хас профессиональлек, киләчәккә карап фикер йөртү авыр 90нчы елларда башта заводны яшәтеп калырга, ә аннары үсеш өчен яңа этәргеч бирергә ярдәм итте. Александр Петрович КВЗ белән 17 ел җитәкчелек итте, ә аннары Директорлар советы рәисе булды. Бүген Лаврентьевның идарәче сәләте элеккечә үк кирәк. ТР Предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре ассоциациясе президенты оешманың үз миссиясен җиренә җиткереп башкаруын оештыра – ТР эш бирүчеләренең законлы хокукларын яклау һәм аларның эшчәнлеген көйләү өчен барысын да эшли.

Ронис Шәрипов,
«В.И. Шимко исемендәге радиоэлектроника» ФҖБ АҖ генераль директоры

Рөстәм Абдуллин,
«Радиоприбор» АҖ башкарма директоры

Сез Татарстан Республикасы сәнәгатен үстерүгә зур өлеш керттегез!

Хөрмәтле Александр Петрович!

Юбилеегыз көнендә Сезне котларга һәм «В.И. Шимко исемендәге радиоэлектроника» АҖ һәм «Радиоприбор» АҖ коллективлары исеменнән чын күңелдән рәхмәт һәм ихтирам сүзләрен җиткерергә рөхсәт итегез!

Сезнең бөтен тормышыгыз һәм һөнәри юлыгыз – югары гражданлык, профессиональлек, хезмәт сөючәнлек, кешелеклелек, җәмгыять каршында зур шәхси җаваплылыкның ачык мисалы.

Сез Татарстан Республикасы сәнәгатен үстерүгә зур өлеш керттегез. Без Сезне дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, сәләтле оештыручы, зур тормыш энергиясенә һәм гаҗәеп эрудициягә ия кеше буларак беләбез, хөрмәт итәбез. Югары профессиональлегегез һәм бай эш тәҗрибәгез Сезгә сәләтле җитәкче дигән дан китерде.

Сез – күптөрле бүләкләр һәм исемнәр иясе, алар Сезнең күпкырлы һәм кызыклы шәхес булуыгызны раслаучы булып торалар. Сез күп нәрсәгә ирештегез, һәм алга таба тормыш Сезгә тагын бик күп итеп матур мизгелләр һәм кызыклы ачышлар бүләк итсен.

Александр Петрович, әлеге бәйрәм көнендә Сезгә ныклы сәламәтлек, гаилә иминлеге һәм Татарстан икътисадын һәм сәнәгатен үстерү эшендә бетмәс-төкәнмәс дәрт-дәрман телибез. Сезнең янда һәрвакыт ышанычлы дуслар һәм якыннарыгыз булсын, ә өегездән шатлык һәм җылы бөркелсен! Сезгә һәм гаиләгезгә күтәренке рух, тынычлык һәм тигезлек телибез!

PRESSA.RU

Илнур СӘГЪДИЕВ,
«Казан Компрессормаш» ААҖ
идарәче директоры

Күңел күтәренкелеге һәм бәхет телибез!

Хөрмәтле Александр Петрович!

«Казан Компрессормаш» ачык акционерлык җәмгыяте коллективы һәм шәхсән үз исемемнән 70 яшьлек юбилеегыз белән чын күңелдән тәбрик итәм!

Сезнең хезмәт биографиясенә һәркем сокланырлык. Безнең зур коллективта Сезне авиатөзелеш өлкәсендәге зур белгеч, А.Н.Туполев исемендәге Казан авиация институтын тәмамлап, зур тәҗрибә туплаган җитәкче-оештыручы һәм илебезнең машина төзү тармагын үстерү өчен шактый көч һәм энергиясен түккән эре җәмәгать эшлеклесе буларак беләләр һәм хөрмәт итәләр.

Дүрт дистә елдан артык вакытны Сез илнең вертолетлар төзү тармагында лаеклы рәвештә алдынгы булган Казан вертолетлар заводын торгызу һәм үстерүгә багышладыгыз. Биредә Сез һөнәри үсешнең инженер-конструктордан башлап, генераль директор, предприятиенең Директорлар советы рәисе вазыйфасына кадәрге зур һәм катлаулы юлын үттегез. Сезнең җитәкчелегегез астында заманча, ышанычлы һәм киң спектрлы куллануга ия булган һәм бөтен дөньяда танылган вертолетлар, мәсәлән, «Ми», «Ансат», «Актай» семьялыгына караганнары өйрәнелде һәм серияле итеп чыгарыла башлады. Сыйфатлы һәм ышанычлы булулары турында дөньяның күп кенә илләре җитәкчеләренең нәкъ менә аларга өстенлек бирүе сөйли. Сезнең энергиягез, эшкә сәләтегез, максатчанлыгыгыз, һәрвакыт диалогка әзер булып, партнерлар белән продуктив мөнәсәбәтләр төзи белүегезгә сокланырга гына мөмкин. Россия һәм Татарстан өчен бик үк җиңел булмаган чорда Казан вертолет заводын җитәкләвегез һәм бик авыр икътисадый кризис чорында предприятиене саклап кала алуыгыз да ихтирамга лаек күрсәткеч.

Сезнең данлыклы хезмәтегез лаеклы рәвештә дәүләт бүләкләре – «Почет билгесе», Дуслык ордены, IV дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлар өчен» орденнары белән билгеләп үтелгән, ә Казанның Мактаулы гражданины исемен йөртүегез халыкның Сезне чын мәгънәсендә тануы турында сөйли.

Соңгы елларда Сезнең Татарстан Республикасы Предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре ассоциациясе президенты буларак актив эш алып баруыгыз да олы хөрмәткә лаек. Монда да җитештерү өлкәсендә һәм тормышта тупланган зур тәҗрибәгез һәм киң эрудициягез республика сәнәгатенең төрле тармакларында килеп чыккан мәсьәләләрне уңышлы чишәргә ярдәм итә. Эш белән тәэмин итүчеләрнең региональ берләшмәсе җитәкчесе сыйфатында Сез инновацияле эшчәнлек өчен уңайлы шартлар тудыруга, көндәшлеккә сәләтле продукция җитештерүне арттыруга, социаль-икътисадый үсешнең иң мөһим бурычларын чишүгә ярдәм итәсез. Югары эшлеклелек, заманча фикер йөртү сыйфатларына һәм актив тормышчан позициягә ия булуыгыз белән Сез республиканың машина төзүчеләре коллективында зур ихтирам казандыгыз.

Сезнең энергиягез һәм даими рәвештә Татарстан Республикасы һәм аның халкына файда китерергә омтылуыгыз Сезгә ТР Предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре ассоциациясен җитәкләп кенә калмыйча, киң даирә мәсьәләләр һәм проблемаларны чишүне күз алдында тоткан Гомумроссия халык фронтының Татарстан региональ штабында рәистәш буларак актив эшчәнлек алып барырга да мөмкинлек бирә.

Хөрмәтле Александр Петрович, юбилей көнегездә Сезгә чын күңелдән нык сәламәтлек, бәхет, күңел күтәренкелеге һәм иминлек, хезмәтегездә алга таба да уңышлар телибез! Сезгә һәм якыннарыгызга бары тик иң изге теләкләр генә юлдаш булсын!

Рафаэль Галимов,
«КВАРТ» АЖ
генераль директоры

Татарстан сәнәгате аксакалы

Хөрмәтле Александр Петрович, Сезне чын күңелдән 70 яшьлек юбилеегыз белән котлыйм!

Татарстанның һәм тулаем алганда Россиянең сәнәгать өлкәсендә Сезнең исемегез һәркемгә таныш. Һәм һәркем өчен дә ул эшкә фидакарьләрчә хезмәт итү, зирәклек һәм алдан күрүчәнлекнең синонимы булып тора. Сез – безнең сәнәгатьнең аксакалы, әйткән сүзегез һәрвакыт вакытында кирәкле һәм әһәмиятле, ә Сез туплаган һөнәри һәм тормыш тәҗрибәсе – җитештерү тармагындагы һәр җитәкче өчен үрнәк.

Боларга Сез күп еллар буе Казан вертолетлар заводының генераль директоры вазыйфасында эшләгән чакта ирештегез. Нәкъ менә Сез җитәкчелек иткән вакытта әлеге предприятие җитештерүче булып кына түгел, ә бүгенге көндә даны бөтен дөньяга таралган вертолет техникасын уйлап чыгаручы буларак та танылды. Нәкъ менә Сезнең стратегик күзаллавыгыз һәм бетмәс-төкәнмәс энергиягез нәтиҗәсендә КВЗ тулы цикллы вертолетлар төзү компаниясенә әйләнде. Шуңа күрә Татарстан җитәкчелеге Сезне Татарстан Предприятиеләре һәм эшкуарлары ассоциациясе президенты вазыйфасына тәкъдим иткән чакта республиканың директорлар җәмгыяте кандидатурагызны берсүзсез кабул итте. Һәм ялгышмады – эш белән тәэмин итүчеләрнең хокукларын һәм ихтыяҗын яклау өчен әлеге оешманың файдасын бәяләп бетерү мөмкин түгел. Моннан тыш, без, сәнәгатьчеләр, предприятиеләрне үстерү буенча Сезнең киңәшләрегезне дә, Россия һәм дөньядагы макроикътисадый хәл буенча фикерегезне дә һәрвакыт аерым игътибар белән тыңлыйбыз, аларны исәпкә алабыз.

Александр Петрович, Сезгә исәнлек-саулык, барлык башлангычларыгызның бәрәкәтле булуын телибез. Республика һәм бөтен ил файдасы өчен алып барган гаять әһәмиятле эшегездә алга таба да зурдан-зур уңышлар юлдаш булсын.

Виктор Дьячков,
«ICL-КПО ВС» ААҖ
генераль директоры

Тормыш юлыгыз – ихтыяр көченең үрнәге

Хөрмәтле Александр Петрович!

Шәхсән үзем һәм АйСиЭл-КПО ВС коллективы исеменнән Сезне юбилеегыз белән котлыйм! Республикада Сез – күпләр өчен үрнәк шәхес, ышанычлы партнер, зирәк остаз, аркадаш. Үз эше өчен җан атучы кеше буларак та билгеле Сез. Сезгә ышаналар, сүзегезгә колак салалар, яныгызга киңәшләшер өчен дә килләр. Сезнең тәҗрибәгез, абруегыз, энтузиазмыгыз, максатчанлыгыгыз һәм киләчәккә ышаныч белән каравыгыз безнең күңелләргә дә Сезнең ярдәм һәм уртак тырышлык белән дөньяны яхшырак итә алачагыбызга ышаныч бирә. Тормыш юлыгыз – үзгәрешләр чорының иң авыр вакытында да үз идеяләренә һәм үз-үзенә тугры кала алган кешенең ихтыяр көченә ачык мисал. Минем өчен сез, һичшиксез, профессионализм үрнәге һәм ихтирамга лаек шәхес булып торасыз. Сезнең белән таныштырган һәм бәяләп бетергесез тәҗрибәгезне үзләштерү, яхшы киңәшләр алу мөмкинлеген тудырган язмышыма рәхмәтле.

Чын күңелдән Сезгә энергия, зур бәхет, нык сәламәтлек, куанычлар, иминлек, барлык башлангычларыгызда уңышлар, яңа тәэсирләр, фикердәшләрегезнең ярдәмен телим. Яныгызда һәрвакыт ышанычлы дуслар булсын, ә туганнарыгыз белән якыннарыгызның мәхәббәте һәм күңел җылысы Сезгә яңа биеклекләр яулауда көч бирсен. Эшчәнлегегезнең барлык юнәлешендә дә уңышлар юлдаш булсын!

Тыныч һәм имин тормышта озын-озак яшәргә насыйп булсын!

PRESSA.RU

Татарстан – яхшы кешеләргә генә түгел, гаҗәеп кызыклы риваятьләргә дә бай төбәк. Кайсы гына районга барып төшмә, үз якларына хас төгәллекләр белән тулы борынгы хикәятләрне сөйләп бирүче, барысыннан да хәбәрдар кеше һәрвакыт табыла. «Татарстан» журналы республикабыз риваятьләрен туплады һәм алар белән сезне дә таныштыра бара.

ТАТАРСТАН РИВАЯТЬЛӘРЕ: КАРА КҮЛДӘГЕ СУ ҮГЕЗЕ

Татарстанның Биектау районында урнашкан Кара күл ярларыннан берничә гасыр дәвамында һәр төн диярлек куркыныч тавышлар ишетелә, дип сөйлиләр. Әлеге тавышлар ярсыган үгез үкерүенә охшаган, һәм бу якларга ялгыш килеп чыккан һәм әлеге тавышны ишеткән Испаниянең иң кыю матадорлары да куркып калыр иде, мөгаен. Әмма Кара күл янында урнашкан һәм шул ук исемне йөрткән авылда яшәүчеләрнең берсенең дә әлеге үгезне күргәне юк.

Кара күл турында җирле халык арасында яман хәбәрләр йөри. Авыл халкы куркынып кына сөйли торган риваятьләр буенча, биредә һәр төн саен ачулы үгез тавышын хәтерләткән куркыныч тавышлар ишетелә икән. Һәм бу Биектау янына беренче кешеләр килеп утырганнан бирле дәвам итә, ди.

Риваять буенча, әлеге җан иясе су астында яшәгәнгә күрә, аны беркем дә тасвирлап бирә алмый.

Кайберәүләр кеше башлы үгез күрдек дип сөйләсә, икенче берәүләрнең күзенә мөгезле канатлы балык күренгән. Ләкин барысы да аны бер төрле – «су үгезе» дип атый.

Тагын элеккеге заманнарда аучылар һәм балыкчылар аудан исән-сау һәм табыш белән кайту өчен аңа корбан китергәннәр, дип тә сөйлиләр.

Әлбәттә, геологларның әлеге тавышлар буенча үз аңлатмасы бар: алар карст плитәләре һәм катламнары кучә, ә килеп чыккан бушлыкларга су тартыла, шуңа бәйле рәвештә әлеге куркыныч тавышлар килеп чыга, дип саный.

Әмма җирле халык үз ата-бабаларының фикеренә таяна. Һәм сулыкларда коенмыйлар. Саклангынны саклармын дигән бит.

Continental
The Future in Motion

Прошли сквозь пламя, чтобы покорить лёд

IceContact™ 2
от концерна Continental

- Улучшенное сцепление на льду благодаря увеличению количества шипов на 50% и их оптимальному распределению;
- Повышенный уровень безопасности благодаря инновационной технологии крепления шипов;
- Сокращение тормозного пути на ледяной поверхности*;
- В отдельных размерах шины доступны с технологиями: SSR™, ContiSeal™, ContiSilent™.

* По отношению к предыдущей модели IceContact™ компании Continental. Реклама.

ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН
КАМСКИЙ СУДАК
«ТАТАРСТАН»НЫ ТАТАР
ҺӘМ РУС ТЕЛЛӘРЕНДӘ УКЫГЫЗ!
НИЧЕК БОРГАЛАСАҢ ДА...
Реклама 16+